# Казан утлары

7
июль
1968

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

**7**

Июль
1968

## Бу санда:

ПЬЕСА, ХИКӘЯ, ПОЭМА ҺӘМ ШИГЫРЬЛӘР

**Ш. ГАЛИЕВ. Чаң турында баллада; Борын заман...; Хакыйкать; Тормыш — рифма; Бәйрәм итә халык...; Көнкүрештә шөгыльләр күп...; Үкенүләр; Тормыш кәмите; Тормыш иләгендә; Авыр минутларда; Яши идем...; Онытканды ди еп...; Дога.** Шигырьләр . . . . . . . . 3
**Ф. ХӨСНИ. Бәдретдин.** Хикәя . . . . . . . . 7
**Р. ИШМОРАТ. Шаулыйлар дулкыннар!..** Лирик драма . . . . . . . . . . . . . . . 10
**Х. КАМАЛОВ. Тормыш дулкыннары.** Поэма . . 52

ӘДӘБИ МИРАС

**Ф. ГЫЙЛМАНОВА. Язучы, журналист һәм публицист** . . . . . . . . . . . . . . . 57
**М. ГАЛӘУ. Болганчык еллар.** Романнан өзек . . 60

ДУСЛАР ҖЫРЫ

**С. СӘЙФУЛЛИН. Уюҗитмәс.** Легенда, Казакъчадан И. Салахов тәрҗемәсе . . . . . . . . . 82

ПУБЛИЦИСТИКА

**Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Көн дә уйлый торган уйлар** . 85

ТАТАРСТАН НЕФТЕНӘ 25 ЕЛ

**Ш. БИКЧУРИН. Тамырлар** . . . . . . . . . . 90

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

**А. ХӘСӘНОВ. Контрибуция.** Очерк . . . . . . 99

ТӨРЛЕСЕННӘН

**Г. САТТАРОВ.** Җирле географик атамалар сүзлекчәсе . . . . . . . . . . . . . . 106
**Ф. ВӘЛИЕВ.** Борынгы Болгар . . . . . . . . 112

ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**М. МӨХӘММӘДИЕВ. Тел байлыгыбыз һәм аңардан файдалану** . . . . . . . . . . . . 124

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

БАЯН ГЫЙЗЗӘТКӘ 50 ЯШЬ

**М. ГАЙНУЛЛИН.** Әдәбият һәм сәнгать белгече . 132

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Ә. КӘРИМУЛЛИН.** Казан татар матбагачылыгы тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . . . 134

САТИРА һӘМ ЮМОР

**Г. ГАЛИЕВ.** Минем Мәликәм. Хикәя . . . . . . . 147

УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

**Ш. ШӘЯХМӘТОВ.** Әлбинә кулын бирерме! . . . 152

СӘНГАТЬ

**С. ЧЕРВОННАЯ.** Имтихан уңышлы узды . . . . 154

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 156


**Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый**


Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*



Редактор урынбасары: **Ләбибә Ихсанова**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**



Производствога бирелде 15/V-1968 ел. Басарга кул куелды 25/VI-1968 ел. ПФ 05106.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 64146 экз.
Заказ Д-861. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1968 ел.

## Шәүкәт Галиев

# Чаң турында баллада

Тоболь музеенда 1591 елда Углич шәһәреннән сөрелгән бер чаң күрдем. «Беренче сөргенче» дип язылган иде аңа.

Күкерт иде халык нәфрәте,
Очкын булып чәчрәп чыкты чаң,
Ил алдында утлар чатнатып,
Патша янагына сукты чаң.

Түзеп-тынып гомер итәрме —
Халык айнып башын күтәрде.
Онытып законны һәм языкны,
Каерып алды имән казыкны!
Кинәнеп бер әй соң тукмады!

Ә чаң, ә чаң моны хуплады,
Көрәш авазларын туплады.
Беркөнне ул кинәт туктады...

... Күк читендә кызыл таң ата,
Байрак булып җирдә кан ята,
Яраланган җирдә чаң ята,
Күктән төшерелгән чаң ята...

Ахмак димә, патша — мәкерле,
Җәза-газап анда мең төрле;
Чанның телен йолкып алдылар,
Камчы белән аны ярдылар,
Муенына элмәк салдылар...

Шактый тәҗрибәле патшалар —
Телсез калдыралар башта алар...

Ирек даулап аваз салганга,
Озаттылар чаңны сөргенгә,—
Баш күтәргән ирләр баш иеп
Җирдән сөйрәп барды Себергә...

Кешеләрдән элек, беренче,
Шул телсез чаң булды сөргенче...

... Мәңге ятар иде Себердә
Ирек чаңы шулай сөргендә,
Тик шаулатып барлык чаңнарны
Чаңчы даһи туды Сембердә!

●

Борын заман гаҗәп тыныч булган —
Булса булган су һәм җил шавы.
Юллар озын...
Вакыт салмак аккан...
Галәмәт зур булган Җир шары!

Хәзер — үзгә...
Шар да бик бәләкәй;
Бер хәл булса берәр ягында,
Орынмыйча һич тә үтә алмый,
Йөрәгемә килеп кагыла.

## Хакыйкать

Туры сүзне чәчрәп әйткән чакта
Кая хәтер саклап торышлар —
Бер—беребезгә бигрәк мәрхәмәтсез,
Каты бәгырьле без тормышта...

Сискәндерә мине шундый уйлар,
Берәр иптәш китсә арадан...
Ә тереклек үзенекен итә,
Шул ук принцип яши яңадан;

Һәр кешегә ярап, мыштым гына
Йөри алырмын дип уйлама —
Яшәүдән һәм үлемнәрдән көчле
Хакыйкать бар әле дөньяда!

## Тормыш—рифма...

Якты бер сүз
Сөенеч бар,
Куләгәсе —
Көенеч бар.

Күз алдында
Яхшылыклар,
Күршесендә —
Шакшылыклар.

Туры сүзле
Кыю яши,
Рифмадашы —
Тыю яши.

Ярый, дөнья
Тыныч тора.
Баш өстендә
Кылыч тора...

●

Бәйрәм итә халык рәхәтләнеп,
Шау-шулы җыр, дәртле биюләр!..
Уен кәефенә кучәлмичә
Уйчан йөрим һаман мин юләр.

Тантанадан пыялалар зыңлый...
Абзаң маңгай җыерып утырмыш;
Әгәр мин дә каләмемне куйсам,
Туктап калыр сыман бу тормыш.

●

Кәнкүрештә шөгыльләр күп —
Анысы да монысы;
Тормыш жырын күмеп китә
Кайчак ыгы-зыгысы.

Тәгәрмәчтәге тиендәй
Бөтерелүдән тынып,
Дөньяга карыйм текәлеп,
Күзләремне тутырып.

Күнеккәнбез — имеш, бәхет
Гел киләчәктә көтә.
Сизмисең дә, менә шулай
Гомер үтә дә китә...

## Үкенүләр

Искә төшсә
Үткән көннәр,
Үкенүләр,
Үкенүләр:
Күрер кичәләрне
Күрмәгән өчен;
Йөрер жирләрдә
Йөрмәгән өчен;
Житәр теләкләргә
Житмәгән өчен;
Әйтер сүзләрне
Әйтмәгән өчен...

Искә төшсә
Үткән көннәр,
Күңелемдә
Үкенүләр,
Үкенүләр...

Ул арада үтә
Бүгенге көнең,
Өстәлмиме яңа бер
Үкенүең?..

## Тормыш кәмите

Мәшәкать белән көн үтә,
Яңасы тагын туа.
Син дөнья куган буласың,
Ә дөнья сине куа!..

## Тормыш иләгендә

Салмак орлык
Аска тарта,
Жиңел кибәк
Өскә калка.

Шулай була
Вакытлыча;
Орлык кала,
Кибәк оча!..

## Авыр минутларда

Бу арада илһам сирәк кунак,
Кинәт килә, кинәт югала.
Аяк очына карап җәяү үтәм...
Авызлыгын чәйнәп җырым кетә,
Җырым кетә кайсы юлларда?

●

Яши идем —
Сагынусыз,
Моңаюсыз,
Янусыз...

Син килдең дә
Таш аттың
Тын күлгә —
Тын күңелгә.

Уйлый идем —
Тынуыммы,
Суынуыммы,
Сынуыммы?

Хис дулкыннары
Уйнаттың,
Уйлаттың,
Һәм уяттың...

●

Онытканды́р диеп йөрисеңдер,
Рәнҗегән дә чагың буладыр.
Ни булса да мине уйлыйсындыр,
Төшкә керүләрең шуңадыр?..

Үзем дә еш карыйм күңелемнең
Истәлекләр дигән киносын,
Күз алдыма кояшлы көн белән,
Ромашкалар белән киләсең.

Ә күзләрең моңсу, сагышлылар,
Әйтелмәгән үпкә — иреңендә.
Син үзеңнең тәүге мәхәббәткә
Бүтән язмыш көткән идең лә...

Уртаклашыр уйлар туадыр да,
Юксынган да көннәр буладыр,
Яшьлегемә кайтып, сине күреп,
Йөрүләрем, ахры, шуңадыр...

## Дога

Сине генә уйлыйм күккә
Карап мин,
Адым саен исемеңне
Кабатлыйм.

Мин бәндәңне нигә һаман
Кагасың,
Газаплаудан әллә кызык
Табасың?

Минем хәтле сиңа беркем
Табынмас,
Минем кебек табынганнар
Табылмас.

Теләкләрем сиңа барып
Ирешсен,
Бергә булыйк, җанкисәгем,
Килеш син!

## Фатих Хөсни

# БӘДРЕТДИН

хикәя

Бәдретдиннең кече яшьтән үк биергә дәрте бик зур иде, ә менә биергә туры килмәде. Ник туры килмәде? Аңлатып булса, менә шул турыда сөйләргә җыенабыз да инде.

Дөресен әйткәндә, яшь чагында дәрт кемнеке дә булыр. Бәдретдиннең исә коры дәрт кенә түгел, ул биюнең техникасын, бөгелмәләрен-сыгылмаларын, кайсы биюдә аякны ничек борып алырга, гәүдәне ничек тотарга, парлап биергә туры килә калса, кулны туташның кай җиренә һәм ничек салырга икәнлеген, биеп туктагач, шул ук туташынны урынына ничек илтеп куярга кирәклеген — барысын да, барысын да белә иде. Сүз дә юк, теге хореография дигәннәренең бөтен хикмәтен өйрәнеп, һәртөрле «па»ларын белеп түгел, безнең авыл җирендәгечә, чама тартканча чамалап. Һәрхәлдә, килештерә алганча килештереп биегәнне яки, кәҗә бәтие кебек, сикергәләүдән узмаганны бик яхшы аера иде. Монысына без үзебез шаһит. Сәбәпләре дә бар иде моның, хәер.

Бәдретдин яшьтән үк авылның оста гармунчысы булып танылды. Аның уйнавын яраталар, бигрәк тә бию көйләрен — авылныкын да, радио аша, болай аралашу юлы белән, шәһәрдән кайтканын да — тәмам җиренә житкереп, дәрт һәм ярсу белән, аякны үзеннән-үзе очыра торган итеп уйный белә иде ул. Әле унөч-ундүрт яшьлек кенә малай чагыннан ук, клубта «вечер» буласы көннәрне, көндездән үк Бәдретдиннең көен көреп куялар, хәер, бу яктан ул алай назландырмый, ике әйттерми, вакыты җитүгә, ә кайбер көннәрне вакытыннан элек үк, клубка атылып бәрелеп ул килеп керә торган иде. Бөтен хикмәт тә шунда: ул гармунны ярата, клуб эченең шау-гөр килгәнен ярата, аякларның чаж-чож тыпырдап торганнарын ярата, хәтта — бусы беркадәр тилелек тә булгандыр инде — башкалар биегәндә аяк астыннан күтәрелә торган тузан исенә хәтле ярата торган иде. Әйе, болай үзе һич ялындырмас, шул ук вакытта үзенең базарын да тота белер. Әйтмичә, һич уртага чыгып утырмас, аның каравы бер әйттеләрме, икенче әйткәнне көтмәс, чыгар тыз-тыз гына басып. Алдан ук уртага чыгарылып куелган урындыкка җәлт кенә килеп утырыр. Җәелеп түгел, ничектер урындыкның читенә генә, очып китәргә җыенган кебек итеп кенә утырыр... Әй, сөйләп тә бетермәле түгел. Аннан бирле күп хәлләр кичте адәм башыннан, иске мәчеттән әтмәләгән иске клубны ватып, аның урынына колхоз өч йөз урынлы, киенүсяну бүлмәләре, шашка-шахмат, бильярд уйный торган җирләре булган зур яңа клуб салдырды. Гармунчыларның да төрлесен күрдек. Үзебездә-

геләр дә бар, Казаннан — филармониядән дә киләләр, мактана бу дип уйламагыз, дөресе шулай. Әмма теге вакытта Бәдретдиннең тыз-тыз атлап чыгып утыруы кебек утыра белүче гармунчыны күрә алганыбыз юк — ышансагыз, ышанмасагыз анысы сезнең эш. Чыгуында, урындыкка килеп утыруында, күз сирпеп карап алуында һәм, бигрәк тә, дәрт белән гармунын бер сузып, сызып җибәрүендә үк йөрәкне җилкендерә торган ниндидер әфсене бар иде аның. Уйладым, уйланам, мәгәр һич очына чыга алмыйм — кай ягы белән җилкендергәндер ул безне ундүрт яшьлек колдун?

Аннары ул унбиш яшьлек, уналты-унҗиде яшьлек, унсигез яшьлек булды, буй җитте, әзрәк усалланды, чак-чак кына ялындырырга да өйрәнде, кызлар аның артыннан үзләре тагылып йөри башладылар, әмма дә Бәдретдин Бәдретдин булып калды, гармунын ташламады, клубны ташламады, безне — иптәшләрен ташламады.

Әйтә идек үзенә кайчакларда:

— Кара әле, Бәдри малай, синең соң үзеңнең бер дә биисең килмимени? Бөтен бер авылны биетәсең, ә үзеңнең биегәнеңне тәки күргәнебез юк, — ди торган идек.

Менә шунда инде егетнең күзләрендә хәтәр ут чагылып китә, безгә томырылып бер карап ала бу — әллә ачулана, әллә көлә бу бездән, белгән кеше юк. Ләкин нәрсә булса да әйтергә ашыкмый. Кулына гармун алса, кешене дә җилкендерә, үзе дә җилкенә белә торган безнең ул Бәдретдинебез сүзгә алай батыр түгел, кеше әйтеп бетермәс борын, кабаланып, бергә ун белән җавап кайтарырга ашыкмас — яшьрәк чагында да шулай иде, хәзер дә шулай.

— Биергә булыр иде, ник булмасын,— ди бу бераздан, бер дә ашыкмыйча гына,— әлегә мин үзем белән парлап биердәй кыз таба алганым юк, ә ялгыз бисем килми.

Әлбәттә, шаяртып кына әйтә ул бу сүзләрне. Шаярткалыгы күзләреннән, тавышын уйнатып әйтүеннән үк сизелеп тора. Шулай икәнлеген без үзебез дә белеп торабыз, кызлар дигәнең муенына асылынырга торалар Бәдретдиннең. Авылда бер гармунчы, буй-сыны да коеп куйган, эшкә дигәндә дә ким-хур түгел, янәсе имеш, кыз таба алмый бу. Юри мәтәштерә, факт.

Шулай да озак аптырап йөрергә калдырмады бу, бер көнне чын дөресен ярып салды безгә:

— Биергә дисез сез. Әллә мин үзем белмимме? — дип башлады бу, безнең сүзгә чак-чак кына ачуланган кебек итеп. Ачуланмаса да, һәрхәлдә, уйнап сөйләшкәнгә бер дә охшамый иде,— бик тә бисе килгән чаклар була, парлап биергә кызын да тапкан булыр идем, орлыгы Бохарада түгел кызларның... Ләкин уйлап караганыгыз бармы: кем уйнаганга биетмәкче буласыз Бәдретдинне? Бармы соң мине биетерлек гармунчыгыз?

Бу болай гына, кәкрене кыекка сапларга торган кешегә генә бераз тегеләйрәк ишетелер: янәсе, үзен әллә кем итеп куя икән боларның бу Бәдретдин дигән егетләре, дип уйлаулары мөмкин. Ә Бәдретдинне якынтын белгән, аның дәртле уйнавына биеп үскән кешеләргә, менә безгә, бигрәк тә ул сүзләрне Бәдретдиннең нинди ачыну һәм өзгәләнү белән әйткәнлеген ишетеп торганнан соң, алай уйларга һич резон юк. Оста гармунчы, аннары тагы бию дигән хореографияне тамыры-җелеге белән белә торган Бәдретдин әллә синең Түбән оч Хәйри малаеның җылатып азаплануына биер дисеңме? Биемәгән кайда! Аңарга булса булсын, үзе уйнагандагы кебек, аяклардан ут чәчрәтеп торсын.

Һич онытасым юк, күңеле купшынган иде ул кичне Бәдретдиннең. Болай үзе күп сөйләргә яратмый торган безнең ул егетебез күңеленә килгәнне кире җибәрмәде. Бераз тын торганнан соң, безгә тагын мондый сүзләрне дә әйтте:

— Бар минем өйрәтеп үстерә торган берничә егетем. Минә алардан, ичмасам, көтәргә була. Ничава! Әле соң түгел, өлгерербез биергә...

Ул моны, кулына гармун тоткан чагындагы кебек, бик дәртләнеп-хыялланып әйткән иде, югыйсә. Ә менә егетнең ул хыялы барып чыкмады. Элек башкаларны өйрәтеп, алар өйрәнгәнче үзе уйнап, клубта «вечер» булган саен безне — авыл яшьләрен шашындырып-очындырып килгән ул егетне, инде менә үзенә вакыт, дигәндә генә, 1941 нче елгы сугыш башланып, фронтка алып киттеләр.

Фронтта ул начар биемәгән булса кирәк, күкрәгенә тагып кайткан орденнары, медальләре шул турыда сөйли иде. Ләкин, шул ук вакытта, фронт аның бер аягын да алып калган иде.

Еллар узды, сугыш беткәнгә дә инде байтак, башта бер әйтеп үткәнебезчә, безнең колхоз болын хәтле зур клуб салдырды. Клуб көн дә кич яшьләр белән шаулап тора. Кайсы шашка-шахмат уйный, кайсы бильярд суга, күбесе шунда, чаж-чож аяк киеме ышкып, бии. Яшь гармунчылар үсеп житте, яңа җырлар, яңа биюләр хәзер — исемнәре генә дә телне сындырырлык. Шулар арасында — клубта кайбер кичләрне безнең Бәдретдин дә күренгәли. Сакал-мыекны ялтыратып кырган, өстендә өр-яңа костюм, мин сиңайтим, кереп туктар, сөялер ишек яңагына, шуннан ник кенә бер адым китсен, үзе башлап ник кенә бераүгә сүз катсын. Тора, сәгатьләр буена тора карап — күзләрендә әллә соклану, әллә яшь? Әллә икесе дә бергә? Белгән кеше юк. Аңарга урындык тәкъдим итәләр.

— Утырып торыгыз, Бәдретдин абый,— диләр.

Утырмый Бәдретдин. Шулай ук урын тәкъдим итүчегә рәхмәт әйтергә дә ашыкмый Бәдретдин. Күрәсең, белә үзенекен: аласын тулысынча алып бетермәсә дә, бирәсен артыгы белән биргән, дөнья алдында төчеләнергә, баш иярга теләми.

*Апрель, 1968.*

**Риза Ишморат**

# ШАУЛЫЙЛАР ДУЛКЫННАР!..

ЛИРИК ДРАМА

## 3 пәрдә 7 картинада

**КАТНАШАЛАР**

| | |
|---|---|
| Айсылу | Гөлзифа |
| Рәзилә | Яшәр |
| Сәрия | Бәркет |
| Минсрур | Акбүләк |
| Нэлли | Мәгъсүм |

Вакыйга безнең көннәрдә Акшәһәрдә бара.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

#### БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

Айсылулар яши торган баракта кечерәк кенә бер бүлмә. Унда ишек. Ул Яшәр белән Рәзилә бүлмәсенә чыга. Вакыт кич. Тышта көчле җил сызгыра. Күңелгә нindидер борчу салып, музыка уйнап куя. Бераз паузадан соң, куркып коты алынган сары бөдрә чәчле яшь кыз — Сәрия йөгереп керә дә ишекне тиз генә ябып, тоткасын тотып тора.

Сәрия *(авыр сулап)*. Уффф!.. Тотып ала да хәзер бугазымнан буа дип торам... *(Тыңлый.)* Айсылу!.. Рәзилә!.. *(Түрге ишеккә килеп карый.)* Берсе дә юк... *(Тыштагы тавышны тыңлап тора.)* Ярабби!!! Гомер буена шулай тетрәнеп яшәргә калдымыни хәзер? *(Карарга килеп, тумбочка тартмасыннан кәгазь, каләм алып яза башлый.)*

Ишекне киң итеп ачып Рәзилә керә. Башына бәйләгән косынкасы артка төшкән, кара, озын чәчләре тузгыган.

Рәзилә *(түрге ишекне ачып, сузылып карый)*. Кайтмаган... Сәрия! Мин юкта Яшәр кайтып китмәдеме?

Сәрия. Күрмәдем.

Рәзилә. Син гел өйдә булдыңмы?

Сәрия. Әле кайтып кердем.

Рәзилә *(ишек яңагына сөялгән килеш)*. Кайларга гына китеп югала көн саен... Әй, ник бәйләдем шуңа газиз башларымны. *(Сыгылып төшә, җылый.)*

Сәрия *(Рәзилә янына килеп)*. Рәзилә!

Рәзилә. Белмисең хәлемне, Сәрия! *(Кочаклап җылый.)* Ата буласы кешe бит... *(Кискен.)* Ә мин аны табам. Табачакмын һәм...



Спектакльнең режиссерлары Вәкил Закиров белән Делюс Ильясов, композитор Хөснул Вәлиуллин һәм балетмейстер Рычков әсәрнең авторы Риза Ишморат белән

Сәрия. Төнгә каршы? Җитмәсә шундый шомлы җил.

Рәзилә. Булсын.

Сәрия. Күрәсеңме тәрәзәгә ничек бәрә...

Рәзилә. Бәрсен... *(Сәрия кулыннан ычкына да бәреләсугыла чыгып китә.)*

Сәрия утыра. Яза. Айсылу керә. Өстәл янына килә дә кулындагы китап һәм дәфтәрләрен өстәлгә ташлый. Утыра да бөтен күңеле белән укуга чума.

Сәрия *(Айсылу янына килеп)*. Айсылу! Айсылу, дим.

Айсылу *(башын күтәрми генә)*. Нәрсә?

Сәрия. Яшәр бүген дә кайтмады.

Айсылу *(эшендә дәвам итеп)*. Кайтмаса бит...

Сәрия. Рәзилә өзгәләнә...

Айсылу. Өзгәләнсә бит...

Сәрия. Урамда шундый җил... Ә ул Яшәрне эзләп китте.

Айсылу *(эшеннән аерылып)*. Яшәрне? Ә Яшәр кая?

Сәрия. Әйтәм ич, кайтмады.

Айсылу. Кайтмады?! *(Кызу гына барып ишекне ачып карый.)* Ул бит миңа сүз бирде. Бүген өйдә булам, диде.

Сәрия. Яшәр сүзенә ышансаң...

Айсылу. Яшәрдән дә бигрәк гаеп әле бүген Рәзиләдә булды. Урын җиреннән торып җитмәде, битәрли башлады. Әйтмәгән сүзен калдырмады.

Сәрия. Яшәргә аз әле ул.

Айсылу. Юк, Сәрия...

Сәрия. Яклама!.. Ирләр барысы да бер алар. *(Язуын Айсылуга бирә.)* Мә, сәлам хат сиңа.

Айсылу. Хат?

Сәрия. Укы...

Айсылу *(укып)*... Сәрия Янбулатовадан. Гариза. *(Укыган саен гаҗәпләнә барып.)* Син? Бригаданы ташлап?!

Сәрия. Әйе. Бөтен төзелешне, Акшәһәрне калдырып.

Айсылу. Иң җаваплы чорда?

Сәрия. Җавапсыз чорның булганы да юк бездә.

Айсылу. Җибәрмим! Җибәрмибез! Син безгә комсомол путевкасы белән килдең. *(Җил тавышына игътибар итеп.)* Җил нинди котыра. *(Тәрәзәне яхшылабрак ябып куя.)* Эх, Рәзилә... Шундый кичне бит... *(Китабын ябып өстәлгә ыргыта.)*. Булмады! Тыныч кына әзерләнимме дисәм, башта ут булмый интектерде. Аннан инде... вакыт бетте, имеш, китапханәне ябам, ди, Касыймов абый. Ай, бу вакытны... Тәүлеге дә бит нибары егерме дүрт сәгать кенә. *(Чигәләрен тотып тынсыз кала. Утыра.)* Сиңа ни булды, Сәрия?

Сәрия. Туйдым. Эшеннән дә... Акшәһәрдән дә.

Айсылу. Ышанмыйм, Сәрия.

Сәрия. Син ышан!.. Күңелсез монда. Ни театры, ни рәтле киносы юк. Ичмасам, биер урыны булса икән.

Айсылу. Биер иденме.

Сәрия. Ничек кенә әле. Их-х!.. *(Ярсып.)*

Су буенда зәңгәр чәчәк
Өзелеп суга төшәчәк.
Без төзибез яңа тормыш,
Иске тормыш бетәчәк.
*(Жылый-жылый бии.)*
Бас эзенә генә,
Кара күзенә генә,
Карасаң күзенә генә
Булыр үзеңә генә.

Син бит берни дә белмисең, Айсылу! *(Үкереп җылый.)* Авыр миңа яшәүләре.

Айсылу. Тукта, ни булды сиңа? Нигә сөйләмисең?

Сәрия. Миңамы? Юк... Сөйләмим.

Айсылу. Гашыйк булгансың әле...

Сәрия. Аллам сакласын.

Айсылу. Әйтмә! Мәхәббәт шундый хикмәт ул, аңардан башка бәхет тә, хәтта кеше тормышының үзе дә юк диләр ич акыллы агайлар.

Сәрия. Акыллары корысын ул агайларның.

Айсылу. Я әле сөйлә, яшермә. Бәлагә очрадыңмы?

Сәрия. Элек мин шундый чәлән кыяфәтле идеммени? Киткәндә ни әйтте әни, йөремә, кызым, харап буласың, диде. Юк, тыңлыйммы соң. Җенем котыртты. Имеш, син бәхет өчен туган кыз. Ә бәхетең, имеш, яңа төзелешләрдә. Яңа шәһәрдә. Аны үзең төзеп керсәң, ул бермә-бер артыграк булачак.

Айсылу. Җен түгел, моны акыллы кеше әйткән сиңа.

Сәрия. Тыңлап бетер әлек. Шул ук җен болай ди тагын: төзелеш әле бәхетеңнең яртысы гына, икенче яртысы алдыңа матур егет кыяфәтендә килеп басар, ди. Яратыр сине, син дә аны яратырсың. Кайнар һәм тигез мәхәббәт белән бергә-бергә, имештер, тормыш юлыгызны узарсыз. Ышандым бит шуңа. Ун классны тәмамладым да әниемне җылата-җылата, дус-иптәшләремнән аерылып, Ангарага киттем. Сигез ай яхшы эшләдем. Көндез эштә, кичен клубта. Биим, җырлыйм. Шуннан бер вакыт алдыма бәхетемнең икенче яртысы килеп басты. Әй җаным, аның матурлыгы!.. Сөйкемлелеге!.. Акылга — диңгез, сүзгә — былбыл һәм шундый наз... Гел бергә булырга чакыра бу мине... Бәхетле булырбыз, ди... Ой!..

Айсылу. Нәрсә?

Сәрия. Бер көнне ул кинәт кенә кочаклап алды да шундый үпте мине... Ә мин... бөтенләй югалдым.

Айсылу. Шуннан.

Сәрия. Моның янына һәр көн барып йөри башладым. Кайчак атналар буе анда калам. Үземне аның хатыны итеп исәплим. Загс ту-

рында сөйләшәбез. Ә аның исәбендә дә юк... Бүген-иртәгә дип йөртәме йөртә. Ирекле, бәхетле тормыш өчен аның кирәге юк, ди. Ике ай үтмәде, туйды бу миннән. Җикеренә! Сөйләшми йөри. Кайчакта үйный, көлә. Назлаган булып, буа мине, кытыклый. Һуштан яздыру хәленә китерә. Сизәм, ничек тә котылырга тели бу миннән. Шулай итеп, былбыл дигәнем козгын булып чыкты. Нишләргә. Кемгә чишәргә серне? Әллә комсомол комитетына барып сөйләргәме, дип тә уйлыйм. Беләм, ул файдасыз. Бердән, ул комсомол түгел, икенчедән, аны гаепләп сөйләрлек, башкаларны ышандырырлык сүзем дә юк. Җитмәсә ул төзелештә авторитетлы эшче... ударник. Тик сизә күңелем: тагын да бераз яшәсәм, һәлак итәчәк ул мине. Шуннан бер көнне әйберләремне җыйнадым да китәргә булдым. Күрде бу мине, белде ниятемне... А!!. Ул минутлар!.. Аның зәһәрле күзләре... Йөзе... Сүзләре... Әле дә тетрәнәм...

Айсылу. Нинди сүзләр?

Сәрия *(шикләнеп карана)*. Хәтерләмим. Безнең бергә булганны, аның кыланышларын кемгәдер сөйләсәм, мине дөньяда йөретмәячәкмен, диде. Сөйләмәскә ант иттерде. Соңыннан белдем: мин аның бишенче хатыны булганмын. Икесен аерып җибәргән, берсе ниндидер серле шартларда үлгән, берсе минем кебек үзе китеп котылган. Миңа да ул-бу булмасын дип, бөтенләй Ангарадан ук киттем. Мин бит аны, аның белән үткән хурлыклы көннәремне бөтенләйгә күңелемнән сызып ташларга теләгән идем.

Айсылу. Кем иде соң ул?

Сәрия. Телгә алырга чирканам. Куркам да. Менә, менә килеп керер дә буып ташлар төсле.

Айсылу. Ангара бездән ике мең километр.

Сәрия. Акшәһәрдә ул хәзер.

Айсылу. Акшәһәрдә?!.

Мәгъсүм *(ишекне ачып)*. Мөмкинме икән, кызлар.

Айсылу. Әйдә, кереп кара.

Мәгъсүм керә. Таза, киң җилкәле, житез хәрәкәтле егет.

Мәгъсүм. Рөхсәт булгач инде анысы керәбез дә и карыйбыз да. Тик менә Сария ни әйтер.

Айсылу. Сария түгел, Сәрия.

Мәгъсүм. Мин дә шулай дим ич — Сария.

Айсылу. Нишләп йөрисең шундый давылда?

Мәгъсүм. Һәй, мондый давыл ирмәк кенә ул моряк өчен. Да, да! Яратам давылны. Бигрәк тә аңа каршы барулары күңелле. *(Җырлый.)*

Җилфер, җилфер итмәсә, Сария,
Җилләр алып китмәсә, Сария,
Эштә батыр, төскә матур
Сандугач баласы ла,
Эштә батыр, төскә матур,
Ударница житмәсә.

Айсылу. Сәрия ошый алайса сиңа?

Мәгъсүм. Бик. Пәрәккә май булып ята.

Сәрия. Башка җыр җырла син, Мәгъсүм.

Мәгъсүм. Ә миңа шул җыр гына ошаса?

Сәрия. Ул инде бик иске. Җырланган җыр. Син соңга калгансың.

Мәгъсүм. Минем өчен ул яңа, беркайчан да искермәячәк матур җыр. *(Җырлый.)*

Ике матур суга бара, Сария,
Җем-җем кара чиләге, Сария,
Безнең шәһәрнең кызлары
Сандугач баласы ла,
Безнең шәһәрнең кызлары
Пешкән кура җиләге.

Ярый, жырын жен алсын. Мин әле икенче ният белән килдем. Сине кинога чакырырга.

Сәрия. Шундый давылда? Кыр аша пычрак ярып йөрергә?

Мәгъсүм. Яртысы асфальт юл. Сазлык урыннарда күтәреп алып чыгармын.

Сәрия. Юк инде, Мәгъсүм абзыкай, күтәрми тор, яме.

Айсылу. Тукта инде, Сәрия, Мәгъсүм яхшы ният белән килгән, а син кире кагасың...

Сәрия чыгып китә. Нишләргә дә белми аптырабрак калган Мәгъсүмгә Айсылу «Бар инде!» дип Сәрия артыннан чыгарга киряклеге турында ишарә ясый. Мәгъсүм чыгып китә. Пауза.
Ишек шакыйлар.

Акбүләк. Мөмкинме?

Айсылу. Керегез.

Акбүләк керә. Дулкынланып торган кара чәчле, маһабәт сынлы чибәр егет. Өстендә бик ыктымат кына тегелгән килешле костюм. Сул кулын ак чүпрәк белән бәйләгән.

Акбүләк. Хәерле кич!

Айсылу. Акбүләк абый?! Ни булды сезгә?

Акбүләк. Канауга төшеп баткан бер машинаны чыгарышканда бәлагә очрадым. Йодыгыз юкмы?

Айсылу. Хәзер. *(Йод һәм марля алып килә.)* Бирегез әле.

Акбүләк. Ул кадәр куркыныч түгел.

Айсылу. Кулыгыз белән кагылмагыз. Килегез, башта юыйк. *(Акбүләкнең кулын спирт белән юа.)* Менә шулай... Хәзер бәйлибез... Менә шулай...

Акбүләк. Ай!..

Айсылу. Сабыр итегез, Акбүләк абый. Югыйсә кулсыз каласыз.

Акбүләк. Әрни...

Айсылу. Түзегез.

Акбүләк. Түзүләре бик авыр.

Айсылу. Хәзер, хәзер. *(Марля белән бәйли.)* Һу-у... мангаегыздан тир бәреп чыкты. *(Кулъяулыгы белән Акбүләкнең тирен сөртә.)*

Акбүләк. Бирегез, үзем, Айсылу.

Айсылу *(кырыс)*. Тик кенә утырыгыз.

Акбүләк. Нинди генә рәхмәтләр әйтергә инде сезгә?

Айсылу. Бернинди дә *(йод савытын аптекага урнаштырып)*. Я, беттеме әрнүе?

Акбүләк. Кулымныкы бетте.

Айсылу. Тагын кай жирегездә, нинди яра бар?

Акбүләк. *(йөрәген күрсәтә)*. Менә монда...

Айсылу. Ой, юк. Йөрәкярагызны бәйләргә осталыгым җитмәс.

Акбүләк. Син генә бәйли аласың аны, Айсылу.

Айсылу. Юк, Акбүләк абый, булдыра алмам, мөгаен. *(Пауза.)* Бездә бүген күңелсезлек әле.



Айсылу ролендә Нәҗибә Ихсанова. Акбүләк — Ирек Баһманов.

Акбүләк. Нәрсә бар?

Айсылу. Эштән соң Яшәр тагын өйгә кайтмады.

Акбүләк. Харрасовмы?

Айсылу. Унбиш көн инде... Тәмам чыгырдан чыкты. Хатыны Рәзиләгә дә көн күрсәтми.

Акбүләк. Сәбәбе нәрсәдә соң? Сөйләшеп караганың бармы?

Айсылу. Бар да соң, әйтәмени ул. Кызык кына аның характеры. Кайчакларда бик шат күңелле, шаян... Ә кайчак шундый күнелсез, ачулы, аска карый да тик уйланып йөри. Бездәге гаделсезлектән зарлана. Квартира сорап трестка, Курамшинга барган иде, ә ул сөйләшмәгән дә, куып чыгарган. Шуңа бик хурланып кайтты. Өч-дүрт көн беребез белән дә сөйләшмәде... *(Пауза.)* Акбүләк абый, әллә син сөйләшеп карыйсыңмы? Тик начальник булмыйча гына сөйләш, яме.

Кылтый-былтый атлап Яшәр керә. Рәзилә йөгереп керә дә түрге ишеккә килеп баса.

Рәзилә *(ишеккә аркылы төшеп)*. Кайда йөрдең?

Яшәр. Анда синең эшең юк.

Рәзилә. Эшем юк?

Яшәр. Туйдым. Синнән дә... барыннан да. Акшәһәр, имеш... Ха!.. Ал кулыңны!

Рәзилә. Алмыйм, Яшәр.

Яшәр кинәт зур күзләрен ачып, Рәзиләгә карап тора. Пауза.

Яшәр. Бу син?!..

Рәзилә. Яшәр бәгырем *(кочаклап җылый.)* Әйт, нигә син шундый хәзер? Син бит миңе мәңге яратачакмын дип ант иттең...

Яшәр. Иттем... Син бит үзең дә...

Рәзилә. Ә мин сине яратмыйммы? Яратам!.. Яратам, Яшәр бәгырем! *(Кат-кат үбә.)* Үтенәм, бәгырем, әллә нинди хатыннар белән йөреп хурлама, газаплама мине. Син бит комсомолец. Син...

Яшәр. Нәрсә?! Тагын мораль укыйсың... Тагын...

Бүлмәгә үтәргә тели.

Рәзилә *(ишек тоткасына ябышып)*. Яшәр бәгырем...

Яшәр. Җитте, ал кулыңны...

Рәзилә. Яшәр...

Яшәр. Ал диләр сиңа.

Рәзилә. Алмыйм!

Яшәр. Алырсың! *(Рәзиләнең беләгеннән ала да нык итеп этәреп җибәрә. Рәзилә егыла, ләкин шунда ук торып, Яшәр каршысына килеп баса.)*

Акбүләк *(Рәзиләгә сугарга дип кизәнгән Яшәргә)*. Тилермә, Яшәр.

Яшәр. Арага кермә, мастер!.. Миндә эшегез булмасын.

Акбүләк. Эшебез бар, Яшәр!

Яшәр каты итеп Рәзиләгә суга.



Рәзилә — Нуруллина.

Айсылу. Яшәр!..

Рәзилә сыны катып тын да чыгармыйча сыгылып төшә. Шунда ук сикереп тора да бүлмәгә кереп Яшәрнең чемоданын чыгарып куя. Тагын кереп китеп мендәр белән җәймә һәм аккордеон күтәреп чыга.

Рәзилә. Менә әйберләрең. Бар. Күземә күренмә, кит!
Яшәр. Кит! Ха-ха!
Рәзилә *(кычкырып)*. Хәзер үк кит!! Бар!! Кит!!
Айсылу. Шашма, Рәзилә.
Рәзилә. Җитәр, күп чыдадым. Китсен! *(Җылый.)* Тәнем күгәрмәгән җир юк. Йөрәк яраларымны сөйли торган да түгел.
Яшәр. Әз әле сиңа.
Айсылу. Бүген дә намусыңны эчеп кайттыңмы?
Яшәр. Китегез!..
Рәзилә. Юк инде, үзең кит, бар. Менә әйберләрең... Менә чемоданың...
Яшәр *(зәһәр белән)*. Нәрсә? Чемодан...
Рәзилә. Менә аккордеоның...
Яшәр. Аккордеон? *(Күтәрә дә идәнгә бәрергә тели.)*
Айсылу. А-а...
Акбүләк *(Яшәр кулыннан аккордеонны тартып ала)*. Юк, дускай, син инде шаярма алай.
Яшәр. Үз аккордеоным, теләсәм нишләтәм. *(Акбүләк кулыннан алмакчы була.)*
Акбүләк. Юк әле, эшләтми тор.
Яшәр. Бир монда...
Рәзилә *(кычкырып)*. Бирмәгез!..
Яшәр. Синең эшең юк анда.
Рәзилә. Бар!
Яшәр. Ах, бар, мә!.. *(Почмакта яткан утын агачын алып Рәзиләгә кизәнә.)*
Айсылу, Акбүләк. } Яшәр!!!
Рәзилә *(Яшәр каршысына басып)*. Сук!..

Кечкенә чемодан күтәреп, шәлгә төренгән мәһабәт сынлы карчык Миңсрур апа керә дә аптырап ишек төбендә тора.

Сук, сук! Балаңны да, мине дә бергә үтер.
Миңсрур. Исәнмесез, балалар!
Яшәр. А-а... *(әнисен күреп аптырап кала)*.
Миңсрур *(Яшәргә)*. Нишләвең бу синең, улым? *(Пауза.)*
Айсылу. Минсрур апа, ничек болай, төнгә каршы чыгасы иттегез. Шундый давылда. Кырык километр җирне.
Миңсрур. Яшәрнең ниндидер бәлагә очравы турында төрле хәбәрләр ишеттем дә юлга чыктым... Давыл дип кенә ничек өйдә түзеп утырасың... Ярый әле, рәхмәт төшкере, юлда бер шофер очрады, югыйсә җәяүләп килә торгач, тәмам хәлдән тайган идем. *(Ишектән төенчеген күтәреп кергән Бөркеткә.)* Бик зур рәхмәт инде улым. Изге җан икәнсең.
Бөркет. Рәхмәт әйтерлек урын юк, апа... Менә төенчегегез...
Миңсрур. Кая, әз генә булса да кучтәнәч бирим әле. *(Төенчекне чишә башлый.)*
Бөркет. Юк, юк, апа. Берни дә кирәкми.
Яшәр. Ал, ал биргәндә.
Бөркет. Яшәр?! Синме соң бу? Хәерле кич, дус! Чү, төсең киткән, әллә авырыйсыңмы? Көндез генә сау-сәламәт идең. Әллә инде исергәнсең...

Я ш ә р. Юк! Яшәр беркайчан да исерми... Һәм исермәс тә.
Б ө р к е т. Беләм, син тәртипле егет. *(Башкаларга баш иеп.)* Хәерле кич, дуслар!

Бар да баш иеп исәнләшәләр.

Син инде әниеңне хөрмәтләп каршы ал, кунак ит, дустым.
Я ш ә р. Бүген... бераз гына кәефләнеп кайттым. Син инде, әни, ачуланма.
Б ө р к е т. Әниләрне беркайчан да борчырга ярамый. *(Колагына.)* Гафу үтен.
Я ш ә р. Әни!.. Нигә алай сәер итеп карыйсың! Әйдә, утыр... Гафу ит.
Б ө р к е т. Әгәр иптәшләреңнең кәефен җибәргәнсең икән... Алардан да гафу сора...
Я ш ә р. Мин?!. *(Пауза.)*
Б ө р к е т. Гаебебез бар икән, гафу үтенү, кеше булган кеше өчен, беркайчан да хурлык түгел, Яшәр дус. Олы йөрәклелек, кешелеклелек...
Я ш ә р. Кеше... Кешелеклек... Дөньяда бөтен бәланең башы — кеше, әнә шул кешедә дә инде.
Б ө р к е т. Ялгышма, дустым. Кеше табигатьнең иң кыйммәтле җәүһәре. Безгә — кешеләргә карата, менә нәрсә ди Хәйям:

Бу дөньяда иң зур максат кыясы — без,
Акыл күзе нурларының кояшы — без,
Әгәр галәм түгәрәк бер йөзек икән,
Шиксез аның мең алтынга тиң кашы — без.

Шулай булгач, кешене — үзебезне хөрмәт итик инде, дустым. *(Башкаларга.)* Гафу итегез, зинһар, тоткарладым...
А й с ы л у *(әсәрләнеп)*. Сез бик мәгънәле һәм матур шигырь укыдыгыз. Язучысын кем дидегез әле.
Б ө р к е т. Гомәр Хәйям... Борынгы Иран шагыйре.
М и н с р у р. Изгелегең өчен зур рәхмәт сиңа, улым. Сау-сәламәт бул. Әйдәгез әле, балалар, бүлмәгезгә керик...

Рәзилә белән Яшәрне бүлмәгә алып кереп китә. Алар артыннан Бөркет тә керә.

А к б ү л ә к. Ярый, Айсылу, бүгенгә хуш, ә иртәгә... эштән соң, сөйләшербез.
А й с ы л у. Хуш, Акбүләк абый, тәмле йокы сезгә.
А к б ү л ә к. Сиңа да шулай ук, Айсылу... *(Китә.)*
А й с ы л у *(авыр сулап)*. Мең чуалчык... мең бәла... Барысы да бер башыңа синең, Айсылу. Чишәлсәң чиш, чишәлмәсәң дә чиш... *(Китапларын алып.)* Әй... сынауларны биреп институтка кереп алсам, башкалары җиңелрәк чишелер иде, мөгаен.
Б ө р к е т *(чыгып барган җиреннән тукталып)*. Гафу итегез...
А й с ы л у. Сез?..
Б ө р к е т. Хәйям шигыре бик ошады кебек сезгә. Әгәр теләсәгез, китабын биреп тора алам. Дөрес, бераз таушалган ул, иске... Әммә эчендә шагыйрьнең алтын юллары. Ширази белән Сәгъди дә, борынгы Кытай һәм Япон шагыйрьләренең дә кайбер үрнәкләре бар.
А й с ы л у. Бик яхшы булыр иде дә, тик...
Б ө р к е т. Минем үз машинам. Эштән соң көн саен диярлек йөз, йөз егерме километр җир әйләнеп килә́м. Теләсәгез бер узып барышлый кертеп чыгармын.
А й с ы л у. Мәшәкать димәсәгез...
Б ө р к е т. Юк, юк, һич!.. Әгәр инде вакыт таба алсагыз, үзегез кереп алыгыз. Дүртенче квартал, җиденче йорт. Бөркет дип сорасагыз, бар да күрсәтер.

Айсылу. Исемегез Беркетме?

Беркет. Исемем Борһан, Борһан Байсаров. Иптәшләр шулай үзара Беркет дип йөртәләр. Һәрвакыт биектә эшләгәнем өчендер инде, мөгаен.

Айсылу. Сезнең һөнәрегез нинди соң?

Беркет. Монтажчы-высотник. Күп вакыт алтмыш-җитмеш, хәтта йөз, йөз егерме метр биеклектә, беркетләр генә очып җитә торган җирдә эшлибез.

Айсылу. Кыюлар, көчлеләргә хас һөнәр сайлагансыз.

Беркет. Кыюларга хасмы икәнен әйтә алмыйм, ләкин романтика, поэзия эзләүчеләргә хас һөнәр — анысы дөрес.

Айсылу. Беркет! Әйбәт! Мин Айсылу Җәгъфәрова. Ташчы, бригадир, йортлар салам.

Беркет *(кулын бирел).* Бик шат. Чын-чынлап, Айсылу! Ишегем дә, күңелем дә һәркемгә ачык минем.

Айсылу. Бәлки килермен дә.

Беркет *(нәзакәтлек белән).* Хушыгыз, Айсылу.

Айсылу. Хушыгыз... Беркет.

Беркет ишеккә борыла. Анда — Сәрия. Ул яңа гына кереп баскан. Беркетне күргәч, алга узарга да, чыгып китәргә дә белмичә, аптырап тора.

Беркет *(ягымлы).* Рәхим итегез.

Сәрия сүзсез генә баш иеп алга уза. Беркет китә.

Сәрия *(гаризаны бирел).* Мә, Айсылу, мине эштән бушатуларын сорап, язып бир.

Айсылу. Җүләрләнмә, Сәрия. Беркая да җибәрмибез!

Сәрия. Барыбер китәм. Син дә, Акбүләк абый да риза булмасагыз, кадрлар бүлегенә барам.

Айсылу. Юк, Сәрия, беркая да җибәрмибез!

Гаризаны ертып ташлый.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Хәзерге стиль белән җиһазланган Беркет бүлмәсе. Киң, иркен, җыйнак. Дугалы кресло, өстәл, диван, радиола. Стенада зур рәсем. Балконның ачык ишеге аша, кызарып кояш баеганы күренә. Бер як читтә бокс тренировкасы өчен күн тышлы туп эленгән. Ут яктыру белән Беркет Яшәрне алып керә.

Беркет. Әйдә, кер, Яшәр дус.

Яшәр *(сокланып карап).* Шәп яшисең.

Беркет. Квартир ул, Яшәр дус, кеше бәхетенең яртысы. Аерым квартирың бармы — кеше син. Хуҗа! Үзеңә ошаганча яшисең. *(Әкрен генә җырлый.)*

Кемгә сөйлим серләремне
Йөрәгем ялкын кебек.
Ялкынланган йөрәгемә
Бирәү бик якын кебек.

*(Сөйләп.)*

Аның өчен кырлардагы
Чәчәкләр җитмәс кебек.
Чәчәкләр дә йөрәгемне
Аңлатып бетмәс кебек.

Я ш ә р. Гашыйк булгансың, ахры.
Б ө р к е т. Һәрвакыт гашыйк мин.
Я ш ә р. Ялгызың гына инде син?
Б ө р к е т. Иректе башымны гаилә чылбырына бәйләргә... Юк...
Я ш ә р. Күңеленә ошаган берәр әйбәтрәк кыз очрасамы? *(Башын селкеп.)* Һей...
Б ө р к е т. Килен булып килгәнче, бөтен кыз да бик әйбәт, изге фәрештә кыяфәтендә була, ә килгәч, шайтанга әверелә дигән ич бер философ.
Я ш ә р. Шайтанга?.. Ой, дөрес әйткән дә ул философ.
Б ө р к е т. Шул шул әнә.
Я ш ә р *(тупка игътибар итеп)*. Нигә асып куйдың монда бу тупны?
Б ө р к е т. Бокс гыйлемен өйрәнәм... *(Тупны бәргәли.)* Раз, два, раз, два! Кара менә, өйрән! *(Йодрыгын Яшәрнең борын төбенә куеп.)* Менә монда, я монда — раз!
Я ш ә р *(бераз Беркетне карап тора да диванга килеп утыра)*. Уф, йөрәк сызлый...
Б ө р к е т. Бер кайчан да, берни өчен дә эчең пошмасын синең. Күр, нинди матур булып кояш байый. Төн килә. Ә төннең үзенә бер яме бар. Төн куркыныч дисеңме? Юк! Авторитетлы кешегә берни дә түгел. Ә синең белән миндәге авторитет, аллага шөкер. *(Мускулын күрсәтә, йодрыгын йомарлый.)* Менә кара. Безнең кебек егетләргә һәр заманда да шушы инде авторитет. Йодрыгы ныкның йөрәге нык, йөрәге ныкның акылында тәртип. Берсе берсенә үрелеп бара.

Чәчәкләр дә йөрәгемне
Аңлатып бетмәс кебек.

Беләм инде, дус, Рәзиләң кайгысы синдә. Бөтен мәхлук ирләр кебек, мөгаен, бәхетем ул гына, эчкән һәм эчәчәк шәрабләрнең мөкатдәс касәсе ул гына дип уйлыйсыңдыр. Хәтта аның өчен Гомәр Хәйям сыман алланың үзенә жикренә торгансыңдыр. Шулай, шулай.

Әбрико мәййо мәра шикәсти, раббн!
Бармән дәро гыйшра бәбәсти, раббн!

Я ш ә р. Ничек, ничек?
Б ө р к е т. Фарсычасы бу, үзебезчә болайрак:

Шәраб касәмне ваттың нигә, раббем?
Бәхет ишегемне яптың нигә, раббем?
Минем ал ширбәтемне жиргә түктең,
Исерденме әллә син юкса, раббем.

Я ш ә р. Исерден? Ха-ха-ха! Менә, ичмасам, әйткән.
Б ө р к е т. Сигез йөз ел моннан элек...
Я ш ә р. Шул чакны ук аллага тел озайта? Кыю...
Б ө р к е т. Безнекеләр өлкәнрәк начальникларга да тел тидерми.
Я ш ә р. Дөньяда яшәселәре бар ич.
Б ө р к е т. Кеше булган кеше куркып яшәмәсен ул дөньяда. Яратмыйм куркакларны. Шулай, дус, яши белеп яшәгән кешегә генә ул дөнья.
Я ш ә р. Дөньяныкын белмәссең. Ата-анасы юк аның. Әйтәләр ич, дөнья иске моржа — әйләнә дә төтен кайтара.
Б ө р к е т. Һи!.. Дөнья ул, дустым, дүрт капкалы, өч капкасын япсалар, берсе барыбер ачык кала. Яшь чакта, исән чакта дөньяның рәхәтен күреп кал, дус. Тик инде, кара, рәтен белеп. Урлама! Күп эчмә. Дәүләт милкенә кагылма! Ә алла хәзинәсен кызганма. Аллаһе тәгалә үзе үк: «Минем өчен бер дә гөнаһ кылмаган фәрештәләремә караганда, хәзинәмдә бары белән файдаланып, гөнаһ кылганның соңында тәүбәгә килгән иблис шайтан күп кадерлерәк», — дип әйтә ди ич!



Бөркет — Наил Әюпов.

Яшәр. Алла әйтер, ул рәхимле... *(Диванда яткан журналларны карый.)* «Чехословакия», «Польша», «Америка».

Бөркет *(журналның битләрен ачып-ачып).* Менә, ничек яши анда кеше... Ух, паразитлар... Кара, техника нинди, йортларын күр, җиһазларын... Иректә тормыш шул — демократия. Кеше үзе теләгәнчә яши. Күр, ничек котырынып бии менә бу егет белән кыз.

Яшәр. Журналга язып була, бизәп тә була...

Бөркет. Дөньясында шулай булмаса, бик бизәп тә булмый.

Яшәр. Бир миңа бу журналны!

Бөркет. Юк, булмый, үзем дә кешедән генә алып тордым. Шулай ул, дускай, кеше җәмгыять өчен генә түгел, үзе өчен дә яшәргә һәм әйбәт итеп, үзенчә яшәргә тиеш. Дөньяга без үз ихтыярыбыз белән килмәгән. Әгәр безне хөрмәтле эти-әниләребез бар иткәннәр икән... Бигайбә! Яшәвен инде үзебез теләгәнчә яшик. Иртәгә түгел — бүген, дөнья шулай инде ул...

Ул картая, бу — алмашка үсеп житә.
Яшәү шулай — чиратлашып дәвам итә.
Дөнья һаман кемнеке дә түгел хәлдә
Килгән китә, бүтән килә, ул да китә...

Так что, дускай, безгә дә бер китәргә туры киләчәк. Ә киткәнче, давай әле... Беренче кат өемә килгәнсең икән. *(Рюмкаларга салып эчәргә алып килә.)* Монысыннан да авыз итик. Күп түгел. Әз-мәз генә. Күңелне һаман күтәренке тоту өчен. Акшәһәр, комбинат, химия, ди, ди, егылганчы эшлә эшлә дә кайтып баракта ауна, имеш.

Яшәр. Ике ел азапланам. Квартир сорап баргач, жилком фабкомга, фабком замтрестка җибәрә. Ә замтрест. Ух, хурлык, валлаһи!.. Өйгә кайткач, Рәзилә битәрли. *(Пауза.)* Син ничек алдың соң бу квартираны.

Бөркет. Ала белсәң, мондыйны гына түгел, шәбрәген дә алып була, Яшәр дус.

Яшәр. Миңа да алып бирешсәң иде, ә?

Бөркет. Нигә? Чамалыйбыз аны.

Яшәр. Чыннан да?

Бөркет. Әйтәм бит чамалыйбыз да и алабыз да. Син аңа лаеклы, Яшәр дус. Яратам сине. Теләсә кемгә баш имичә үз акылың белән яшәгәнең өчен яратам.

Яшәр. Иркенрәк, үзем теләгәнчәрәк яшәү өчен мин әле институтка керү дигән уемнан да ваз кичмәкче булып торам.

Бөркет. И бик дөрес эшлисең. Инженер, аннан ниндидер бер начальник булып өстеңә җаваплылык алырга?.. Кирәге юк. Аның өчен ахмаклар да бетмәгән. Миңа кара, мин... инженердан, я булмаса, шул ук директорлардан начар тораммы әллә.

Яшәр. Рәзилә белән дә эшне җайласам...

Бөркет. Хәле ничек соң әле аның.

Яшәр. Һаман сызлана, эчем, ди.

Бөркет. Шул кадәр гайрәт күрсәттең, ә?

Яшәр. Булды инде.

Бөркет. Ахмак син, Яшәр дус. Хатынга кул күтәрә торган заманамыни хәзер. Җитмәсә комсомол башың белән. Культурага өйрәтәсең килә икән, я инде аерылып котылырга ниятең бар икән, башка юллар беткәнмени?

Яшәр. Бетмәгән дә бит...

Бөркет. Юк, сукма син аңа, ачу да чыгарма йөзеңә. Ни, ни, ни!.. Эшләмә андый ахмаклык. Иркәлә, кочакла, яратам, дип кысып сөй дә... Кытыклап хәлдән тайдыр. Үп, назла һәм... Ә кичен яткач, үткен сүзләр белән үгетләпме үгетлә. Хатыннарның үзләре шикелле үк игәүлә, игәүлә! Үзең һаман елмай, көл, шаяр. Беркайчан да синең өстеңнән жалоба бирерлек булмасын. Шундый хәлләрдән соң Рәзиләң үзе үк ташлап качар. Качар! Миң чакрымга. Аннан соң син богаудан азат. Ирекле җан һәм главное — пакьтан пакь, сафтан саф.

Яшәр. Үзеңнең шулай богаудан котылып, сафтан саф калган чакларың булгаладымы соң?

Бөркет. Мин дә бит, дустым, изге шәех түгел, гади кеше. Димәк, кеше татыган ләззәтне татырга минем дә хакым бар.

Яшәр. Шуңа, ахры, матуррак кызларга күзең төшә синең, дус.

Бөркет. Каян алып әйтәсең?

Яшәр. Теге көнне безнең Сәриягә күзең төште ич.

Бөркет. Сәрия? Кем ул Сәрия?

Яшәр. Безнең белән эшләүче кыз... Сары чәчле...

Бөркет. Ә-ә... хәтерлим... Матур кыз. Ләкин минем үземә ошамый андыйлар.

Яшәр. Ошаса да сиңа була торган түгел.

Бөркет. Ни өчен?

Яшәр. Китә ул Акшәһәрдән.

Бөркет. Китә?! Кая китә? Ни өчен?

Яшәр. Кая киткәнен белмим, китәм, ди. Бая гаризасын тотып кадрлар бүлегенә бара иде.

Бөркет. Димәк, Акшәһәрдән туйган.

Яшәр. Үзе дә шулай, ди, туйдым, шуңа китәм, ди.

Бөркет. Һәркемнең үз ирке. Мин үзем дә еллар буе бер җирдә эшләргә яратмыйм. Яшь чакта күбрәк дөнья күреп каласы килә... Яңа шәһәрләр, яңа кешеләр... Шулай-й... шулай-шулай... Советлар Союзы киң... Һөнәрем күп минем. Ин югары разрядлы монтажник... Югары класс шофер. Уртадан югары финансист, уртадан югары химик...

Яшәр. У-у... Димәк, ике-өч җирдә яртышар институт. Әти-әниләрең кем соң синең, Бөркет дус?

Бөркет. Әти инженер, завод директоры. Әни әдәбият укытучысы, доцент. Куйбышевта яшиләр. Әмма биш ел инде аларның миңа бер катнашлары да юк. Минем үз дөньям, үз бәхетем. Ир егеткә әти, әни кулында ярым кол булып яшәү хурлык ул. Кеше гомере кыска, шуңа

күрә һәр минуты кадерле. Сезнең ул сары чәчле кызыгыз да яшәү кадерен белә, мөгаен. Хәерле юл телик аңа, Яшәр дус.

Яшәр. Белмим, юл булып ук бетәр микән әле. Бригадир бик үз сүзле безнең. Җибәрмим, ди.

Бөркет. Җибәрмим?! Кем соң ул?

Яшәр. Әнә, теге көнне бар иде бит бер җәбхәер... Айсылу исемле кыз.

Бөркет. Әйе. Хәтерлим... Тик мин аны акыллы кызга санаган идем ул көнне.

Яшәр. Аның акыллылыгыннан миләр чатный кайчакта, йөрәк... Шундый чәберчектәй генә кызчык сиңа акыл биреп, команда биреп йөрсен әле.

Бөркет. Димәк, кызу характерлы?

Яшәр. Җенле!

Бөркет. Усал дамы?

Яшәр. Аждаһа!..

Бөркет. Шулай да үзе сөйкемле кыз. Айсылу булгач, Алсуның сеңелесе, мөгаен.

> Үзе усал, үзе сөйкемле,
> Ә үзе бер дә
> Усал түгел кебек шикелле.

Яшәр. Кебек шикелле булса, өйлән, күрерсең.

Бөркет. Өйләнсәм? *(Тәрәзәгә карап.)* Чү! Кая бара болар.

Яшәр. Кем?..

Бөркет. Нэлли, Гөлзифа белән. *(Тәрәзәне ачып.)* Кая киттегез?

Нэлли *(арттан)*. Паркка. Әйдә син дә.

Бөркет. Юк! Үзегез монда керегез.

Нэлли. Син ялгыз гынамы?

Бөркет. Яшәр дә мин генә...

Яшәр. Ой!.. *(Йөгереп китә.)*

Бөркет. Җүләр! *(Яшәрне куып тотып, тәрәзәгә алып килә. Кызларга.)* Керегез монда! Чынлап. Яшәр дә чакыра. Ә?.. Керәсез? Рәхим итегез. *(Тәрәзәне ябып, Яшәргә.)* Я әле, тәртипкә китер үзеңне. Нэлли нәзакәтлекне ярата. Кыюрак бул! Рюмкаларны хәзергә алып куябыз.

Яшәр. Торсын... Коньягы да калсын.

Бөркет. Юк. Эчеп-исереп йөргәнне адәм рәтле кыз яратмый. Әгәр инде күңел күтәрерлек кенә чамаласаң, хөрмәт, почет сиңа. Кызлар алдында да, киң дөнья алдында да...

Яшәр. Ә бөтенләй эчмәсәң, димәк...

Бөркет. Шыр җүләр буласың. Андый кешене кызлар гына түгел, өлкән абзыйлар да төшеп калганга саный. Тагын шул сиңа, Яшәр дус, әгәр алар монда чагында кем дә булса берәр ят кунак килеп чыкса, мин ымлау белән Нэллиләрне алып китәрсең. Ярыймы?

Яшәр. Пожалуйста... Тик...

Бөркет. Шым! Май кап! *(Ишеккә бара.)* Рәхим итегез!

*Өр-яңа модада, ләкин яхшы зәвык белән киенеп-ясанып Нэлли керә.*

Нэлли. Һау-ду-юду!..

Бөркет. Олрайт!.. Рәхим итегез! Нэлли! Сандугачыбыз безнең.

Нэлли. Сандугач, әйе сандугач, тик сиңа дип сайрар микән ул. *(Яшәргә карап елмая, кул изи.)*

Бөркет. Дустым өчен сайрасаң, мин аңа да шат.

Нэлли. Ярый ла көнләшмәсәң...

Бөркет. Юк... көнләшмим.

Нэлли. Ә кем белә. *(Җырлый-җырлый Яшәр янына килә.)* Сәлам сөеклем...

Яшәр *(уңайсызланып)*. Нэлли!..

Н э л л и. Болай кыргый булма, дустым. Хатынын түгел ич мин.

Б ө р к е т. Тукта, Гөлзифа кая?

Н э л л и. Керергә курка.

Б ө р к е т. Курка?!

Н э л л и. Курыкмаска, дөньяга беренче кат чыга кыз. Ә син Беркетсен икән, аңлый бел инде кызлар хәлен. Ул бит әле кулга өйрәнмәгән кыр кәҗәсе. Беләсеңме... Кыр кәҗәсе.

Б ө р к е т. Кыр кәҗәсе... Әйе, әйе, син хаклы, Нэлли. Кайда ул, урамда калдымы?

Н э л л и. Әйе...

Б ө р к е т. Хәзер алып керәм ул кыр кәҗәсен. *(Яшәргә кыюрак булырга кирәклек турында ымлый-ымлый чыгып китә.)*

Н э л л и *(Бөркеткә ишарәләп)*. Рыцарь! Үрнәк ал!

Я ш ә р. Минем бит кыр кәҗәм юк.

Н э л л и *(радиоланы җибәрә, ул бию көе уйный)*. Кәҗәң булмаса, сандугачың бар. Сандугач...

Я ш ә р. Сандугачтан бигрәк чәүкә ошый миңа.

Н э л л и. Чәүкә? Алай дисәң, дустым, миннән дә чәүкәрәк чәүкә юк Акшәһәрдә.

Я ш ә р *(көлеп)*. Чәүкәрәк чәүкә? Менә монысы шәп, черт возьми. *(Кинәт кочаклап ала да каты итеп үбә.)*

Н э л л и. Ярамый.

Я ш ә р. Ярый. *(Биеп китәләр.)*

Бөркет белән Г ө л з и ф а керә.

Б ө р к е т. Әйдә, тартынма.

Г ө л з и ф а *(ишек янына туктап)*. Нинди күңелле сездә.

Б ө р к е т. Ә син тартынып торасың.

Г ө л з и ф а. Шушы күңеллелеккә бар күңелем белән тартылып китүдән куркам.

Б ө р к е т. Синең тартыласың килмиме?..

Г ө л з и ф а *(Бөркетнең колагына гына)*. Килә.

Б ө р к е т. Соң? Кем тота?

Г ө л з и ф а. Вөжданым кушмый. Уңайсыз. Әгәр дә менә үз ихтыярымнан башка гына, ну бераз көчләбрәк димме, берәрсе өстерәп алып керсә, ул чагында, бәлки, намусым бик җыламас, вөжданым да тыныч булыр иде.

Б ө р к е т. Алайса, бу авыр бурычны миңа тапшыр, Гөлзифа, ярыймы.

Г ө л з и ф а. И, и... алай рөхсәт сорап торгач инде ул...

Б ө р к е т. Бетте, аңладым... *(Нэлли белән Яшәргә.)* Дуслар! Гөлзифаны котлагыз. Аның туган көне!

Н э л л и. Туган көне?

Б ө р к е т. Әйе. Кая әле... *(Рюмкаларга эчемлек салып.)* Әрмәнстан ширбәте. Бары тик берәр рюмка Гөлзифаның туган көне хөрмәтенә.

Н э л л и. Туган көнем дип ник әйтмәдең миңа.

Г ө л з и ф а. Ул әле ай ярымнан.

Н э л л и. Ә-ә... аңладым...

Б ө р к е т. Без аны бүгеннән үк каршы ала башлыйбыз. Ярыйдыр бит?..

Я ш ә р.<br>
Н э л л и. } Тәбрик итәбез, Гөлзифа.<br>
Б ө р к ет.

> Матурлыкта һич кайда юк тиңең,<br>
> Йөзең көләч, буй-сын бик зифа.<br>
> Дөньяга син шатлык алып килдең,<br>
> Мең ел яшә, гүзәл Гөлзифа.

Я әле!.. *(Эчәләр.)*

Гөлзифа *(чыраен сытып)*. Әбәү, ачы ич бу.

Бөркет. Кояш нуры. Ике рюмкадан күнелең нур белән, бәхет ялкыны белән тула. Барыр юллар өчен якты маяк бу. Һич алдашмыйча җәннәткә барып керергә була.

Яшәр. Ярый ла сират күперен кичкәндә, башың әйләнеп җәһәннәмгә егылып төшмәсәң...

Бөркет. Һей, егылырлык булгач инде ул, дустым, җәһәннәмең дә җәннәткә әверелә. *(Радиолага бию көе — «Шейк»не куя. Гөлзифага баш иеп.)* Прошу!

Гөлзифа. Пожалуйста. *(Биеп китәләр.)*

Бөркет. Әйдәгез, дуслар, калмагыз! Җәннәткә!

Гөлзифа. Бергә-бергә булганда, җәһәннәмдә дә миңа берни түгел. *(Кулларын бутап, төрле хәрәкәтләр ясап, күбрәк бер урында баскан килеш биилар.)*

Нэлли *(Бөркетнең колагына нидер әйтә дә Яшәр белән Гөлзифа янына килеп)*. Дусларым, сез дәвам итегез. Эш турында Бөркет белән минем бераз сүзем бар. *(Бөркет белән алга, просцениумга чыгалар һәм бии-бии сөйләшәләр.)*

Бөркет. Бәлки, иртәгә?..

Нэлли. Юк, бүген... *(Пауза.)* Миннән бөтенләй бездән син хәзер.

Бөркет. Урынсыз шелтә.

Нэлли. Сизәм ич мин. Сиңа хәзер минем мәхәббәтем берни тормый.

Бөркет. Нэлли сөеклем, син үзең миңа караганда Яшәрне якын күрәсең.

Нэлли. Борчылма, Бөркет. Яшәрне бу көннәрдә гел-гел миңа таба син этәрәсең. Мә ал янәсе, йот башы-аягы белән.

Бөркет. Нигә, егет ошамыймыни?

Нэлли. Бик тупас...

Бөркет. Зарар юк, чарланыр. Аның каравы менә дигән ир. Буй-сын нинди! Аргамакмыни! Атлан да чап кына.

Нэлли. Миңа аргамак кына түгел, гомер итәр кеше дә кирәк.

Бөркет. Алай дисәң инде бигрәк тә. Яшәр әйбәт кеше. Безнең егет. Өстәвенә комсомолец! Әнисе дә, әтисе дә башта комсомол чыныгуы алган кешеләр.

Нэлли. Ф-фи!..

Бөркет. Филәмә, сөеклем. Безнең чорда әле андыйларга һаман почет та хөрмәт. Картларына персональ пенсия, балаларына...

Нэлли. Йомран башы.

Бөркет. Киресенчә, майлы бутка, җайлы урын. Яшәр синең юлыңа келәм булып түшәләчәк. Ә син рәхәтләнеп таптап уз аны.

Нэлли. Ой, нинди шәфкатьле йөрәк синдә.

Бөркет. Шул шул. Ә икәүсенең дә йөрәкләре, характерлары бер булган ир белән хатын, бәхетле булып гомер итә алмый, ди. Фән әйтә. *(Яшәргә.)* О, Яшәр олрайт! *(Нэлли белән сүзне бетерергә теләп.)* Ганимәт бел, ычкындырма! Әйдә, шикләнмәсеннәр...

Яшәр белән Гөлзифа янына килеп биюгә кушылалар. Бөркет Гөлзифа белән бии.

Айсылу керә дә мондагы тамашага карап тора.

Бөркет *(Айсылуны күрә)*. Айсылу?

Бар да. Айсылу!.. *(Пауза.)*

Бөркет *(музыканы туктатып)*. Рәхим ит, Айсылу.

Айсылу. Комачауладым, ахрысы.

Бөркет. Юк... Килүеңә бик шат. Таныш булыгыз. *(Нэллине күрсәтә.)* Трестыбызның конструкторлар бүлегендә...

Нэлли. Консультант Нэлли Апанаева. *(Баш ия.)*

Бөркет *(Гөлзифаны күрсәтеп)*. Ә монысы...

Нэлли *(Гөлзифаны кочаклый)*. Минем дус кызым — Гөлзифа Миңнәхметова. *(Үзе үк баш ия.)*

Бөркет *(Яшәрне күрсәтә)*. Ә бу иптәш...

Айсылу. Яшәр Харрасов. *(Яшәргә.)* Ялгышмадым дип беләм.

Яшәр. Ялгышмадың.

Бөркет *(Айсылуны күрсәтеп)*. Ә бу минем кадерле кунагым Акшәһәрнең атаклы бригадиры — Айсылу.

Айсылу. Купертмәгез, Бөркет абый, атаклы сүзе артык. Гади ташчы кыз — Җәгъфәрова.

Нэлли. Айсылу Җәгъфәрова? О-у, болай булгач чын-чынлап атаклы. Безнең газета күтәрә сезне. Комсомол тәрбияләп үстергән яшь талант, дип бәя бирә.

Айсылу. Анысы күптәнге хәл. Ә бүген шәптән түгел безнең эш. Ә, Яшәр?

Яшәр. Мин нәрсә әйтим. Мин... Тукта, Сәрия Янбулатова ничек сон, китәргә булдымы? Кадрлар бүлеге нәрсә әйтте?

Айсылу. Алар җибәрәбез дигән иде дә, мин каршы төштем. *(Бөркет белән Яшәр мәгънәле итеп бер-берсенә карашалар.)* Парткомга бардык. Партком мине яклады. Сәрия китми хәзер.

Яшәр *(Бөркеткә)*. Күрдеңме безнең бригадирны... Ничек алып бара ул эшне.

Бөркет. Браво!.. Мактыйм, Айсылу! Принципиальлек, каты куллылык иң мактаулы сыйфатыбыз ул безнең.

Айсылу. Туктагыз әле, нәрсә булды сезгә? Бик күңелле генә ял итә идегез, ашкынып бии идегез, ә мин кергәч, җыелыш ясый башладыгыз. Юк, килешми бу...

Яшәр *(чәнчеп)*. Син соң бисеңмени безнең белән?

Айсылу. Нигә биемәскә? Аягым-кулым исән, йөрәгемдә ялкын житәрлек... Шулай булгач, әйләндерегез әле пластинканы.

Бөркет. Чынлап әйтәсезме? Шаярмыйсызмы?

Айсылу. Шаяртып сөйләргә яшем житмәгән әле минем, Бөркет абыкай. *(Жакетын салып куя да бии башлый. Ул бик оригиналь хәрәкәтләр ясап, бик оста бии.)*

Бөркет *(бию тукталгач)*. Браво! Менә бу номер, ичмасам. Я, Яшәр, инде синә чират. Бие, сынатма! *(Радиоланы җибәрә.)* Я, биемисеңме? Алайса үзем! *(Ярсып, ашкынып бик оста итеп бии. Урыны-урыны белән балет солистлары гына ясый алган хәрәкәтләр ясый. Биегән чагында Яшәргә кызларны алып кит дигән мәгънәдә ымлый. Музыка туктала. Бөркет тә туктый.)*

Айсылу. Отлично! *(Кул чаба.)*

Нэлли *(Бөркеткә)*. Замечательно! Браво! *(Айсылуга.)* Сез дә искиткеч биедегез, сөеклем. Чудесно! Көнләшәм сездән.

Айсылу. Һич урынсызга лакин. *(Жакетын кия.)*

Яшәр *(Нэллине бер читкә алып, әкрен)*. Нэлли, беләсеңме мин... *(Колагына нидер әйтә. Нэлли аңа гаҗәпләнеп карый.)* Үтенәм...

Нэлли *(пышылдап кына Гөлзифа белән сөйләшә, Яшәргә)*. Барабыз! *(Бөркеткә.)* Мәҗлес күңелле иде, бик күңелле... ләкин, зинһар, гафу итегез, Яшәр белән без сезне калдырып китәргә булдык.

Бөркет. Безне калдырып?! Юк, ышанмыйм. Ничек инде бу...

Нэлли. Ә син ышан, кадерлем...

Бөркет. Мин сезне кунак итәргә дә өлгермәдем ич...

Нэлли. Кунак булу өчен икенче килербез, ә Яшәр? Гөлзифа?

Яшәр. Бүгенгә гафу үтенәбез. Хушыгыз.

Нэлли. Әйдә, Гуленька! *(Яшәргә подручка алырга тәкъдим итеп.)* Алыгыз, сөекле кавалерым. *(Бөркет белән Айсылуга кул изәп.)* Гутбай! *(Китәләр.)*

Бөркет *(озата барып)*. Хушыгыз!
Айсылу *(аптырап)*. Нәрсә булды инде бу?
Бөркет. Һич нәрсә аңламадым. Мөгаен, Нэллинең капризыдыр.
Айсылу. Әллә Яшәрнекеме?
Бөркет. Белмим...
Айсылу *(ялгыз калудан уңайсызланып)*. Мин сезгә Гомәр Хәййам шигырьләре өчен дип килдем.
Бөркет. Беләм. Мин сине көттем, Айсылу... Хәзер... *(Этажеркә янына килә. Озак кына эзли.)* Башта, бәлки, берәр стакан чәй эчәрбез?
Айсылу *(кискен)*. Юк, рәхмәт.
Бөркет. Өйгә килеп тә бер чинаяк чәй эчми киту... Халкыбызның гореф-гадәтенә хилаф.
Айсылу. Шулай да эчмим.
Бөркет. Менә ул китап. Әйттем ич, бераз таушалган, ә эчендә тылсымлы сүзләр. Менә тыңлагыз әле.
Айсылу. Укымагыз. Китапны гына бирегез.
Бөркет. Рәхим ит... *(Китапны суза, үзе күзләре белән Айсылуга текәлә.)* Айсылу!
Айсылу. Рәхмәт... *(Бөркеткә карый һәм гипноз астында сихерләнгән кешедәй катып кала.)* Бөркет.
Бөркет. Айсылу! *(Кулыннан тота.)*
Айсылу. Бөркет...
Бөркет. Син... син... *(Айсылуны үзенә тарта.)*
Айсылу. Юк! *(Бөркетнең кулыннан ычкынып ишеккә йөгерә.)*
Бөркет. Тукта!.. Бер генә минутка, китмә! Гафу ит, куркыттым, ахры.
Айсылу *(тынычлана төшеп)*. Юк.
Бөркет *(ярсулы һәм җитди)*. Ах! *(Ягымлы елмаеп.)*

Буй сыннарың синең чинар агач,
Биткәйләрең ялкын, таң кызы,
Килеп кермәс борын китәр булгач,
Ник килдең соң монда, ай кызы.
Ник елмайдың назлап йөрәгемне
Салыр булгач хәсрәт утына?
Ник яктырттың барыр юлларымны,
Атар булгач төпсез упкынга.

Айсылу. Кем шигыре бу?
Бөркет. Анысы әһәмиятсез.
Айсылу. Шулай да?
Бөркет. Гомәр Хәййам шәкерте Борһан Байсаровныкы.
Айсылу. Борһан Байсаров? Әйбәт... *(Елмаеп.)* Шигыреңә каршы миңа да бер шигырь укырга кирәк иде дә, тик берни дә хәтеремә килми. Ә менә... *(Бераз назлап һәм шаяртып, күтәренке тон белән укый.)*

Һай, читен соң сиңа атап шигырь сөйләү,
Чөнки без ич бер үк кеше нәрсә дим!
Мин син икән, шәпме үзеңне җырда мактау?
Син мин икән, ничек үземне күккә чөйим.
Шуңа күрә аерылышыйк. Аерым чакта
Гыйшкыбыз «уртак» дигән исемен җуйсын,
Булыр ул чак җырым фәкать синең хакта.
Лаек моңар синең йөрәк, синең буй-сын.
Аерылышу! Зур сынау ул, авыр хәсрәт.
Көчең җитми төнне көнгә ялгар өчен.
Шуңа да ул бирә җанга тирән ләззәт.
Вакыт белән хисне генә алдар өчен
Аерылышу берне һәрчак икегә бүлә,
Ерак дусны мактау җиңел шуңа күрә [1].

*(Пауза.)*

[1] Шәрәф Мөдәррис тәрҗемәсе.

Бөркет. Айсылу!
Айсылу (*дәвам итеп*).

Ләкин дусмы, дошманмы син, анысын мең...
Хакмы икәнен тик бер шайтан үзе белә.

Бөркет. Ничек, ничек?
Айсылу. Тик бер шайтан үзе белә.
Бөркет. Кем шигыре бу?
Айсылу. Анысы әһәмиятсез.
Бөркет. Шулай да?
Айсылу. Вильям Шекспир шәкерте Айсылу Җәгъфәрованыкы... дияр идем дә, үз иҗатым белән даһиның рухын рәнҗетү булыр дип, остазымның Сонетын укыдым. Бары тик соңгы ике юлы гына үземнеке.
Бөркет. Ах, соңгы ике юлы... Әйтәм аны... Ха-ха-ха.
Айсылу. Нигә көләсез?
Бөркет. Соңгы ике юлы Сонет калыбына сыймый, дим.
Айсылу. Аның каравы мәгънәсе шәп. (*Басымнар белән кабатлап.*)

Ләкин дусмы, дошманы син, анысын мена,
Хакмы икәнен тик бер шайтан үзе белә.

Бөркет. Син инде аны шайтанга калдырма, Айсылу, үзең бел.
Айсылу. Кеше күңеле — төпсез күл. Ничек белеп бетерәсең, ди аны.
Бөркет. Айсылу! Әйдәгез, киләсе ялга, машина белән кая да булса барып киләбез. Болынгамы анда, урмангамы берәр...
Айсылу. Юк.
Бөркет. Урман димәсәгез, көймәдә йөрергә төшәбез, Камага, ә? Күңелле анда, халык, яшьләр...
Айсылу. Белмим...
Бөркет. Көндез сәгать өчләрдә, ә?
Айсылу. Вакыт таба алсам...
Бөркет. Табыгыз, Айсылу!
Айсылу. Ярый! Бәлки төшәрбез дә.
Бөркет. Бәлки түгел, ныклы вәгъдә булсын. Көтәм.
Айсылу. Көтегез! Хуш! (*Кызу гына китә.*)
Бөркет (*тәрәзәгә килеп*). Ычкынды. Ух, ут та соң каһәрең. (*Көйләп.*)

Кемгә сөйлим серләремне,
Йөрәгем ялкын кебек,
Ялкынланган йөрәгемә
Берәү бик якын кебек...

(*Пауза.*) Айсылу дип Нэлли белән Гөлзифаны да озатып җибәрдем. Менә утыр инде хәзер ялгыз башың, сөмерәеп. Төнге ябалак сыман...

Кулындагы гитарасын атып бәрә.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КАРТИНА

Барак алды. Тәбәнәк рәшәткә белән тотылган бакча-палисадник. Сирень, сәрби агачлары. Агач төбендә эскәмия. Агачлар аша барак ишеге һәм бер тәрәзә күренә. Якшәмбе көн. Еракта Акшәһәр силуэты күренә. Барак ишегеннән киенеп-ясанып Айсылу чыга. Кулында ефәк косынка.

Айсылу (*иркен сулап*). Әй көне!.. Кояшы нинди көлә. Әй, кояш! Ал мине үз яныңа! Бөркетләр бит югарыда, зәңгәр күктә оча. И, җүләр кыз... Кая ашкынасың шулкадәр! (*Сәгатенә карый.*)

Жилкәсенә аккордеон аскан **Яшәр** һәм аның белән бергә **Нэлли** керә. Яшәр пөхтә генә итеп киенгән, яхшылап кырынган.

Нэлли. О-у, Айсылу? Исәнме, Айсылу!.. Бәйрәм белән, сөеклем.

Айсылу. Бәйрәм?! Ә-ә, дөрес, дөрес! Ял көне, кояшлы ямьле көн...

Нэлли. Бик, бик ямьле! Юлда очраштык та озата килдем. *(Яшәргә күз кысып куя.)* Егете күркәм, мин әйтәм, күңелсез булмасын аңа дим.

Айсылу. Тагын килегез... Өебез тәбәнәк булса да, күңелебез түгәрәк безнең.

Нэлли. Рәхмәт, сөеклем... Тик башта әле үзең безгә кил... Тантана мәҗлесенә...

Айсылу. Нинди тантана ул?

Нэлли. Анысы сюрприз, сөеклем. Килгәч күрерсең. Димәк, сөйләштек, киләсең? Шәһәрдә, тугызынчы квартал, 12 йорт.

Айсылу. Ихтимал, килермен дә...

Нэлли *(шат)*. Кил сөеклем, кил. Бик күңелле бездә. Ә тантана көнне аеруча күңелле булыр. *(Яшәргә, акрын.)* Кара аны, төгәл ике сәгать вакыт сиңа.

Яшәр. Бәлки әле иртәрәк тә котылырмын.

Нэлли. Көтәм. Хәзергә хуш, кадерлем. *(Айсылуга кул изәп.)* Гутбай, сөеклем! *(Китә.)*

Айсылу. Гутбай...

Яшәр. Ох, шундый кайнар йөрәкле кыз ул...

Айсылу. Кайнар?

Яшәр. У-у-у *(кулы белән ниндидер кызыклы хәрәкәтләр, ымлар ясый.)* Гиго милли-майн!..

Айсылу. Нәрсә?

Яшәр *(тагын хәрәкәтләр ясый)*. Миа-Хандру Сима! Аңламыйсың?

Айсылу. Юк. *(Башын селки.)*

Яшәр. Хандраш чуль-чуль. Марсиannар теле бу.

Айсылу. Җүләр сатма, Яшәр.

Яшәр. Космос чорында яшибез. Маг-гайне лэйтен унд ди кәлбина.

Айсылу. Ах, лейтун кәлбинамени? Ха-ха-ха! Аңладым. Алайса шул — ду бист гыйфрите чиллаги пиш-пиш, кәлбен кәлбөра! *(Кулларын белән кызу-кызу хәрәкәтләр ясый.)* Вә идиотын илла төшкәри җаһилен, олрайт критин, колләһу фәллах!

Яшәр. Монысы нәрсә тагын?

Айсылу. Күктән төштем дисең ич, марсианнар телен белүең белән мактанасың? Ә сатурнлыларның иң популяр телләрен дә аңламыйсың.

Яшәр. Сатурн? Ха-ха-ха! Ну каһәр кыз да син, Айсылу. Я, я, ул сатурнлылар телен тәрҗемә итсәк ничек була инде?

Айсылу. Ничек булсын, Сатурн халкы ерак күктән, үзенең алтын бөҗрасы аша карап көлә синнән. Юлда адашкан Мәҗнүн, ди. Сезнең ул Марстан төшкән егетегез — Яшәр бине Хәррас үз акылында түгел, ди.

Яшәр. Ә шулаймыни. Мәҗнүнме? Үз акылында түгелме. Ха-ха-ха. Менә нәрсә, сеңелкәем Ай кызы! Тегермән кормасыннар синең ул сатурнлыларың. Ачуым килсә, мин аларның бөҗраларын өзеп ташларга да күп алмам. Мин аларга: кию-майн минәл Марси Инкәсәрүн ләм яльтәфит! Җир телендә әйтсәк — үзебезнең Марстан торып төкерәм мин аларның сүзенә.., Ни сүзләре, ни үзләре миңа, белдеңме? Ә дөресен генә беләселәре килсә, шул: монысы сиңа да кагыла, иптәш Айсылу. Бүген мин как раз үз акылымда, әйе, нәкъ үз акылым, үз намусым, үз вөҗданым, үз көнем...

Айсылу. Үз көнең?.. Әниең... Рәзиләң...

Яшәр. Ишетәсем дә килми!



Яшәр (Р. Тажетдинов) һәм Айсылу (Н. Ихсанова).

Айсылу. Алар турында ишетәсең килми, эшенә төкереп карыйсың. Институтка керәм дип әзерлек алып бара идең, ташладың...

Яшәр. Укымыйча да менә дигән итеп яшәп була.

Айсылу. Элек болай сөйләми идең син.

Яшәр. Элек, сезнең акыл белән яшәгән чагымда, әллә нәрсәләр сөйләгәнмендер. Ә хәзер, үз акылым. Бик айнык ул.

Айсылу. Айнык микән...

Яшәр. Айнык. Эчмәдем. Моннан соң эчмәячәкмен дә. Ә әз-мәз, күңел күтәрер өчен генә булса... Чурр!.. Аисын инде өлкән агайлар да эчә. Вот шулай. Ташладым эчүне. Аллаһе тәгалә шәрап касәмне ватты. Ачуым килгәч әйттем аңа: әбрико мәййо мәра шикасти, рабби...

Айсылу. Бу да марсианнар телеме?

Яшәр. Әйе. Үзебезчә болай:

> Шәраб касәмне ваттың нигә, раббем?
> Бәхет ишегемне яптың нигә, раббем?
> Ләгънәт кенә төшсен сиңа, раббем!..

Да, да! Мин инде хәзер элекке сарык бәрәне түгел... Мио-кито-май!.. Олрайт! *(Өйгә кереп китә.)*

Айсылу *(Яшәрне күзәтеп калып)*. Кызык. Каян килгән аңа болар. *(Сәгатенә карый.)* Вакыт. Ни өчен әле мин ул чакыргач та риза булдым. Аның әллә ни уйлавы бар.

Бәйрәмчә киенгән Акбүләк керә.

Акбүләк. Сәлам, Айсылу. Каядыр җыенасың, ахры!

Айсылу. Свиданиегә дигән идем дә... Соңга калдым кебек.

Акбүләк. Соң дип... Бәлки әле соң да түгелдер.

Айсылу. Аннан килгән кунакны ташлап китү дә килешми.

Акбүләк. Мин сине алырга килдем, Айсылу.

Айсылу. Кая?

Акбүләк. Көймәдә йөрергә. Камага.

Айсылу. Кама? Юк, Акбүләк абый, бармыйм анда. *(Көлә.)*

Акбүләк. Нигә?

Айсылу. Свиданиегә мине бит шунда көтәләр. Кама буенда

Акбүләк. Бөркетме?
Айсылу. Әйе — ул.

Пауза. Акбүләкнең җиргә сызыклар сызып уйный торган чыбыгы сына.

Чыбык сынарлык берни дә юк, Акбүләк абый.
Акбүләк. Иртәгә, бәлки, бүрәнә сынса да соң булыр.
Айсылу. Иртәгәсе өчен беркем дә, берни дә алдан әйтә алмый.
Акбүләк (*көлеп*). Күрәзәче әйтә ала.
Айсылу. Ярый әле күрәзәче булмаганмын. Үз хисләреңнең нинди ерганаклар буйлап, ничек агарына кадәр алдан белеп торсаң, дөньяда яшәүнең бер кызыгы да булмас иде.
Акбүләк. Юк, Айсылу, әгәр хисләрен кеше үзе теләгән ерганаклар буйлатып, үз ихтыяры белән борып җибәрә алса, шуңа көче житсә иде, яшәү аңа кызыграк та, мәгънәлерәк тә булыр иде.
Айсылу. Димәк, үз хисләрең белән идарә итәргә? Баш министр дәүләт белән идарә иткән сыман? Кайгың... шатлыгың... нәфрәтең, дуслыгың-мәхәббәтең... Ой, бик четрекле бу.
Акбүләк. Шуңа да үзең белән идарә итү күп катлаулырак, минемчә.
Айсылу. Шулай булмыйча... Үз ихтыяр көчең диген дә җылыйсы урында көлеп, берәүне бик яратсаң да яратмыйча кара әле син.
Акбүләк. Кемне, мәсәлән?
Айсылу. Әй, хәйләкәр син, Акбүләк абый... Бөтен эч серләремне белеп алыр идең бугай.
Акбүләк. Белсәм соң?
Айсылу. Барын дамы?
Акбүләк. Әйе.
Айсылу. У-у... Чәчең үрә торыр иде. Мин әле кайчакта үземнән үзем дә куркам. Әйбәт кенә, акыллы гына булырга кирәк, ә минем уйлар, тойгылар шундый котырына, ярсый, ашкына. Нәкъ инде давылда диңгез дулкыннары диярсең. Син шулар белән идарә итәргә дисең.
Акбүләк. Әйе... Дулкыннар безне йомычка урынына чөймәсен. Без дулкыннарга түгел, дулкыннар безгә буйсынсын!
Айсылу. Юк, көч житмидер моңа, Акбүләк абый.
Акбүләк. Җитәргә тиеш.
Айсылу. Минем җитми. Җитми... Беләм ич үземне.
Акбүләк. Әйтимме сиңа бер сүз?
Айсылу. Өчне әйт.
Акбүләк. Син... син шундый кыз, Айсылу... үзеңдәге көчне үзең белмисең. Алла син!
Айсылу. Алла? Ха-ха-ха... Димәк, мин юк?
Акбүләк. Киресенчә, син бар, син бер, кодрәтең зур, тиңдәшең юк...
Айсылу. Акбүләк абый, житте. Ачуымны китерәсең! Җеннәр дә аңламас сүз сөйли башладың. Лутче уйнап җибәр. (*Аккордеон бирә.*)
Акбүләк (*аккордеонны күреп*). Ба!.. Нәкъ минеке сыман... Чү! Таныш ич бу миңа. Нишләп монда бу? (*Аккордеонны ала, телләрен тикшереп.*) Тамагы карлыккан дип әйтимме.
Айсылу. Булыр да. Төн буе гулять итеп кайтты. Кемнәрнедер җырлатып, биетеп...
Акбүләк (*әйләндерә-әйләндерә карый*). Димәк, төзәтүгә, ремонтка мохтаҗ.
Айсылу. Бик мохтаҗ... Тик сөйләп кенә калмыйча, чын-чынлап төзәтергә иде.
Акбүләк (*карап*). Бәлки, житди операция кирәк булыр?

Айсылу. Операциясез генә төзәтеп булмый икән... Ясарга! Үзе өчен дә яхшы, ансамбль өчен дә. Бармакларың төзәлгән, уйна әле, ичмасам, Акбүләк абый.

Акбүләк. Бармаклар төзәлде дә...

Айсылу. Уйна!.. Уйна!..

Акбүләк бармакларын житез йөгертеп «Сандугач» көен уйный.

Айсылу *(нык әсәрләнеп)*. Матур... Сандугач кебек сайрап тора. *(Пауза.)* Тагын берәр көй.

Акбүләк. Тагымы? *(Уйланып, икеләнеп тора.)*

Айсылу. Уйна, уйна! Йөрәгемнең ярсуы бөтенләй басылсын әле, ичмасам.

Акбүләк. Юк, булмый... Хәер, тыңла... Сиңа бу, Айсылу. *(Уйный һәм әкрен генә җырлый.)*

Карурманның былбыл кошы син,
Зәңгәр күкнең тулган ае син,
Гөлбакчаның матур гөле син,
Акшәһәрнең яме, даны син...

Айсылу. Даны? Кем ул Акшәһәр даны?

Акбүләк. Син ул, Айсылу. Алдагы юлларда әйтелә анысы.

Айсылу. Юк!.. Бернинди алдагы юл кирәкми, Акбүләк абый. Миннән көлү өчен бу кадәресе дә бик житкән.

Акбүләк. Айсылу?!

Айсылу. Акшәһәр даны, имеш. Бригада таркала. Берсе прогул ясый, читтә кунып йөри, икенчесе шәһәрдән качарга жыена... Мин үземне кая куярга белмим. Ә син... Шәһәрнең яме, дисең. Беләсеңме кичә горком секретаре Сафин нәрсә әйтте? Болай булса, Айсылу, арбадан төшеп каласыз, ди. Сизеп торам, тагын атна-ун көн шулай барсак... Хурлык, хурлык бит бу! Ә син...

Акбүләк. Мин якын күргәннән генә, Айсылу... Чын күңелдән яратып сине...

Айсылу. Кирәкми! Якын да күрмә, яратма да, бар...

Акбүләк. Айсылу!

Айсылу. Бар, Акбүләк абый.

Акбүләк. Бу нәрсә инде, кит дигән сүзме?

Айсылу. Әйе, кит! Кит!

Акбүләк *(аптырап басып тора да)*. Ярый алайса, хуш!

Айсылу. Хуш.

Акбүләк китә. Пауза. Айсылу механик рәвештә эскәмиягә утырып уйга чума. Бөркет керә.

Бөркет *(Айсылуны күреп)*. Айсылу! *(Айсылу эндәшми.)* Авырыйсыңмы әллә?

Айсылу *(башын да күтәрмичә)*. Авырыйм.

Бөркет. Ни булды, Айсылу, кай жирең?

Айсылу. Бөтен жирем дә авырта минем бүген.

Бөркет. Температураң да бармы?

Айсылу. Температура? *(Аңына килеп.)* Нинди температура? *(Бөркеткә игътибар итеп шатланып.)* Бөркет? Бу син...

Бөркет. Көттем көттем дә син килмәгәч, үзем килдем.

Айсылу. Гафу ит, Бөркет, бара алмадым.

Бөркет. Авыргач инде, билгеле...

Айсылу. Юк, мин авырмыйм.

Бөркет. Авырмыйсың? Әле генә авырыйм, дидең...

Айсылу. Ә-ә-ә, әйе...
Бөркет. Синең вәгъдәңә шундый ышанган идем...
Айсылу. Ни өчен?
Бөркет. Сәер генә сорау. Ничек сиңа ышанмаска мөмкин.
Айсылу. Нигә, кешеләрнең күбрәк күңелендә бер, телендә бөтенләй икенче нәрсә була ич.
Бөркет. Аңламыйм, кемгә ишарә бу?
Айсылу. Сиңа түгел, үземә карата әйтәм.
Бөркет. Үзеңне кимсетергә дә хакың юк.
Айсылу. Дөресен генә әйт әле, Бөркет, мин килмәгәнгә ачуланмадыңмы?
Бөркет. Юк... *(Пауза.)* Ышанмыйсың?
Айсылу. Ышанырга бик теләр идем дә...
Бөркет. Ышан, Айсылу. Гомеремдә бер тапкыр гына да ялган сөйләгәнем юк. Туры сүзле булырга, уемда ни булса, бары шуны гына сөйләргә бала чагымнан ук әнием өйрәтте. Әтием дә, әлбәттә, Куйбышевта алар. Әтием номерлы заводның директоры — инженер, әнием университетта әдәбият укыта, доцент.
Айсылу. Доцент?
Бөркет. Аларның тормышлары яхшы, иркен, тик мин генә монда килеп адаштым.
Айсылу. Адаштыгыз?
Бөркет. Ялгызлык үтерә, Айсылу. Таныш-белешләрем күп... Сөйләшеп, җырлашып утырыр өчен. Ә менә йөрәк дустым юк... Юк, Айсылу. Әлегә кадәр күңелемә ошаган бер генә кыз да очрамады... Менә беренче тапкыр син очрадың. Күңелем шатлыгыннан күкләргә күтәрелде. Беренче күрүдә үк йөрәгемә өмет ялкыны кабынды. Эх, Айсылу... Аңласа идең син... Кил әле, утыр, тыңла мине.
Айсылу. Утырам да, тыңлыйм да. *(Утыра.)* Тик...
Бөркет *(аның янына утыра)*. Чап яңагыма! Битемә төкер.
Айсылу. Шаштыгыз? Ни өчен?
Бөркет. Сиңа коточкыч сүз әйтәм хәзер.
Айсылу. Әйтмәгез!
Бөркет. Юк, әйтәм. Сугыгыз!
Айсылу. Мин куркырлык сүз әйтүегез мөмкин түгел.
Бөркет. Алай булса, ишет... *(Айсылуга текәлеп карый.)* Мин гашыйк сиңа, Айсылу.
Айсылу. Бөркет!..
Бөркет. Гашыйк!! *(Күзләренә карый.)* Айсылу. *(Кочаклый.)*
Айсылу *(ачу белән)*. Җибәр! *(Сикереп тора да чыгып китә.)*
Бөркет. Ух усал! Тиз генә баш бирәсе түгел... Ә шулай да... дөнья матур, якты...
Яшәр *(кереп)*. Бөркет?! Биек күктән ничек әле болай җиргә төшәсе иттең?
Бөркет. Ошый миңа сезнең барак, матур палисадникгы, тирәкләре...
Яшәр. Тирәкләреннән бигрәк асыл кошы.
Бөркет. Нигә, асыл кош булса гаепмени?
Яшәр. Юк, дус өчен бишәве дә җәл түгел.

Көлешә-көлешә Мәгъсүм белән Сәрия чыга.

Мәгъсүм *(ишек янында)*. Кара, бу теге Миңсрур апаны китергән зирәк егет түгелме? Исеме кем әле... Тилгәнме шунда, карчыгамы?
Сәрия. Белмим... Мин ул көнне рәтләп игътибар да итмәдем.
Мәгъсүм. Шул үзе. Әйдә янннарыннан узабыз, сәлам биреп.

Сәрия. Кирәкми, бу яктан гына китик.

Мәгъсүм. Әй, килешмәгәнне. Әйдә юлдан китәбез. *(Сәрияне култыклап алып китә.)* Хәерле көн.

Бөркет. Хәерле көн... Дус.

Мәгъсүм. Үзегез хәтердә... Укыган шигырегез дә колак төбендә янгырап тора. Валлаһи менә. Ә исемегез хәтердән чыккан. Ни то лачын, ни то карчыга?

Бөркет *(көлеп)*. Бөркет.

Мәгъсүм *(Сәриягә)*. Шул, шул, Бөркет. Әйтәм бит... Шундыйрак булып хәтердә торып калган. Мин — Мәгъсүм булам, танышыйк. Бу — Сәрия Янбулатова.

Бөркет *(баш иеп)*. Якыннан танышуыбызга бик шат.

Мәгъсүм. Мин дә шат. Сәрия дә шулайдыр дип беләм.

Сәрия. Әйе, шулай. *(Баш ия.)*

Мәгъсүм. Әйтәм ич. Ярый, хушыгыз. Безнең эле Кама буена барышыбыз. Ял көне, мин әйтәм, әйдә, Сәрия, көймәдә йөреп кайтыйк, дим. Әмма ләкин ишкәклесендә, мин әйтәм. Моторны яратмыйм. Тыртыр да тыр-тыр. Гавыштан болай да туйган. Ә ишкәк тыныч. Чульт, чульт. Чульт, чульт!.. Ике-өч тапкыр каерып алсам, Кама уртасында, тагын каерсам — аргы якта. Баш чутына ул кадәр үк булмаса да, беләгемнең авторитеты, аллага шөкер.

Бөркет. Сизелеп тора.

Мәгъсүм *(үзеннән бик канәгать)*. Ха-ха-ха! Сизелә дисең, э. Ярый, ярый! Сизелүе яхшы. Югыйсә... кайбер абзыйлар фәлән дә төгән диләр дә бик исәпләшми дә башлыйлар. Әйдә, Сәрия!.. *(Башындагы салам эшләпәсен алып.)* Хушыгыз! *(Китәләр.)*

Бөркет. Хуш, дустым, хуш! Күнелле егет.

Яшәр. Сәрияне кара син? Ничек тота үзен. Әйтерсең, күргәне дә, белгәне дә юк.

Бөркет. Бик акыллы тота, молодец! Хөрмәт аңа! Бик чибәр кыз. Менә кемне ярат син, Яшәр дус.

Яшәр. Юк, рәхмәт! Нәллидән дә бик канәгать.

Бөркет. Канәгать дисең алайса...

Яшәр. Канәгать... Бүген аның янына күчеп барырга ук булган идем дә...

Бөркет. Соң?

Яшәр. Рәзилә әнә җибәрмим, ди.

Бөркет. Рәзилә? Ха-ха-ха! Син үз акылыңдамы соң? Хатыныңнан рөхсәт сорап, кайда, кемнең аерылышканы бар?

Яшәр. Юктыр да соң... Үтерә язганчы кыйнап, балам белән икебезне ташлап китте, дип комсомол комитетына язып бирәм, ди.

Бөркет. Бирсен, нигә ана исең китте. Заманында мин дә комсомолец идем. Яшим бит әле.

Яшәр. Алай гына түгел шул, судка да бирәм, ди.

Бөркет. Судтан да курыкма. Бердән, вакыт узган, икенчедән, шаһитләре... шаһитләре бармы?

Яшәр. Кемнәр диген әле, берсе минем әни, икенчесе Айсылу, өченчесе — Сәрия...

Бөркет. Менә монысы инде — житдирәк... Ну шулай да кайгырма, дус. Барын да син теләгәнчә ерып чыгабыз. Берәр юлын табарбыз әле.

Яшәр. Юлын табулары кыенрак шул. *(Пауза.)* Әйдә әле, Бөркет дус, сиңа барыйк булмаса. Пәрәк ярсый.

Бөркет. О, юк, зинһар, гафу ит, дустым, бүген булмый. Ә өч көннән соң, рәхим ит. Ишегем һәрвакыттагыча ачык сиңа. Хәзергә хуш. *(Китә.)*

Я ш ә р *(аккордеон алып).* Я, сердәш! Нишлибез хәзер? Шәп түгел бит безнең хәл. Нәрсә? Җырлавың да, көлүең дә, бары миннән генә? Ярый, синеке шулай, ә минеке, минеке кемнән? Белмисең. Шул шул. Үз хәлемне үзем дә белмим. *(Тын гына утыра.)*

Урам ягыннан, таякка таянып, М иң с р у р апа кайта. Я ш ә р н е күреп сискәнеп китә, турая. Әкрен генә янына килә.

М и ң с р у р *(Яшәр янына ук утырып, аның башыннан сыйпый).* Әй, улым, улым... Төн буе сине эзләп йөрдем.

Я ш ә р *(әнисенең кулын этәреп җибәрә дә читкәрәк елышып утыра).* Бала түгел лә инде мин.

М и ң с р у р. Юк, улым, йөземә күтәрелеп карарга теләмәсәң дә, барыбер бала син минем өчен. Ә мин — ана сиңа.

Я ш ә р. Боларны кычкырмыйча гына да әйтеп була бит.

М и ң с р у р. Боларны бер сүз әйтмичә дә аңларга тиеш идең син...

Я ш ә р. Бик аңлыйм.

М и ң с р у р. Юк шул, аңламыйсың. Күрәм, бик күп нәрсәләрне аңламыйсың син, улым.

Я ш ә р. Сезнең кебек караны да ал-гөл итеп күрергәме?

М и ң с р у р. Юк, түгел!.. Син тынла әлек, аңла.

Я ш ә р. Кирәкми, сөйләмә. Тыңламыйм да, аңламыйм да! Аңлаган кадәресе дә бик җиткән. Кеше кеше өчен туган, имеш, дус, иптәш... Саф вөҗдан, гаделлек, һәркемгә тигез хокук. Бар да алар кәгазьдә генә, ә тормышта...

М и ң с р у р. Безнең тормышны син, улым, үзең бүген яшәгән бүлмәң киңлегенә карап кына үлчәмә. Бөтен җитәкче коммунистларны да бүген сиңа квартир бирмәгән, беренче чиратта үзләрен генә тәэмин иткән хуҗаларың белән тиңләмә. Кешелекле, гадел җитәкчеләр әз түгел бездә.

Р ә з и л ә аксый-аксый чыгып, сүзсез генә Миңсрур янына килеп баса.

М и ң с р у р. Әгәр моннан соң да Рәзиләне шулай мәсхәрәли, җәберли торган булсаң, кара аны, улым, хөкемем каты булачак... *(Пауза.)* Хәзер инде синнән үземә берни дә өмет итмим. *(Пауза.)* Ә минем иптәшләреңә карата начар булсаң, я эшеңә бармыйча дуамалланып йөрсәң, ул чагында миннән рәхим көтмә! *(Аягүрә баса.)* Бу минем хөкемем генә түгел, мәрхүм атаңның да, сугышта һәлак булган абыйларының да хөкеме булыр.

Я ш ә р *(Рәзиләгә).* Синең нинди хөкемең бар?

Р ә з и л ә. Әнкәй хөкеме минем дә хөкемем.

Я ш ә р. Мине өзгәләргә сүз берләшеп куйганыгызны яхшы беләм. Инде минем хөкемемне ишетегез: туйдым! Барыгызның да куркытуыннан туйдым. Сезнең сүзләрне тыңлап кына да акылдан шашарга мөмкин. Ярый, моннан соң күзегезгә күренмәскә тырышырмын. *(Аккордеонын ала.)*

М и ң с р у р. Киртәгә сикермә, улым.

Я ш ә р. Суд белән куркытып кайтарабыз дип уйламагыз да! Курыкмыйм! *(Китә.)*

М и ң с р у р. Тукта! Тукта дим, бала! *(Артыннан китә...)*

Р ә з и л ә *(урынында басып калган килеш).* Китте...

А й с ы л у *(кереп).* Рәзилә!

Р ә з и л ә. Айсылу җаным! *(Кочаклап үкси.)*

Әкрен генә атлап М и ң с р у р апа керә.

М и ң с р у р. Артына да борылып карамады, ичмасам. *(Рәзиләне юатырга теләп, иңсәсеннән сөя, кочаклый.)* Сабыр ит, кызым.

Өчесе дә тын гына басып торалар.

Айсылу. Әйдә, Минсрур эпа, өйгә... Әйдә, Рәзилә. *(Житәкләшеп ишеккә киләләр. Миңсрур белән Рәзиләне өйгә кертеп җибәрә дә озак кына уйланып утыра, күккә карый.)* Кояш та батты... Нишләргә соң? Кемгә генә барып... Әйе, әйе, аңа!.. Ул акыллы.:: Ул:..:

Йөгереп китә. Ут сүнә.



## ДҮРТЕНЧЕ КАРТИНА

Акбүләк бүлмәсе. Яңа стиль белән җиһазланган зур гынә бүлмә. Өстәл, урындыклар һәм башка җиһазлар. Алгы планда тәбәнәк өстәл, җиңелчә ике кресло. Шунда ук торшер. Стенада зурайтылган ир белән хатын рәсеме. Ир — озын мәһабәт гәүдәле, калын мыеклы матур кеше, аның янында кечерәк буйлы, мөлаем табигатьле, иргә караганда күп карт күренә торган тыйнак бер хатын. Болар — Акбүләкнең әтисе һәм әнисе.

Ут алына. Сәхнәдә беркем дә юк. Тик тормыш юлларының сикәлтәле булуын, кешеләрнең төрле каршылыкларга очрап, еш кына авыр хәлдә калулары турында сөйләп, дулкынландыргыч музыка яңгырый. Акбүләк кайтып керә. Ул бик күңелсез. Өстендәге пиджагын салып ыргыта да арлы-бирле йөри башлый. Стенадагы рәсем каршында туктала.

Акбүләк. Менә шулай, кадерлеләрем, уңмады юлым. Нишләргә хәзер? Пиджакны? Юк, пиджакның гаебе юк... Хәзер!.. *(Пиджагын алып элеп куя.)* Институтны да отличнога диярлек тәмамладым. Эшем дә ярыйсы бара. Шәһәр салам. Яңа йортлар... Ә менә аның күңеленә ачкыч таба белмим. *(Рәсемгә карап.)* Их, әнкәй, килсәң якын киңәшчем булыр идең дә бит... *(Пауза.)* Ә йөрәк ашкына! *(Гармунын алып, ярсып уйный башлый. Ул импровизация ясап уйный һәм бер кат уйнап чыккач, үзе үк кушылып җырлый.)*

Дулкыннар!
Шаулыйлар дулкыннар,
Ургылып, ярсынып, ашкынып...
Туктаусыз чабалар дулкыннар,
Каядыр ашыгып, ашыгып.

Тукта, шәп көй бит бу. *(Уйный.)*

Туктаусыз чабалар дулкыннар,
Каядыр ашыгып, ашыгып.

Агыла дулкыннар, дулкыннар,
Агыла айкатып диңгезне.
Ыргыла күкләргә дулкыннар,
Әйтерсең, язмышлар бер безнең.

Иссен җил, дуласын дулкыннар,
Яшьнәсен күкләрдә яшеннәр.
Безгә ул тагын да күңелле.
Үзебез яшеннәр без яшьләр.

Мәгъсүм *(арттан ишек шакып)*. Мөмкинме?
Акбүләк. Әйдә, кер, Мәгъсүм.
Мәгъсүм. Их, өздерәсең, иптәш мастер!
Акбүләк. Әйдә, күрше, уз, утыр.
Мәгъсүм. Утыр дип... Әгәр вакыт таба алсаң, бер олы киңәш бар иде, иптәш мастер.
Акбүләк. Олы киңәш булгач, булмаса да табарга туры килер, Мәгъсүм.

Мәгъсүм. Бик четерекле вопрос инде бу... минем кинәш дигәнем... Эшләр бик хөрт бит әле минем, Акбүләк туган.

Акбүләк. Нәрсә булды.

Мәгъсүм. Главное булмады шул әле. Квартир алдым. Мебель алдым. Әнине китереп утырттым. Ә менә главное белән эш начар. Прәмә-беда.

Акбүләк. Нинди беда?

Мәгъсүм. Йөрәк эшләре. Мин үлеп гашыйк, ә ул...

Акбүләк. Сине яратмыймы?

Мәгъсүм. Ярата да сыман, әзрәк кенә сизгерлегем бар ич инде. Ә менә шул турыда сөйли башладыңмы — бөтенләй тырпая... Сөйләмә, ди. Син, ди, әйбәт егет, Мәгъсүм, ди, бик әйбәт, ди. Ни дигән сүз инде бу, иптәш мастер, ә? Бер дә егет яратмаган кыз буламыни дөньяда?

Акбүләк. Күрәсең була.

Мәгъсүм. Һе! Нишләргә соң ә, иптәш мастер?

Акбүләк. И, Мәгъсүм, Мәгъсүм, мондый хәлдә нишләргә икәнен сорап, үзем әле сиңа киңәшкә кермәкче идем.

Мәгъсүм. Көлүеңме соң бу, иптәш мастер.

Акбүләк. Йөрәк эшләре көлке түгел икән шул ул. Сыкрана йөрәк, Мәгъсүм дус, яна...

Мәгъсүм. Шул шул, яна...

Акбүләк *(гармунын күрсәтеп)*. Аптырагач, шушы дуска мөрәҗәгать иттем.

Мәгъсүм. Ничегрәк соң, юатамы?

Акбүләк. Юата да, ярсыта да.

Мәгъсүм. Шул шул, ярсыта.

Акбүләк. Сәриягә чыннан да мәхәббәтең зур икән, суындырма күңелеңне. Ул әйбәт кыз.

Мәгъсүм. И-и... әйбәт кенәме соң... Ул шундый... чибәрлеген әйтмим дә, анысы болай да күренеп тора, ә менә сафлыгы аның, эчкерсез, гөнаһсыз булуы... И, кайчакта нәкъ сабый бала инде. Әле аның, мөгаен, бер егетне дә яратканы юктыр. Иптәш мастер, әллә мин әйтәм, син сөйләшеп карыйсыңмы? Ә, Акбүләк дус?

Акбүләк. Синең өченме?

Мәгъсүм. Әйе.

Акбүләк. Юк, Мәгъсүм дус, син ничек тә үзең тырыш инде, кыюрак бул.

Мәгъсүм. Һайй кыюрак дип... Аларга шул кыюлык кына да, белмәк көче генә дә житми икән. Йөрәк, йөрәк ачкычы кирәк икән. Ә нинди ул ачкыч, кайлардан табарга аны?..

Акбүләк. Минемчә, Мәгъсүм дус, аның өчен әллә кайларга барырга кирәкми кебек, үзеннән, үз йөрәгеңнән эзләргә кирәк. Билгеле инде Сәрия үзе... Аның уйлары, хисләре кай тирәләрдә әйләнә... Нинди рәк хыяллары бар, нәрсәгә омтыла.

Мәгъсүм. И-и, аңардагы хыял... Чуты-чамасы юк.

Акбүләк. Бәлки, берәр яраткан егете бардыр.

Мәгъсүм. Әйтәм ич, егет дигән сүзне ишетсә, тырпая прәме. Юк, егетләрне ярата торган кыз түгел ул.

Акбүләк. Сине ярата дисең ич...

Мәгъсүм. Соң мин... Мин бит инде ул.

Акбүләк. Егет түгелмени?

Мәгъсүм. Һей, дурак... Әллә нәмә әйттерерсең, иптәш мастер. Әйдә лутчы ул турыда сөйләшмик.

Акбүләк. Ярый, сөйләшмик. *(Икесе дә тын гына утыралар.)*

Мәгъсүм. Кара әле, болай булгач, барыйм әле мин, Сәриянең үзенә дигәнем. Туп-туры, ә? Син ничек уйлыйсың?

Акбүләк. Белмим шул.

Мәгъсүм. Юк, син бел инде, Акбүләк дус, биргән кинәшеннән кире кайтма.

Акбүләк. Кинәшне әле монда үзең бирдең миңа!

Мәгъсүм. Мин?!

Акбүләк. Йөрәккә ачкыч турында... Бары син генә, бары аныкын гына ача ала торган...

Мәгъсүм. Һ-и моны бит икәүләп, бергә-бергә уйлаштык ич инде. Кара әле, син тотма инде... Мин барыйм. Башыма әйбәт кенә уйлар килеп тора, телемә дә акыллы сүзләр килер сыман. Син, зинһар, рөхсәт ит инде, иптәш мастер, ә?

Акбүләк. Нәрсәгә рөхсәт.

Мәгъсүм. Китәргә, дим. Сәрия янына.

Акбүләк. Пожалуйста. Бар, бар, Мәгъсүм дус.

Мәгъсүм *(честь биреп)*. Есть барырга, иптәш капитан-лейтенант.

Акбүләк. Мин бары тик лейтенант кына.

Мәгъсүм. Мин матрос-моряк. Диңгезгә барсаңмы, сразу капитан-лейтенант ясыйбыз үзеңне, иптәш мастер.

Китә.

Акбүләк. Моряк? Матрос... Болай булгач, синең эшләр җиңелрәк, иптәш матрос. Ни әйтсәң дә диңгез... Корабль... Ә без — пехота... Юк, иптәш лейтенант, пехотаңа сүз тидермә. Пехота ул — сугыш кыры королевасы. Җиңүне хәл итә, ныгыта торган көч. Борыныңны төшермә, иптәш лейтенант! Җиңәрбез! Җиңәрбез һәм... Ой, белмим шул. *(Уйга чума.)*

Ишек шакыйлар. Акбүләк җавап бирергә дә өлгерми, атылып Айсылу килеп керә.

Айсылу?

Айсылу *(көчкә тын алып)*. Акбүләк абый...

Акбүләк *(борчылып)*. Нәрсә, бер-бер хәл булдымы?

Айсылу. Яшәр Харрасов... хатынын ташлап китте. Әнисен дә... Рәзилә бит ана булачак... Ана!.. Ни дә булса бер нәрсә эшлисе иде, Акбүләк абый...

Акбүләк. Без нишли алабыз соң, Айсылу?

Айсылу. Нәкъ шул турыда киңәшкә дип сиңа килдем дә, Акбүләк абый.

Акбүләк. Утыр әле, Айсылу... Уйлашыйк.

Айсылу. Аларның хәле шундый...

Акбүләк. Алар хәле нинди генә булмасын, Айсылу, без хәзер генә берни дә эшли алмыйбыз.

Айсылу. Ничек инде эшли алмыйбыз. Бу бит... бу бит... Ай! *(Башын селки һәм кулы белән йөзен каплап катып кала.)*

Акбүләк *(бераз паузадан соң)*. Яшәр янына барып, хәзер үк кире кайт, дип приказ бирү... Файдасыз, хакыбыз да юк. Хәзер генә барып Миңсрур апа белән Рәзиләне юату... Монысы инде тагын да зуррак мәгънәсезлек, тупаслык.

Айсылу. Ничек? Юк! Юк, юк.

Акбүләк. Айсылу акыллым, мондый хәлдә аларны юатам дип азапланганчы, тыныч калдырырга кирәк. Иң яхшысы шул. Уйлансыннар...

Айсылу. Тукта, кеше олы кайгыга төшә, ә син... Әй, синең шундый мәрхәмәтсез икәнеңне белсәмме...

Акбүләк. Юк, Айсылу, мәрхәмәтсез түгел мин.

Айсылу. Алай булгач, нигә соң кеше кайгысына әз генә дә исең китми.

А к б ү л ә к. Бәлки, гаеп Яшәрнең үзендә генә дә түгелдер. Бәлки, Рәзилә үзе артык рәхимсездер. Бездә дә гаеп бардыр? Бер ай, ай ярым элек әйбәт кенә эшли иде ич ул... Әле дә эшендә начар түгел...

А й с ы л у. И-и эштә начар булмаудамыни? Кеше — кеше булмагач.

А к б ү л ә к. Бәлки соңгы көннәрдә ана башка берәүнең начар йогынтысы бардыр?

А й с ы л у. Кемнең?.. Юк, булмас!

А к б ү л ә к. Кайчакта безнең күзебезгә иң матур, иң саф булып күренгән әйберләр дә агулы булалар. Магнолия чәчәкләрен беләсеңме син, Айсылу.

А й с ы л у. Ишеткәнем бар.

А к б ү л ә к. Аның матурлыгына, хуш исенә сокланмаска мөмкин түгел. Кеше йотлыгып исни аны, исни һәм исеннән исерә дә бер кайчан да айнымый...

А й с ы л у. Айнымый?!..

А к б ү л ә к. Магнолиягә охшаган кешеләр тагын да куркынычрак...

А й с ы л у. Син кем турында, Акбүләк абый.

А к б ү л ә к. Магнолия турында.

А й с ы л у. Юк, моны син Бөркетне күз алдында тотып әйттең. Шулаймы?

А к б ү л ә к. Әгәр шулай булса?

А й с ы л у. Көнләшүдән генә сөйлисең бит боларны, Акбүләк абый. Ләкин урынсыз. Шундый борчулы минутларда аякларым синең янга алып килгән икән, димәк, бернинди магнолия дә исертә алмаган мине. Шулай түгелмени?

А к б ү л ә к. Айсылу! *(Кинәт аны үзенә тартып китерә дә кочаклап каты итеп үбә.)*

А й с ы л у. Акбүләк абый... *(Пауза. Кинәт үксеп җылый башлый.)*

А к б ү л ә к. Айсылу акыллым, чү!

А й с ы л у. Мин сиңа шундый зур кайгы, хәсрәт белән килдем, ә син... Әле соң мәхәббәт кайгысымыни?

А к б ү л ә к. Бик сылу шул син, Айсылу.

А й с ы л у *(ачу белән)*. Бер дә сылу түгел. Туганда ук ямьсез булып туганмын. Пәри кебек. Әни кулына алгач, коты очып кычкырып җибәргән. Өйгә алып кайтмыйм, дип җылаган.

А к б ү л ә к. Ә әтиең?.. Син утыр, Айсылу.

А й с ы л у. Утырмыйм... Әтием ул көннәрне авырып түшәктә яткан. Сугышта җиде кат яраланган ул. Шулай да әле кайткач, елга якын эшләгән ул. Ә мин туар көннәрдә генә ярасы ачылган. Шул. Әнием больницадан кайткан да салган мине түшәккә, әйткән әтигә: «Мә, ал ямьсез кызыңны», — дигән. Шуннан әти кулына алып сөйгән мине. И-и бик сылу ич, дип юаткан әнине, — төсе, бите өчен борчылма син, йөрәге сылу булсын дигән, кызыбызның исеме дә сылу булсын дип, Айсылу куштырган.

А к б ү л ә к. Акыллы кеше булган әтиең.

А й с ы л у. Тынгысыз кеше булган. Үлем чире тоткач та әле — дөнья белән алыш-бирешем бетмәде, тегесен әле болай, монысын тегеләй итәсем бар дип, бик нык тырышкан, тырмашкан терелер өчен..., Ләкин терелә алмаган... Үлгән... Җиде айдан соң әнием дә үлгән.

А к б ү л ә к. Икесе бер үк елны?

А й с ы л у. Әйе. Ярар, Акбүләк абый, Айсылу турында житте. Әйдә киен, Яшәрне эзләп барабыз. Аннан Рәзилә белән Миңсрур апа янына...

Ишек шакыйлар.

А к б ү л ә к. Рәхим итегез!

Б ө р к е т керә.

Б ө р к е т. Хәерле кич!
А к б у л ә к *(бераз аптырап)*. Хәерле кич, Бөркет.
Б ө р к е т *(Айсылуга)*. Сине монда булыр дип уйлап ялгышмаганмын икән...
А к б у л ә к. Әйдә, Бөркет, уз, утыр! Чәй кайнатам, чәй эчәрбез.
Б ө р к е т. Юк, Акбүләк дус, рәхмәт. Концертка билет алдым. Бүген безнең Акшәһәрдә Москва филармониясенең күренекле артистлары кунакта бит. Шуңа Айсылуны алып барыйм әле, мин әйтәм.
А й с ы л у. Мин... Мин бүген концертка бара алмыйм.
Б ө р к е т. Бара алмыйсың?
А й с ы л у. Эшем бар...
Б ө р к е т. Эшне иртәгә калдыр. Менә билет. Әйдә!
А й с ы л у. Яшәрне тапмыйча, бер кая да бармыйм.
Б ө р к е т. Яшәрне? Табабыз аны. Табабыз да, концертка да алып барабыз. Әйдә.

Ишек шакыйлар.

А к б у л ә к. Керегез!

Ишек янына килә Сәрия керә.

С ә р и я. Гафу ит, Акбүләк абый, мин күршегезгә килгән идем. Нурижамал апа Мәгъсүм сездә дигәч... *(Бөркетне күреп.)* А-а... *(телсез кала.)*
А к б у л ә к. Мәгъсүм сине эзләп китте. Ә бу иптәш... Хәер син аны күргәнең бар ич.
С ә р и я *(ашыгып)*. Юк, күргәнем юк....
Б ө р к е т *(елмаеп, Сәриянең күзләренә туры карап)*. Хәтерләгез әле, хәтерләгез...
С ә р и я. Хәтерләмим, берни дә хәтерләмим.
Б ө р к е т. Хәтерләмисез?.. Хәтерегез начар, ахры, сеңелем.
С ә р и я. Ә-ә... *(Хәлсез.)* Хәтерлим... Бөркет. Минсрур апаны китергән...
Б ө р к е т. Дөрес! Ха-ха-ха! Әйтәм ич, бер күргән кешене үзем дә онытмыйм, ул да мине онытмый.
С ә р и я. Ярый, гафу итегез... *(Чыга.)*
Б ө р к е т. Ха-ха! Шәп егетне эләктергәч, күзе акайган кызның... Исеме ничек дидегез әле?
А к б у л ә к. Сәрия...
Б ө р к е т. Исеме дә жырлап кына тора икән шул. *(Айсылуга.)* Әйдә, Айсылу, киттек!
А й с ы л у. Бара алмыйм, Бөркет.
Б ө р к е т. Гажәп. Бәлки, Акбүләк рөхсәт итми торгандыр.
А й с ы л у. Мине үз ихтыярымнан башка бер кем дә тотып та кала алмый, алып та китә алмый.
А к б у л ә к. Ишеттеңме, Бөркет дус.
Б ө р к е т *(зәһәр белән)*. Тегермән!
А к б у л ә к. Нәрсә?
Б ө р к е т. Көрәсән, мин әйтәм, тик тарттырып он чыгар хәлгә житкерә алырсыңмы, дим.
А к б у л ә к. Ул чагында, Бөркет дус, синә көрәк оны түлисе булмас.
Б ө р к е т *(көлеп)*. Әгәр көнең көрәк онына кала икән, барыбер түләрмен аны сиңа. *(Ягымлы.)* Бирерәк кил әле, Акбүләк дус.
А к б у л ә к *(Бөркет янына килеп)*. Тыңлыйм, дускай.
Б ө р к е т *(йодрыгын Акбүләкнең борын төбенә китереп)*. Иснәп кара әле, нәрсә исе килә.
А к б у л ә к. Айсылу монда булмаса, нәрсә исе килгәнен күрсәтер идем инде...

Бөркет. Айсылуны алып китәм аны моннан. Китәм! Үзеңнең инженер-интеллигент булуыңнан файдаланып, Айсылу кебек саф күңелле эшче кызларны аздырма инде, Акбүләк дус. Начальник булуыңнан, тоесть үзенең служебный положениесеннән файдаланып эш итүчеләргә беләсеңме ничек карый безнең закон? Белмисең? Юк, без эшче класс вәкилләре, үз кешеләребезне мәсхәрә итәргә ирек бирмәбез! Әйдә, Айсылу.

Айсылу. Бармыйм!

Акбүләк (*тынычлыкны җуймаеп*). Синең провокацияңә мыегым да селкенми, Бөркет дус.

Бөркет. Мыегың селкенмәсә, сөягең селкенер. Бокска оста диләр ич сине.

Акбүләк. Бокска? Әйе, аңа осталыгым бар. Бар! (*Пиджагын сала.*)

Бөркет (*салкын*). Әгәр башың ике булмаса, ки пиджагыңны, мастер.

Айсылу (*урталарына кереп*). Нишлисез?

Бөркетне каты итеп этәреп җибәрә. Бөркет чайкала-чайкала барып урындыкка утыра.

Яшәр (*ишекне шакып һәм үзе үк ачып*). Ярыйдыр бит? (*Җилкәсенә транзистор аскан.*)

Акбүләк. Әйдә, кер, Яшәр.

Яшәр (*керә. Ул бераз кәефле*). У-у! Менә ул безнең дуслар кайда... (*Артыннан килгән Нэллигә.*) Әйдә, кер, кер, Нэлли! Күршеләрең ич, курыкма.

Нэлли (*кереп*). Хәерле кич! Ба-а, Бөркет! Айсылу! Акбүләк... Бар да үз кешеләр.

Яшәр. Әйтәм ич, безнең мастер эштә генә кырыс ул, ә өендә — душа. Душа — человек. (*Җырлый.*)

Ой миленкий кызларның душасы...

Айсылу. Миңа синең белән сөйләшергә кирәк, Яшәр.

Яшәр. Минем белән?! Соңыннан, Айсылу, соңыннан. (*Нэллигә.*) Я әле, Нэлли! Дуслар хөрмәтенә. (*Уйный. Нэлли аңа кушылып җырлый.*)

Язгы көндә гөлләр матур була,
Гөлләрдән дә бигрәк яшь кызлар
Бакчада кичләрне
Очратсаң иркәнне.
Матурлана бердәм тормышлар.
Бу дөньяда төрле хәлләр була,
Кайчак күкләр күкрәп алалар.
Болытлары ачыла,
Давыллары басыла,
Зәңгәрләнә тагын һавалар [1].

Яшәр. Инде үзебезнең хыр-хыр чәчәгә дә биесәң... (*Уйный.*)

Айсылу. Яшәр!! (*Яшәр уйнавыннан туктый.*) Нэлли! Ишетәсеңме, миңа сезнең белән сөйләшергә кирәк.

Нэлли. Сабыр ит, сөеклем, сабыр ит! (*Яшәргә күз кыса.*) Хэлло!

Яшәр ярсып уйный.

---

[1] С. Алымов сүзләре, М. Ногман тәрҗемәсе.

Нэлли *(бии, җырлый. Яшәр дә кушыла).*

Без биибез чачача!
Тик бары тик чәчәчә.
Белгәнебез чәчәчә,
Күргәнебез чәчәчә.
Бүген дә без — чәчәчә,
Иртәгә дә — чәчәчә.
Дөньясы да чәчәчә.
Чәчәчә, чәчәчә.
Чәчәчә-чәчәчә.
Чәчәчә-чәчәчә.

Бөркет. Браво, молодцы!

Яшәр *(Акбүләк белән Айсылу янына килеп).* Я, безнең концерт ничегрәк, мастер?

Акбүләк. Шәп.

Айсылу. Бик шәп!.. Ләкин... Кил әле монда, Яшәр.

Яшәр *(баш иеп).* Пардон!..

Ишек тә шакып тормыйча Мәгъсүм керә.

Мәгъсүм *(ишек янында туктый да йодрыгын йомарлап).* Ә-ә... мондамы әле син...

Акбүләк. Ни булды, Мәгъсүм?

Мәгъсүм. Миңа черт булсынмы, ә менә Сәриягә... Сәриянең котын алган бичараның.

Акбүләк. Кем?

Мәгъсүм. Кем булсын, әнә шул шома егет, Карчыга.

Бөркет. Бәлки, Бөркет дип әйтергә телисеңдер, Мәгъсүм дус.

Мәгъсүм. Мин синең ипи шүрлегеңне җимерәм хәзер, карга! *(Урындык алып Бөркеткә кизәнә. Аны тоталар.)*

Акбүләк. Тукта, яхшылап кына аңлат әле, ни булды.

Мәгъсүм. Нигә ул минем Сәрияне күзләре белән ашый? Җитмәсә үзен хәтерләтеп маташа, ә? Коты алынган бичараның. Рәтләп сүзен дә сөйли алмый. Бөркет минем күргән-белгән кешем түгел, ә ул, ди... Ул, ди... сүзләрен дә әйтеп бетерә алмый, бичара.

Бөркет. Мин аңа бер начарлык та эшләгәнем юк. Ни бары уенкөлке. Менә шаһитләрем, алар әйтсен.

Акбүләк. Әйе... Моны Бөркет дөрес әйтә.

Мәгъсүм. Дөрес булса шул: моннан соң уен-көлке сүзләр сөйләп тә күз атасы булмас Сәриягә. Югыйсә, сигез бабаңны бер юлы исеңә төшерермен. *(Акбүләк белән Айсылуга.)* Борчыганым өчен, зинһар, гафу итә күрегез. *(Чыга.)*

Бөркет *(башын селкеп).* Ай, бу көнчелек. Аптырыйм. Югыйсә, Отеллолар заманы да түгел хәзер.

Нэлли *(Яшәргә).* Кадерлем, безгә вакыт. Помышыбызны әйт тә...

Яшәр. Помыш дип... Безнең шулай керүебезнең сәбәбе — шатлыгыбыз зур... Алдагы ялга... көндез нәкъ өчтә Нэлли белән безнең туй мәҗлесебез...

Айсылу *(тәмам аптырап).* Туй?!

Нэлли. Туй, сөеклем, туй.. Акбүләк белән парлап рәхим итегез. Бөркет! Бу сиңа да кагыла. Хәер, сине әле өеңә барып чакырырбыз.

Бөркет. Рәхмәт, Нэлли.

Яшәр. Хәзергә хушыгыз, дуслар. *(Китәләр.)*

Айсылу *(артларыннан ишеккә йөгереп барып).* Туктагыз!

Бөркет *(Айсылуга).* Яшәр дигән идең... Әнә сине эзләп үзе үк килде.

Айсылу. Туйга чакырдылар... Нинди туй ул? Бәлки, син аңлатырсың, Бөркет?

Беркет. Бары да ачык шикелле.

Айсылу. Ничек бары да? Яшәр гаиләле кеше. Хатыны бар, тиздән баласы булачак... Әнисе...

Беркет. Четереклерәк мәсьәлә, әлбәттә... Яшьләр шул әле, яшьләр.

Айсылу. Яшь булса?..

Беркет. Әзмени яшьләрнең башында ашкын уйлар, хисләр...

Айсылу. Ашкын хисләрнең дә бер чамасы булырга тиеш... Йөгәне...

Беркет. Йөгән! Ха-ха-ха. Бу инде ха-ха-ха...

Айсылу. Бер дә кәлке түгел, шаша башлаган хисләрне йөгәнләп, хәтта авызлыклап бер юнәлеш бирсәң, бер дә начар түгел...

Беркет белән Акбүләк бер-берсенә карашып куялар.

Тукта! Кая киттеләр. *(Тәрәзәгә килә.)* У-у, алар инде урам чатында, ә мин...

Йөгереп чыгып китә.

Беркет. Айсылу!.. Тукта... Көт... *(Ишек янында туктап.)* Ә безгә аңлашып бетерергә кирәк, Акбүләк дус.

Акбүләк. Сүзең Айсылу турында булса, аңлашып торасы юк. Аны Айсылу үзе хәл итәр.

Беркет. Абайла, дустым, Айсылуны бөтенләй уеңнан алып ташла. Югыйсә, рухыңа корбан чалырга туры килүе бар.

Акбүләк *(көлеп)*. Пычагың үтмәс, Беркет дус. *(Беркетка таба атлый.)* Үтмәс!!

Беркет. Мин искәрттем, абайла! *(Чыгып китә.)*

Акбүләк. Шундый абайлармын. *(Ишекне ачып.)* Җеннәрең туз-гыр, Беркет дус!..

Ишекне яба да бүлмә буйлап йөри. Пауза. Җырлап.

Дулкыннар!
Шаулыйлар дулкыннар.
Ургылып... ярсынып... ашкынып...
Туктаусыз чабалар дулкын...

Тукта! Кая китте ул? А!.. *(Пиджагына ташлана.)*

*Пәрдә.*

## БИШЕНЧЕ КАРТИНА

Урам чаты.

Казылган канау, өй почмагы янында юан гына газ трубасы. Караңгы. Озын багана башындагы фонарь яктысы һәм өй тәрәзәләреннән төшкән яктылык сәхнәне яктырта. Өйнең бу почмагында тәрәзәләр күренми диярлек. Шуңа күрә, яктылык бик тонык. Өй читтә булганга, бу тирәдә йөрүчеләр дә бик аз. Яшәр белән Нэлли кайтып килә.

Яшәр *(Нэллине туктатып)*. Кара әле күзләремә!

Нэлли. Шундый караңгыда күзләреңне күрер дисеңме?

Яшәр. Мин күрермен.

Нэлли *(Яшәр күзләренә карап)*. Я?

Яшәр. Дөресен генә әйт. Ни өчен яратасың мине?

Нэлли *(Яшәргә сыена төшеп)*. Иңсәләрең нык булганы өчен. *(Пауза.)*

Яшәр. Урамда кочаклашып тору килешми, ди, пенсионер бабайлар. Әйдә!

Нэлли. Һи!.. Бабайлар бөтен заманда да яшьләрнең кыланышын килештермәгән. Безнең бабайлар характерын гына заман үзгәртә алмас. Әнә кара, алсу абажурлы торшер яна. Минем... Юк, безнең тәрәзә. Өйгә кирәбез дә люстраларны яндырабыз. Бәхетебез якты булып балкып торсын.

Яшәр. Әйдә!

Айсылу *(арттан йөгереп кереп)*. Нэлли!.. Яшәр!.. Бер генә минутка. Туй турында сез чынлап әйттегезме?

Нэлли. Йөрәк эшләре белән шаярмыйлар, Айсылу.

Айсылу. Ә Рәзилә?..

Нэлли. Айсылу, дустым... Минем үз турымда, Яшәрнең үз бәхете турында кайгыртырга хакыбыз юкмыни?

Айсылу. Бар...

Нэлли. Шулай булгач?

Айсылу. Ләкин икенче берәүнең бәхетен жимереп кору...

Нэлли. Әгәр Рәзилә Яшәргә бәхет бирә алмаган булса?

Айсылу. Алар бәхетле иде...

Яшәр. Син инде, Айсылу, миңа кем бәхет биргәнен белергә үземә рөхсәт ит. *(Нэллига күрсәтеп.)* Менә минем мәңгелек бәхетем. Бүген таптым аны.

Айсылу. Бүген? *(Нэллига карый.)*

Нэлли. Мин дә шулай, сөеклем.

Айсылу. Алайса Рәзилә...

Яшәр. Син мине Рәзилә белән битәрләмә... Ирекле дөньяда үз иркем белән яшәргә комачауламагыз!

Айсылу. Рәзиләгә дә син үз иркең белән өйләндең.

Яшәр. Ялгыш булган ул. Әйдә, Нэлли, киттек.

Нэлли. Сабыр ит.

Айсылу. Бәлки, дүрт-биш айдан соң, Нэлли турында да ялгыштым диярсең.

Яшәр. Әйтмәм, мин... ул... ул минем...

Айсылу. Рәзиләне дә син ул минем мәңгелек бәхетем дигән идең. Туйда!

Нэлли. Анысы инде...

Яшәр. Ышанма, Нэлли.

Айсылу. Үз хәтереңә алдаса, Минсрур  ападан, я туйда булган башка иптәшләрдән сорап кара.

Нэлли *(зәһәрләнеп Айсылу өстенә килә)*. Син... Син мине... Яшәрдән биздерү өчен сөйлисең бу сүзләреңне.

Айсылу. Юк! Мин алдамыйм, Нэлли. Бу сүзләрне әйткәндә, синнән битәр үз язмышым, үз бәхетем турында уйладым. Бәлки, миңа да нәкъ шундый ук язмыш көтә булыр. Дүрт-биш ай элек  кенә Рәзилә белән ал да гөл булып яшәгән Яшәр бүген... Әнә нинди... *(Пауза.)* Яшәр, әйт туры гына, бәлки, сине тагын биш-алты айдан туачак балаң куркытадыр?

Яшәр. Җитте!

Айсылу. Бәлки, син  ирекле дөньяда үз иркем белән теләсәм ничек яшәргә хаклымын дип, ана булыр чакта гына Нэллине дә ташлап китәрсең? Икенче бер кыз белән?

Яшәр. Китсәм, синнән рөхсәт сорамам.

Айсылу. Анысын беләм, сорамассың... Ә менә Нэлли нишләр?

Яшәр. Нэлли акыллым, тыңлама шул чеплә кигәвенен.

Нэлли. Нигә тыңлыйм... Беләм нич мин. Ул... ул... *(Зәһәр белән.)* Син инде минем турымда борчылма, сөеклем. Нэлли үз кадерен дә, ир кадерен дә белә торган кыз. Бәхетне дә күктән түгел, җирдән эзли... Җирдән таба. Үзе дә ирләрне бәхетле итә ала. Боларның берсе өчен дә син мине гаепли алмыйсың, сөеклем. Мин үз заманым кызы.

Айсылу. Замандамыни эш, жирлеген ят, йөрәгең ала-кола булгач.

Нэлли. Ничек, ничек? Ала-кола?!

Яшәр. Әйдә кайтыйк, Нэлли... *(Житәкләп алып китә.)*

Айсылу *(кычкырып)* Тыныч йокы, Нэлли. *(Китә башлый. Каршысына Бөркет килеп баса.)* Бөркет!

Бөркет. Синең турыда борчылып артыңнан килдем.

Айсылу. Минем турыда борчыларга кирәкми, Бөркет. Ә менә Яшәр...

Бөркет. Яшәр ул үзе дә яшәр. Нэлли дә дөнья күргән кыз... Иң элек үз бәхетең турында кайгырт, Айсылу.

Айсылу. Мин гел үз бәхетем турында кайгыртып йөрим.

Бөркет. Беләм, Айсылу, син кешеләргә яхшылык эшләү теләге белән йөрисең. Шунын өчен төн йокыңны калдырасың. Тик ярый ла синең яхшылыгыңны аңласалар, аңа рәхмәт әйтсәләр.

Айсылу. Мин рәхмәт алу өчен түгел, үзем өчен эшлим. Кешегә бер ярдәм күрсәтсәм, аңа яхшы булудан да бигрәк, үземә рәхәт була. Күңелемдә ниндидер бер жылылык, яктылык торып кала.

Бөркет. Анысы әйбәт. Тик шулай да олы бәхетне киңрәк юллардан эзләү яхшырак, минемчә.

Айсылу. Анысы дөрес тә сон...

Бөркет. Әгәр без аны киң юлдан эзләсәк? Бергә, бергә, ә? Табабыз, ди и «Волга»га утырып жилдерәбез генә! Тулы бәхет белән! Ирекле дөньяда үз иркебез белән бәхетле булып яшәүгә ни житә? *(Айсылуның беләгеннән алып.)* Ә Айсылу? Ризамы?

Айсылу. Бу миңа тәкъдим ясавыңмы?

Бөркет. Тәкъдим? Әйе, Айсылу. Без шундый бәхетле булыр идек... Ышан миңа...

Айсылу *(басып торган килеш)*. Сиңа ышанмаска хакым юк... Тик...

Бөркет. Бәлки, миңа кереп утырырбыз? Ерак түгел ич.

Айсылу. Башка вакытта. Хәзер миңа кайтырга кирәк. Әйдә, үзен безгә. Иртәгә иртән, сәгать биштән үк, Миңсрур апа кайтып китәргә жыена... Саубуллашып калырсың.

Бөркет. Нигә саубуллашып кына, әгәр шулай иртә китә торган булса, вакытым бар. Мин аны үзем үк озатып куярмын. Өенә кадәр үк.

Айсылу. Шулай булса, мең рәхмәт әйтер идек.

Бөркет. Мең? Юк, бер рәхмәт тә бик житкән.

Айсылу *(сәгатенә карап)*. Миңсрур апалар йокламагандыр әле, бәлки. Әйдә, Акбуләкне дә кереп алырбыз.

Бөркет. Акбуләк? Юк инде, Айсылу акыллым, синең янында аны артык күрәсем килми. *(Кулыннан тота.)*

Айсылу. Абау, кулымны!

Бөркет. Айсылу бәгырем, кичер, яратам!.. *(Кочаклый һәм каты итеп үбә.)*

Айсылу *(ыңгыраша)*. Жибәр! А-ай!..

Бөркет. Яратам!..

Айсылу. Кит! Жибәр!

Бөркет *(шашынып)*. Яратам...

Айсылу *(хәлсез)*. Кычкырам!.. А-а...

Бөркет *(авызын каплап)*. Юк...

Айсылу *(хәлсезләнә барып)*. А-а...

Акбуләк йөгереп чыга һәм Бөркетне жилкәсеннән алып, көч белән этәреп жибәрә. Бөркет, мәтәлә-мәтәлә барып, жиргә егыла.

Акбуләк. Подлец!

Бөркет. Син?! *(Кирпеч алып Акбуләккә таба килә.)*

А к б ү л ә к. Ташла! Югыйсә дружинниклар чакырам... Кешеләр!.. *(Кесәсеннән сыбызгы чыгара.)*

А й с ы л у *(Акбуләкне тотып)*. Кирәкми, Акбуләк абый... хурлыгы миңа ич аның. Әйдә!.. *(Акбуләкне җитәкләп алып китә.)*

Б ө р к е т *(тукталып кала. Ташын ташлый)*. Бөркеткә кул күтәрдең?! Начар фал, онытма!

*П ә р д ә.*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### АЛТЫНЧЫ КАРТИНА

Айсылу бүлмәсе. Беренче картинадагы декорация. Төн. Сәхнә караңгы. Бераздан ишекне сак кына ачып, А й с ы л у керә.

А й с ы л у *(пышылдап)*. Әйдә уз. Менә бу якка атла, хәзер ут яндырам.

А к б ү л ә к. Миңа инде кайтып китсәм дә ярыйдыр.

А й с ы л у. Юк, юк... Өч кенә минут булса да утыр. Хәл ал. *(Өстәлдәге лампаны яндыра. Сәгатенә карап.)* Өченче биш минут... Ой! *(Хәлсезләнеп урындыкка утыра.)*

А к б ү л ә к. Курыктыңмы?

А й с ы л у. Бик... Ярый әле син килеп җиттең. Шашкын мәхәббәте белән йөрәгемне яра иде, мөгаен.

А к б ү л ә к. Мәхәббәтме икән соң ул.

А й с ы л у *(башын селкеп)*. Белмим!.. *(Тыңлый. Аяк очына гына басып барып Рәзиләләр бүлмәсен карый.)* Миңсрур апа сыкрана мескен. Ә үзе иртәгә иртүк... Юк, бүген инде... иртүк китәм, ди...

А к б ү л ә к. Бәлки, озатып калырга мин дә килермен...

А й с ы л у. Кил, Акбуләк абый. Миңсрур апага да күңелле булыр. Рәзиләгә дә.

А к б ү л ә к. Ярый алай булса, киттем. Син ике-өч сәгать булса да йоклап, ял итеп ал.

А й с ы л у. Ярый, Акбуләк абый. Үзең дә ял ит.

А к б ү л ә к. Хәерле таң, Айсылу.

А й с ы л у. Таң? *(Утны сүндерә.)* Чынлап та таң... Нинди матур булып сызылып килә. Яратам җәйге таңны!

А к б ү л ә к *(әкрен)*. Мин дә...

А й с ы л у. Син миңа «Таң атканда»ны бер уйнарсың әле, яме, Акбуләк абый.

А к б ү л ә к. Уйнармын, Айсылу.

А й с ы л у. Мин җырлармын *(әкрен генә җырлый.)*

Уяна кошлар тирәктә,
Җәйге җил куя исеп,
Кузгала җырлар йөрәктә
Шунда син...

Бар, Акбуләк абый, кайт... Әйдә озатам.

А к б ү л ә к. Әйдә...

Чыгалар. Бераздан Айсылу әйләнеп керә.

А й с ы л у. Уф-ф... Йоклап ял итеп ал, имеш... И-и... Айсылу күзенә йокы керәме мондый төнне. Нишләргә соң? Әй, хәлләрең дә хәлләрең, Айсылу... Эшең күп, теләкләрең тагын да күбрәк, ә көчең — чыпчык борыны. И-их көчләрем житсәме, әйләндереп торыр идем бер дөньясын. *(Пауза.)* Ярый әле Акбуләк абый булды... У-у... Нинди мәкерле ул!.. Көләч йөз, акыллы сүзләр... Ә мин җүләр... Коточкыч!.. Әгәр ул намусыңны таптап өлгерсә... Хурлыгыңнан кая барыр идең син, җүләр кыз...

*(Паузадан соң зәһәр белән.)* Синеме!.. Былбыл булып сайраучы козгыныммы... Былбыл булып сайраучы козгын?! Чү! Кем әйтте әле бу сүзне?.. Кем? Сәрия!.. Әйе, әйе!.. Хәзер ул Акшәһәрдә диде. *(Каты кычкырып.)* Бөркет!!! А-а!.. Юк, уянганын көтеп тора алмыйм.

Йөгереп ишеккә бара һәм Сәрия бүлмәсенә керә. Бераздан Сәрияне житәкләп чыга.

Сәрия *(эчке күлмәктән, ялан аяк, чәче тузгыган. Өстенә юка одеял ябкан)*. Котырдыңмы әллә, кая өстерисең?
Айсылу. Утыр әле шунда!

Сәрия утыра.

Турысын гына әйт — кем иде ул синең Ангарадагы ирен?
Сәрия. Кем дип... ир сыман ир.
Айсылу. Син аны хәзер Акшәһәрдә дидең... Әйт хәзер үк, кем? Кем ул?
Сәрия. Мине үтерергә телисең... Әйтмим! *(Йөгереп китә.)*
Айсылу. Алайса үзем әйтәм. *(Сәрия туктый.)* Бөркет!
Сәрия. Бөркет?! Юк, бернинди Бөркетне дә белмим. Күргәнем дә юк.
Айсылу. Миңа барысы да мәгълүм. Үзенә начарлык теләмәсәң, дөресен әйт. Минсрур апаны китергән шофер шулмы? Әйт!
Сәрия. Юк...
Айсылу. Курыкма! Тырнак белән дә чиртергә ирек бирмәбез. *(Пауза.)* Намуслы кеше икәнсең, әгәр сиңа дөреслек, гаделлек кыйммәт икән, яшереп калма!
Сәрия. Юк, дим, юк...
Айсылу. Сиңа күрсәткән бөтен әшәкелеген сөйлә.
Сәрия. Булмый! Белмим мин аны, белмим!..
Айсылу. Ярый, үзем юлын табармын. Син бар, йокла. *(Сәгатенә карап.)* Хәер, йоклар лык вакыт та калмаган... Тиздән биш була. Бар! *(Сәрия китә.)* Алай-й! *(Утыра. Уйлана. Көлеп җибәрә. Тагын кашлары җыерыла. Кыскасы, озак кына вакыт уй-хисләр чагылышы бары тик йөзендә һәм кул хәрәкәтләрендә генә күренә. Ишек шакыйлар.)* Ул! Сәгать биш тулган ич. *(Ишеккә барып.)* Керегез!

Бөркет керә.

Айсылу *(шат)*. Бөркет?
Бөркет. Хәерле иртә!
Айсылу. Шундый иртәме?
Бөркет. Сине күреп гафу үтенү өчен иртәрәк килдем, Айсылу. Бик борчылып, үземнән үзем оялып килдем.
Айсылу. Ни өчен?
Бөркет. Төнлә эшләгән тупаслыгым өчен.
Айсылу. Тупаслык? И-и... Бөркет... *(Көлә.)* Юкка борчылма. Йөреп-йөреп бер егетлек күрсәткәнсең икән — оялма! Тик миңа ирнемне авырттырдың...
Бөркет. Димәк, син миңа ачуланмыйсың?
Айсылу. Юк, әгәр үзең миңа ачуланмасаң...
Бөркет. Сиңа? Ни өчен?
Айсылу. Усал булганым өчен.
Бөркет. Аның өчен ачуланасы бар иде дә...
Айсылу. Аңа да өлгерерсең. Бөркет абый, сиңа бер йомышым бар.
Бөркет. Синең өчен берне түгел биш йомыш үтәргә әзер, Айсылу.

Айсылу. Машинан белән җилдереп кенә Яшәрне алып кил, әй! Миңсрур апа исәнләшеп китсен... Ни әйтсән дә улы бит...

Бөркет. Мин... авыррак йомыш икән. Яшәр бит ул хәзер...

Айсылу. Шуңа күрә сиңа кушам да. Син Яшәрне күндерә аласың...

Бөркет. Анысында сүз дә юк.

Айсылу. Нәлли курыкмасын. Аның Яшәрен Миңсрур апа да, Рәзилә дә тотып ашамас. Иректә, иркен доньяда яшибез... Һәркемнең үз ихтыяры, үз бәхете... Шулай ич? Әгәр бик шикләнсә, Нәлли үзе дә килсен. Килсен, обязательно килсен. Айсылу чакырды, диген.

Бөркет. Ярый, Айсылу сөеклем. Синең өчен икесен дә кырык, кырык биш минуттан җилтерәтеп китереп җиткерәм.

Айсылу. Менә бу егетлек була, ичмасам.

Бөркет. Очтым, Айсылу сөеклем.

Айсылу. Оч Бөркет, оч. Олрайт! *(Нәлличә кул изәп озатып кала.)*

Бөркет китә.

Оч әйдә, оч! Канатларың каерылгач, оча алмассың!

Пәрдә. Ут сүнә.

### ҖИДЕНЧЕ КАРТИНА

Шул ук бүлмә.

Миңсрур апа кечкенә чемоданын һәм бер төенчек күтәреп чыга.

Рәзилә *(аңа ярдәмләшеп)*. Син юкка гына ашыгасың, әнкәй. Тагын бер өч-дүрт көн торырга иде...

Миңсрур. Юк, Рәзилә кызым... Торуымнан файда булса, айлар буе торыр идем дә, файдасы юк... Үземдә дә гаеп бар. Төпчегем, бердәнберем хәзер шушы бала инде дип, артыграк иркәләп ташладым. Ике абыйсы сугышта һәлак булгач, бу балабыз инде яшәсен, ичмасам, дип, исемен Яшәр кушкан идек... Яшәвен бик теләгән идек... Шатлыгыбыз булыр дигән идек... Юк, хәзер күрәм инде, шатлык китермәде ул. Хатынына кул күтәргән, анасына җикеренгән бала өметсез бала, бәхетсез бала ул...

Рәзилә. Әнкәй, кирәкми...

Миңсрур. Сиңа да авыр, кызым, миңа да... Килсә, ичмасам, соңгы сүземне әйтеп китәр идем. Килмәс.

Рәзилә. Айсылу килә диде бит. *(Кинәт авыр сулыш алып куя.)* Әнкәй... *(Пауза.)*

Миңсрур. Нәрсә, кызым?

Рәзилә *(әкрен)*. Яшәр мине бөтенләй ташласа да, баламны барыбер табачакмын.

Миңсрур. Тапмыйча әллә. Табасың, кызым. Бүтән уйны башыңа да китермә. Икәүләп тәрбия итәрбез.

Айсылу *(кулына пакет тотып керә)*. Әбәү, Миңсрур апа, төенәлеп тә беткәнсең ич. Кая шушыны урнаштырыйк әле.

Миңсрур. И-и, Айсылу кызым, кучтәнәчне болай да бик күп төядегез. Рәхмәт, кызым.

Акбүләк *(ишек шакып)*. Мөмкинме икән?

Рәзилә. Әйдә, Акбүләк абый, кер, уз.

Акбүләк *(керәп)*. Хәерле иртә. Синең хәлләр ничек соң, Миңсрур апа.

Миңсрур. Әлегә ярыйсы, улым, рәхмәт.

Акбүләк. Китә дип ишеттем дә саубуллашып калыйм дип кердем.

Минсрур. Бик рәхмәт, улым. Китәм. Болай да инде бик озак тордым... Озак, тик... *(Пауза.)*

Акбүләк. Икенче килгәндә, туп-туры үземә төш, Минсрур апа. Менә адресым. Телефоным да язылган. Бераздан, бәлки, әнием дә килер әле. Бергә-бергә гөрләшеп, чөкердәшеп утырырсыз.

Минсрур. Рәхмәт, Акбүләк улым.

Айсылу *(тәрәзәдән карый. Гомумән аның кәефе бик күтәренке. Җырлап та ала, биеп тә куя.)*

Үзләренең коесы бар,
Безгә килеп су ала.
Чиләген тутырып ала да
Көлә, көлә югала.

*(Рәзиләне кочаклап.)*

Ай йолдызым, йолдызым,
Йолдызым, Рушаным;
Син кергән гөл бакчасына
Керергә тырышамын.

**Акбүләк.** Әйбәт җырлыйсың.

Айсылу. У-у!..

Минсрур. Син шат бүген, Айсылу кызым.

Айсылу. Сиңа да кайгырырга кирәкми, Минсрур апа, берни өчен дә! *(Пауза.)* Ә Яшәргә әйтәсе сүзләреңне әйт. Туп-туры әйт, каты итеп. Комсомол гвардиясечә.

Минсрур. Кайтса, бик әйтәм, кызым.

Айсылу. Кай-таа! *(Машина тавышы.)* Әнә, кайтты да. *(Тәрәзәдән карый.)* И-и, син китәсе машина белән үк кайткан, Минсрур апа.

Минсрур. Ә-ә... алайса шул, әлеге мине алып килгән унган егет белән инде.

Айсылу. Унган... Әнә бит, үзем алып килдем, үзем үк илтеп куям, ди сине. *(Чыга.)*

Минсрур. Рәхмәт яусын инде бу Айсылуга... Ул булмаса, машина табулары да...

Рәзилә. Яшәр бит әнә...

Яшәр керә. Рәзилә чигенә.

Яшәр *(ишек төбендә туктап).* Хәерле иртә, әни... Хәерле иртә, Рәзилә! *(Пауза.)*

Айсылу *(ишектән керә-керә).* Хәерле иртә, Яшәр, әйдә, уз, утыр.

Яшәр. Килгәч инде узармын. *(Түргәрәк узып урындыкка утыра.)* Тик менә әни белән Рәзилә генә миңа бик кырын карап торалар.

Минсрур. Күрсәткән кыланышларыңа шатланып, якты чырай күрсәтергә кушар идеңмени?

Яшәр. Әгәр үз балаңның бәхетле булуын теләсәң, нигә.

Минсрур. Әле туып та өлгермәгән баланы ятим калдыруны бәхеткә саныйсың икән, юк, теләмим...

Яшәр. Бала ятим булмас, әни, курыкма. Мин аны үземә алып, үзем тәрбия итәчәкмен.

Рәзилә. Уйлама да! Йөзен дә күрсәтмәм.

Акбүләк. Рәзилә! Тынычрак, сеңелем.

Яшәр. Суд нәрсә әйтер бит әле.

Минсрур. Намуслы анадан бала тартып алган суд юк ул бездә. Булмас та... Әнә дингез артында андый суд.

Яшәр. Шул ләгънәт суккан диңгез арты дигән җирдә бәхет дигәнең мулрак түгелме икән.

Айсылу. Нинди дулкыннан әле бу хәбәр.

Яшәр. Югары дулкын...



Сәрия ролендә Флера Хәмитова.

Айсылу. «Иректе дөньядан». Шулаймы?

Яшәр. Шулай булса?

Сәрия *(керә)*. Исәнме, Яшәр!.. Чү! Әзерләнеп тә беткәнсез түгелме?

Минсрур. Мин күптән әзер, кызым.

Яшәр. Мин бүре түгел, Сәрия, сөзеп карама.

Сәрия. Юк, сөзеп түгел, яратып карыйм.

Яшәр *(коры)*. Карама, мохтажлыгым юк.

Сәрия. Бәлки, минем мохтажлыгым бардыр.

Яшәр *(әче мыскыл белән)*. Үз мохтажы белән ирләргә тагылган хатыннан алла үзе сакласын.

Сәрия. Уй... *(Колагын тотып йөгереп китә.)*

Акбүләк. Тупас син хәзер, Яшәр.

Яшәр. Гафу үтенәм, иптәш инженер. Сезнең монда икәнлекне сизмәдем. Югыйсә, колак шәрифләрегезне рәнҗетмәгән булыр идем.

Айсылу. Дустың Хәйям шәкерте булгач, телгә остарган хәзер син.

Яшәр. Һәрхәлдә, синең кебек җан коючы җәфа түгел.

Айсылу. Мин — җәфамы?

Яшәр. Барыгыз да! *(Айсылуга.)* Ә син җәфа гына да түгел, мине тереләй йотарга торган аждаһа!

Айсылу. Син тыныч кына бул әле, Яшәр абзыкай. Дуламыйча гына иптәшләреңә җавап бир: әниеңне, хатыныңны, балаң, иптәшләреңне мәсхәрәләп йөрүдән кайчан туктыйсың.

Яшәр. Куркытмакчы буласыз?

Айсылу. Син комсомолец?

Яшәр. Булса?

Айсылу. Кем өйрәтә сиңа мондый әшәкелекне.

Яшәр *(әнисенә карап)*. Миннән допрос алырга чакырып китердегез? *(Тора.)*

Минсрур. Утыр!

Яшәр утыра.

Кемгә генә охшап шундый булдың соң син, балам.

Яшәр. Кемгә булсын, сиңа, әтигә охшаптыр, мөгаен.

Минсрур. Әтиеңә? Юк, атаң мондый түгел иде синең.

Мәгъсүм керә дә исәнләшми-нитми генә Сәрия янынарак килеп баса.

Иң авыр елларда гомер иттек без аның белән... Гражданнар сугышы, ачлык, колхоз төзү, Ватан сугышы. Ул аһ-зарның ни икәнен дә белмичә, көн-төн эшләде дә эшләде. Сугыштан яраланып кайткач та әле, сыңар күзле килеш, райкомда елдан артык җаваплы эш алып барды. Мин дә тик ятмадым, һаман эштә булдым. Сезне тәрбия иттем. Шул вакыт эчендә миңа кул күтәрү түгел, ник каты сүз әйтсен. Менә нинди кеше иде ул синең атаң.

Яшәр. Әти белән сез инде идеяле әүлия булгансыз...

Минсрур. Ничек, ничек?

Яшәр. Идеяле әүлия. Ач булса да — тук. Ялангач булса да —

күңелен көр итеп күрсәтә. Күренеп тора — хәл начар, жыларга кирәк, акырырга, ә әүлия күл чаба, урра кычкыра.

Миңсрур. Читкә каерма, бала. Яла да якма. Кирәк икән, әйе, иң фажигале минутларда да «ура» кычкырыр, утка да, суга да ташланыр, коммунист ул чөнки.

Яшәр. Күрәм ич мин жаваплы эш алып барган күп кенә коммунистның ничек яшәгәнен. Һи-и!.. Ә әтинең... Гомер буе эшләп, безгә калдырган мирасы нәрсә булды. Ике бүлмәле фатир аламасы да дүрт орден белән өч медаль.

Миңсрур. Шулар әзмени? Яхшы ата баласы дигән мактаулы исемнән дә кадерлерәк нинди мирас кирәк сиңа, оятсыз!..

Яшәр. Әйтер сүзегез шул идеме? *(Китә башлый.)*

Миңсрур. Тукта!!

Яшәр туктый.

Айсылу. Син инде әниең сүзен тыңлап бетер, Яшәр.

Миңсрур. Сүзем бик кыска минем. *(Яшәргә.)* Шуны гына әйтәм: комсомол сафында тору өчен яраксыз син, улым.

Яшәр. Синең хакың юк, әни...

Миңсрур. Иптәшләрең дә шул ук сүзне әйтәчәк.

Яшәр. Әйтсә бит... *(Иптәшләренә карый.)*

Айсылу. Комсомоллар сафыннан төшеп калганга борчыласым юк, дисеңдер, бәлки?

Яшәр. Дисәм?..

Барысы да Яшәргә кырыс кына карап куялар.

Айсылу. Шулай инде, синең бит хәзер яңа дусларың бар.

Яшәр. Бар, чын дусларым бар.

Айсылу. Ләкин чын дусмы икән алар.

Яшәр. Бөркетме?.. Һи!..

Бөркет керә. Тынлык.

Бөркет. Хәерле көн, дуслар! *(Барысының да ниндидер бер шик белән карап торуларын күреп.)* Сәламемне алмавыгыз аңлашылмый, хөрмәтле дуслар? Нигә әле миңа шундый сәер караш?

Айсылу. Нигә икәнен аңлатып бир әле, Сәрия.

Сәрия. Мин?! Мин бер нәрсә дә белмим.

Айсылу. Ничек белмисең? Каршыңда әнә, былбыл булып сайрап, сине бишенче хатын итеп алган кеше, Бөркет түгел идемени?

Барысы да. Нәрсә?!

Мәгъсүм. Бишенче хатыны?

Миңсрур. Коточкыч!..

Сәрия. Юк! Түгел! Түгел.

Айсылу *(Бөркеткә)*. Бәлки, дөресен үзен әйтерсең, Бөркет?

Бөркет *(елмаеп)*. Шаян кыз икән син, Айсылу. Белми идем.

Айсылу *(Сәриягә)*. Сине назлаган, иркәләгән булып, намусыңны таптаган, буып үтерә башлаган кеше... Дөресен әйт: шушы күркәм егет — Бөркет түгел идемени?

Рәзилә. Әнкәй жаным, утыр. *(Тетрәнеп калган Миңсрурны урындыкка утырта.)*

Бөркет. Син, Айсылу сөеклем, ни сөйләгәнеңне белеп сөйлә.

Айсылу. Бик белеп сөйлим. Әнә Сәриянең муенында синең тырнагын эзләре әле дә бар.

Бөркет *(Сәриягә туры карап)*. Тырнак эзләре!.. Булмас!

Сәрия. Юк!! *(Муенын кулы белән каплап.)* Бер нинди эз дә юк!

Яшәр. Син, Айсылу, кешегә яла якма.

Миңсрур. Башкалар сөйләгәнне тыңла син.

Нэлли *(ашыгып керә дә Яшәргә ташлана).* Яшәр, кадерлем, менә син кайда?

Яшәр *(аны бер як читкә этәреп).* Сабыр ит, Нэлли.

Нэлли *(җыларга җитешеп).* Нинди комедия бу?

Бөркет. Мине гаепләрлек бер дәлилең дә юк синең, Айсылу. Берегезнең дә! Бөркетне өркетү, бигрәк тә аны җәтмәгә эләктерергә азаплану өчен синең әле башың яшь, Айсылу акыллым. Ә менә шундый ахмак сүзләр белән кәефемне кырганың өчен синнән мин җавап ала башласам, тетрәнерсең...

Айсылу. Юк инде, Бөркет абзыкай... Син шулай янап, үтерәм дип куркытып Сәриянең авызын томалый алгансың... Ә минекен... Юк!.. Көчең җитмәс! *(Сәриягә, кискен итеп.)* Я әле, Сәрия, ачык кына әйт: бергә торганыгызны кемгә дә булса сөйләсәң, дөньяда йөртмим, дип янадымы сиңа Бөркет?

*(Пауза.)*

Миңсрур. Курыкма, кызым, әйт.

Акбүләк. Әйт, Сәрия, дөресме шул?

Сәрия *(паузадан соң).* Дөрес!.. Ул... ул... *(йөгереп икенче бүлмәгә кереп китәргә уйлый да ишек төбендә туктала.)*

Бөркет *(артка чигенә).* Ялган!..

Сәрия. Син! Син ул козгын!

Акбүләк. Менә кем икәнсең син, кабахәт!

Бөркет. Саграк сөйләш, егет.

Айсылу *(Яшәргә).* Менә ул синең югары дулкыннарың. *(Бары да кырыс кына Яшәргә карыйлар.)*

Яшәр. Тукта, нигә әле миңа шулай текәлдегез? Әйтерсең бүре мин... *(Пауза.)* Иптәшләр, имеш, дуслар. Юк!.. Сез, сез... *(Чигенә-чигенә ишеккә бара.)* Әйдә, Нэлли!

Миңсрур. Юк инде, бала, тукта! Әниеңнең соңгы сүзен дә ишетеп кит.

Яшәр туктый.

Әгәр шушы дуамаллыгыңны тагын дәвам итсәң, дөньяда әнием бар дип исәпләмә. Ничаклы авыр булса да сине мин үз йөрәгемнән суырып алып ташлаячакмын! Дусларын, иптәшләрен, анасын югалткан кеше — туган илен дә югалткан кеше ул. Әнә бар, яшәп кара син дөньяда дус-ишләрсез, туган илсез.

Яшәр *(тетрәнеп).* Ой!..

Бөркет. Яшәр! Әйдә! *(Аның янына килә.)*

Мәгъсүм *(куркынып чигенгән Сәрия янына килеп).* Курыкма, Сәрия!

Айсылу *(Бөркеткә).* Юк, тырнакларыңны тырпайтма инде хәзер. Яшәрне без сиңа бирмибез.

Мәгъсүм *(ишек күрсәтеп).* Сыпырт моннан, чыпчык!

Акбүләк ишек ача.

Бөркет *(үзенә нәфрәт белән текәлгән күзләрне күреп).* Әйдә, Нэлли!

Нэлли аңа нәфрәтле караш ташлап икенче якка борыла. Бөркет бер ялгызы кызу гына чыгып китә.

Пауза. Сүзсез уен. Шул арада нишләргә белми аптырап калган Нэлли дә әкрен генә чыгып югала. Яшәр ишеккә килә дә ишекне нык итеп ябып куя. Радиода җыр яңгырый.

Шаулыйлар дулкыннар, дулкыннар,
Үргылып, ярсынып, ашкынып...

*Пәрдә төшә.*

## Х. Камалов

# ТОРМЫШ ДУЛКЫННАРЫ

ПОЭМА

Мин кайчандыр элеваторына
Икмәк ташып йөргән станса...
Тик узышлый юлым төште шунда.
Их, дим, берәр дус та очраса?!
Базарына кердем. Юраганым
Юш килсә дә булмас болай ук:
Күрәм, бергә олау йөргән дустым

Мине танып, килә елмаеп.
— Камил абый! —
Күзенә яшьләр тулды,
Ә чәчләрен ап-ак бәс сарган.
Мин фронтка аны озаткан идем
Менә шушы шаулы вокзалдан.
Шуннан бирле...
Ул өенә кыстый.

Бардык. Йорты — яңа бураткан,
Семьясы да ялга киткән икән, —

Бу бит инде оҗмах ир-атка!
Искә алдык бөтен үткәннәрне,
Нинди рәхәт шулай
Утыруы төннәр буена.
Беркемгә дә отчет бирәсе юк,
Беркем кысмый, иркен уеңа.

Һәркемнең бар иле белән бергә
Кичергән зур ачы язмышы,
Һәм бар фәкать үзе генә белгән
Кан-яшьләрен койган сагышы.
Ипидән сүз китте.

Камил абый
Ипи телеме тотып: — Могҗиза!. —
Диде житди. — Серен кемнәр белә
Бу ипинең! Ә мин мең риза
Яшәвемнән! Ипи генә булсын,
Бер авырлык җанга көч түгел.
Ипекәйсез — кеше нәрсә соң ул?! —
Шуны күрдем.

Әй ачыта һаман бу күңел!.. —
Абый тынды. Ул азга да риза,
Сугышларда күпне кичергән,
Ә әсирлек инде түбәнлекнең
Бар ачысын аңа эчергән.
— Ипи төшкә кереп,
Бик газаплый иде. Арада
Бер егет бар иде. Искә төшсә,
Якты күңем карангылана.
Исеме Әсгать иде, кушаматы
Нәрсәгәдер инде «пәйгамбәр»,
Ул бәетләр гел чыгара иде,
Әллә шуңа исем биргәннәр.
Тиф эләккәч, барысы куркып, мине
Язмышыма ташлап качканнар.
Тик бу калган, хәтта сөенеп куйдым
Аңга килеп, күзем ачканда.
Азыкны ул миңа сугышып тапкан.
Безне фашист шулай бит тота:
Читлектәге ерткычларга гүя
Койма аша сөяк ыргыта.
Фашист шулай тәҗрибәсен ясый
Безнең тормыш, безнең җан белән...
Бер профессор килеп, бер әсирне
Өшеткән, ди, салкын ваннада.
Ә берсенә тиф вакцины биргән,
Кох-бацилла — икенчесенә...
Моны безгә бер чех чиште. Ул сер
Эверелде нәфрәт көченә...
Шулай итеп фашист кешелекне
Ватып торды, җанны җимереп.
Фәкать Әсгать аркасында гына
Өзелмичә калган гомерем.
Бик башкисәр, үткен егет иде,
Азапланды һаман таярга.
Абзый, башлар әрәм югала, дип
Бик өзелә иде кай ара.

Эчтә янган уч тә рәнжү генә,
Өмет, пыскып, бара кимүгә,
Ачлык безне физик яктан бетерә,
Без куелган әкрен үлемгә.
Әсгать инде белми нишләргә дә,
Бер тиз үлем эзли шикелле.
Рухи үлем аны алалмаган,
Ул яшисе килеп җилкенде.
Әллә инде чиккә җитеп бара?
Шешенеп,
Салынып төшкән күз кабаклары,
Буранкадай эчкә баткан
Ач яңаклары.
Юк әле, ул көч җуймаган икән,
Беләгеннән тоткач шаярып,
Тойдым. Ләкин ул бик моңсу иде,
Һәм ашыккан кебек каядыр,
Бирде миңа бик өметсез генә
Әнисенә язган хатларын:
— Юләрләнмә! — димәи, үзен-үзе
Үтерер дип калмый котларым.
Кулын селти. Китте. Мин дә чыгып
Җылынып тора идем кояшта,
Күрәм, лагерь капкасыннан немец
Папка тотып атлый бу якка.
Якынайды, тере мәетләрдән
Хасыйл итеп тере коридор
Без тезелдек ике яклап. Фриц
Эттәй ырлый, үзе шундый зур.
Ләкин кинәт... аяк чалдылармы,
Ул сөртенеп, алга бөгелде
Һәм дыңк итеп җиргә барып төште,
Бар әсирләр шунда өерелде
Бөҗра булып. Мин читтәрәк. Кемдер
Гыр-гыр килә шунда уртада,
Ату тавышы — кайдан? Хәрәкәтләр
Тиз-тиз, ахры, төркем
Берәр хикмәт кылып бутала?
Ул арада проходнойдан икәү
Ата-ата килә! Чәнчелде!
Төркем
Җебеннән ычкынган төймәләрдәй,
Төрле якка кинәт чәчелде.
Баракларга тулды. Тәрәзәдән
Күрәм ике гәүдә тигендә:
Берсе зәңгәр — тюлень кебек түшкә,
Икенчесе — безнең киемнән.
Дер-дер киләм. Күзне ачып баксам,
Соры гәүдәлесе
Аркылыга аңа — сарышкан,
Күрәм, ышанасыңмы,
Фриц бугазына
Теше белән, ахры, ябышкан!
Әйе, әйе! Йөзен шәйләп булмый,
Кем икән, ә? Җаннар сыктады.
Конвой тибә әсиргә,
Шул фрицтан тизрәк аермакчы,
Тибә шашып, теге купмады.
Үлгән, ахры, тарта, йолкынмагач,
Приклад белән ала каерып.
Каннар чәчри... Үзем күрмәсәм, һич
Моңа ышанмас идем.
Аерып,
Ике армай фриц гәүдәсен
Тиз-тиз җыйды,
Каткан бугай күзе тояктай.
Ә әсирне — җирдән өстериләр
Дулый-дулый ике полицай.
Аннан күтәрделәр,
Кинәт танып,
Безнең төркем шунда ах итте.
— Пәйгамбәр! — дип кемдер әйтеп куйды,
Әрәм булды егет! Эх, бетте!..
Һәм Әсгатьне — җанымны мин дә
Танып алдым — белсәң хәлемне?
Күз алларым томанланды кинәт,
Чәнчү алды хәлсез тәнемне,
Үләм диеп торам. Авыр булды!
Туганымнан артык кеше иде!
Һәлак булды фриц җенен чәйнәп.
Эх,
Бу баш күпме
Кеше ышанмас хәлләр кичерде!?.
...Абый туктый, тавышы калтыранып,
Мөлдерәмә тулды күзләре,
Еламаска ул тәмәке тарта.
Дәвам итә аннан сүзләрен:
— Шул тәмугтан ничек исән чыктым?
Уйласаң гел гаҗәп тосла.
Өйгә кайттым зур өметләр белән,
Әсир булып кайту кыен ла!
Мин теләсә нигә риза идем,
Ис китмәде кимсетүләргә,
Ни булса да тоткынлыкта түгел,
Туган җирдә, була түзәргә.
Эш бирмичә газап чиктерделәр,
Анысына да кослып төшмәдем.
Туган илдә таш та ярдәмчел, ди,
Мин көнлекче булып эшләдем...
Башта авыр булды. Тора-бара
Минем дә, — ди, — тормыш көйләнде...—
Абый миңа баштан үткәннәрен
Шулай озак итеп сөйләде.
Аннан зур сандыкта актарынып
Алды нидер.
Сары пергаментка төрелгән:
— Менә, — диде, — Әсгать әйберләре! —
Ачып куйды, чишеп җебеннән.
Чәчелеп китте вак-вак кына майсыл
Яфраклардай сары кәгазьләр:
— Бу маргарин кәгазьләре, шуңа
Язган икән, мескен, әз-әзләп.
Әнисенә тапшырмадым тик, жәл,
Әманәткә иттем хыянәт.

Курыктым да, заманы бит шундый,
Андый чакта көтмә мәрхәмәт.
Уйлый калдым,
Әсирлеген, димен, белсәләр,
Әнисенә авырлыклар килер,
Пенсиясен, димен, кисәрләр.
Шулай калды, мәшәкатьләр күмде,
Ихтыярым бетте төкәнеп.
Эчтән яндым булдыксыз мин диеп,
Үземне-үзем тиргим, үртәнеп.
Хатларым да гел җавапсыз калды,
Шул сыкраудан узып булмады... —
Сүзе бетеп, абый чәен уртлый,
Сизәм, күзем яшькә тулганын.
Үзәк өзгеч җәл бигрәк тә Әсгать,
Күбәләктәй кыска гомере.
Бик беләсем килде, сугышкача
Ничек булган? Нинди көн күреп
Үскән икән шулай гаюр, кыю?!
Бу дөньяда
Нинди генә булмый кешеләр?
Алдын-артын уйлап тормый, илгә
Мәңге тугры шуның ишеләр!
...Мин Әсгатьнең язмаларын алып,
Вәгъдә иттем эзен табарга.
Абый белән иртән хушлаштым да
Киттем
Зарурият тарткан юлларга.
Өйгә кайтып, тузаннарны каккач,
Язмаларны тагы укыдым.
Тагы мине әрнү биләп алды,
Һәрбер сүзе җанны йолкыды.
Менә алар:
...Хуш, әнкәем, бергә-бергә инде
Язмагандыр, ахры, яшәргә,
Вәхши затлар тырнагына каптык,
Алар безне салды мәхшәргә.
Көн-төн бардык без эшелон белән,
Күпләребез явыз дошманны
Бик тиз юк итмәкче иделәр.
Вагоннардан төшкәнче үк ләкин —
Сез пленда инде, диделәр.
Юл киселде, кайтып булмас инде.
Хәерлегә юра барысын да.
Минем белән бәйле хыялларың
Чынга ашмас инде! Калсыннар!
Белмим нигә, мин бик юньсез булдым,
Үч итеп шул һаман әтигә.
Күп көйдердем синең җаныңны да,
Барысы өчен — шушы нәтиҗә!

Бар нәрсәмне талап бетерделәр,
Ерткычларга кем соң аяныч?!
Уйда гына яшим, уйларым да
Югалталар инде таяныч.
Син нәрсәдер сизенгәндәй, әнкәй,
Күзәтәсең булыр капканы.

Ә мин монда сулыгып-сулыгып ятам
Шинелемә баштан капланып.

Ышанмассың, әнкәй, син сөйләгән
Тәмуг үзе монда, нәкъ үзе.
Кисәү кебек янам, янам шунда,
Тик җан чыкмый һаман, бир түзем.
Кешелегемне салып таптадылар,
Юк инде ул синең бәбкәең.
Мине күрсәң,
Бу түгел бит минем улым диеп,
Син качарсың миннән, әнкәем.
Чит җирләрдә кала сөякләрем,
Күз алларым, әнкәй, караңгы.
Я, хушлашыйк инде соңгы кабат,
Син күрмәссең газиз балаңны...

Син исәнме, әнкәй, туган җирдә,
Төшемә дә никтер кермисең?
Ә мин менә һаман чыкмаган җан,
Өмет белән йөрим, белмисен.
Мин барыбер исән калырмын да
Сине күрермен күк тоела,
Кояш нуры мәзәк, вак яңгырдай
Тып-тып итеп башыма коела.
Рәхәт була, күз алдыма килә:
Мин исән-сау өйгә кайтырмын,
Түр сәкегә безнең мендәр салып
Сине генә карап ятырмын.
Ә син миңа самавыр куярсың,
Әзерләрсең маең, балыңны,
Һәм сөйләрсең миңа ашыкмыйча
Мин юк чакта булган зарыңны.
Кем булышкан сиңа, суык кышта
Кемнәр сиңа утын китерткән,
Зарланырсың, эчең бушатырсың,
Кемнәр сине кайчак кимсеткән?
Теләкләрең сөйләрсең дә миннән
Әйбәт эшләр өмет итәрсең.
Өметеңне мин аклармын, әнкәй,
Бар шул ләкин кайтып җитәсе!
Әнкәй, ни булса да
Мин гаепле синең каршыңда,
Сау бул инде,
Хәерлегә юра барысын да!..»

Шунда өзелә сүзләр — гомер кебек!
Нинди егет! Нинди һәлакәт!
Ду китерде мине бу фаҗига,
Гүя
Тормышымнан качты бәрәкәт.

Бик күңелсез булды миңа бу көз,
Һаман йөрим күңелем кителеп,
Гүя минем гаеп белән аның
Гомере калган шунда киселеп...

Туганнарын тизрәк табарга дип
Юлга чыктым — теге авылга.
Юл унса — шәп, ә уңмаса, димен,
Ял итәрмен шәһәр шавыннан.

Баргач белдем: бергә укыган дус
Завуч икән! Кердем шуларга.
Авыл өе: мич артында бәрән,
Бәйдә бозау — идән сугара.
Өстәлендә ярмаланып пешкән
Бәрәңгесе — барысын яратам!!
Ашап-эчкәч мин фермага бардым,
Җалулар бар шуңа карата.
Ак халатлы кызлар. Бер чаясы
Әйтеп куйды: — Шәһәр абый, ник
«Безразмерный» оек кайтармыйлар,
Һәм «Болоньи» плащлар юк? — дип.
Кышка сылтап, мин уенга бордым.
Тик кыз икән чынлап уй йөртә:
— Авыл шулай, — диде, —
Кышын җәй турында,
Ә җәй көне кышны кайгырта! —

Ә соныннан!.. Әле могҗизаның
Күргәнем юк иде булганын,
Фермадагы баягы кыз үзе
Булып чыкты Әсгать туганы!
Чынлап менә! Башта ышанмадым.
Иртүк бардым.
Һәм аңлаттым нигә килүемне.
Зифа эштә, тик бер апа өйдә,
Ул бетерде булган шигемне.
Мин Әсгатьнең язмаларын бирдем,
Гаҗәпсенеп апа тын торды,
Язуыннан аның таныды да
Күзләренә кинәт яшь тулды.
Апа хаста икән, Зифаны ул
Ике-өч яшьтән үзе үстергән.
Сугыш чоры еллары шул инде
Тазалыгын тәмам бетергән.
— Бичараның бәхете булмады, — дип
Сөйли апа Әсгать турында, —
Ярсу иде, үзен-үзе бер дә
Тоталмады инде кулында.
Күрәчәге әллә булгангамы
Яшьлегенә чыдый алмады,
Ул авылда атамандай йөрде,
Бер усаллык аннан калмады.
Әче такмак чыгарумы кирәк
Начар эшләп йөргән кешегә.
Ялкауларга әйткән мәзәкләре
Хәзер дә әле халык исендә.
Әй, әләкте мескен ул балага,
Ашкындымы ла җаны нигәдер?
Әтисенә каршы барды, ана
Ике утта — хәсрәт чигә гел.

Ә фронтка — икесенә бер көн
Хәбәр килде. Беттек елашып,
Аталы-уллы болар сугыштылар
Ни өчендер тагы дулашып.
Кабат монда кайтмыйм, диеп Әсгать
Җиргә ятып мескен үкседе,
Гарьлегеннән, әллә сизенеп әйтте:
Барыгыз, диде, мине күпсенде!
Йомшамады, әтисе дә каты
Бәгырьле иде, ачу саклады.
Утырып китте икесе ике олауга,
Икесе дә кире кайтмады.
Хәтта алар хушлашмаган да, ди,
Тәялгәндә аерым вагонга,
Кире нәсел шундый, эшнең соңын
Уйламыйлар һичбер чагында.
Әсгать шунда, әй, үзәкне өзде:
Әнкәй, диде, мине күрмәссең,
Минем өчен бүтән кешеләргә
Күренергә оялып йөрмәссең.
Әнисе шул бик бетеште, уйдан,
Йокы кермәс булды күзенә.
Әсгать тавышын ишетәм, диде һаман,
Дәшә диде мине үзенә.
Аермачык менә ишетәм, ди,
Тавышы килә урман ягыннан.
Эзләп китә. Мин зур шиккә тарам,
Язмагае бу, дим, акылдан.
Юк, акылында! Бераз тынып кайта.
Җиңеләйгән кебек сагышы.
Эшкә йөри. Аннан тагы шулай
Ишетә башлый улы тавышын.
Инде нишлим? Врач, им-томчыда
Бик күп булды, һич юк файдасы.
Әле нәни кызыннан ул бизде,
Ачуланам, һич юк дәгъвасы.
Нишләдең син, апа җаным, диям,
Башым шаулый, ди дә бетерә.
Сулды тәмам, керфекләре озайды,
Толымына көн дә чал керә.
Бер көн кышын, эштә идем, апам:
«Әсгать тавышы!» — диеп, торган да
Чыгып киткән, — мине дәшә, — дигән,
Һәм адашып үлгән буранда.
Ярты авыл эзләп табалмадык,
Яз, кар киткәч, чыкты гәүдәсе... —
Күз яшьләре апа сүзен бүлә,
Авыр инде сөйләү һәммәсен.
Мине дә шул кайгы биләп алды,
Көчсез итеп сиздем үземне,
Тамагымда төер, юатырга
Сүз әйталмыйм, борам йөземне.
Апа елап, бушап калуын көттем,
Аннан чыктым, имин хәл теләп.
Мескен ана күз алдыннан китми,
Бәгыремне тора телгәләп...
Тагы килдем, Зифаны очратырмын

Дигән идем, туры килмәде.
Апа ята башын шәлгә чорнап,
Җиксенмәде минс, сөйләде:
— Зифа шулай минем кулда үсте,
Ун классны чыкты бетереп.
Хәзер инде менә мине карый,
Бар кирәкне тора җиткереп.
Эштә алдын, икмәк, акча бик күп
Алып килә ун ел бер тоташ.
Яхшы гына яшәргәе дә бит,
Сугыш-ни юк, ләкин аптыраш:
Бу кешегә нидер җитми һаман?
Бар нәрсә бар, яшә, шөкер ит!
Киим дисәң — кием, ашарга — аш,
Бәрәкәтен җуйма — шулай бит!
Әле район үзәгеннән берәү
Зифаны бик
Сорап йөргәч, риза булынды.
Апамны да үзем белән алам
Дигән икән, егет суынды.
Шуның белән башы әйләнеп йөри,
Шунда китте, бетәр ни булып?

Апа диеп җайлы егетләрне
Ычкындырды. Бара яшь узып.
Инде бәхил, ялгыз калсам да мин,
Үз оясын телим коруын... —
Апа тынды... арыган.
Бик уңайсыз миңа
Аны шулай борчып торуы.
Сәубуллаштым, хәер-саулык теләп.
Тик моңсулык җанга сарылды,
Зифа бәхетен табалырмы?
Шул уй
Эзәрлекләп миңа тагылды.

Кичен инде мин — поездга. Нинди
Әйбәт кешеләр! Килми китәсе,
Шунда калып, килә гел аларга
Бик күп, бик күп игелек итәсе.
Алар өчен бөтен авырлыкны
Үз җилкәмдә килде илтәсем.
Кирәк булса алар тормышы өчен
Теләсә нинди сират кичәсем.

1967

# ЯЗУЧЫ, ЖУРНАЛИСТ ҺӘМ ПУБЛИЦИСТ

«Барыбыз да беләбез: елга бер мәртәбә, сабан туенда халык алдыннан чабып үтәр өчен, бик кадерләп, тәрбияләп, чабыш атлары үстерәләр. Аларга карап сокланалар, алдан килгәннәрнең муенына чиккән сөлгеләр салалар. Чабыш атларыннан үзгә буларак, йөк атлары бер карауда ук күз явын да алмыйлар, алар турында алай шаулашып сөйләшмиләр дә, мактамыйлар да. Чөнки аларның хезмәте шундый — ару-талуны белмичә көне-төне эшлиләр алар.

Мәхмүт Галәүне әдәбиятның әнә шундый бер йөк аты дияр идем мин».

Бу сүзләрне Мәхмүт Галәүнең 80 еллык юбилеена багышланган кичәдә өлкән язучыбыз, М. Галәүне якыннан белгән, аның белән бергә эшләгән Афзал ага Шамов әйткән иде.

Әйе, Мәхмүт Галәү — татар совет әдәбиятының, культурасының үсешенә зур өлеш керткән, бөтен гомерен иҗат эшенә, халыкка хезмәт итүгә багышлаган талантлы һәм үзенчәлекле язучы.

Мәхмүт Галәү 1886 елның сентябрендә элекке Казан губернасы, Арча кантоны, Ташкичү авылында ярлы хәлфә семьясында туа. Башлангыч белемне ул әтисеннән ала.

Ярлы семьяда үскән Мәхмүткә крестьян тормышының ачысын-төчесен татырга, зурлар белән бергә авыр кыр эшләре эшләргә туры килә. Дөрес, авыл тормышы эчендә кайнап үсүнең булачак язучы өчен отышлы ягы да була: ул татар халык тормышын бөтен детальләре, гореф-гадәтләренең бөтен нечкәлеге, милли үзенчәлеге, крестьян психологиясен бөтен тирәнлеге белән күңеленә сеңдерә бара. Күңелгә сеңеп калган бу сурәтләр соңрак язучының тормыш тәҗрибәсе, иҗтимагый аңы, талант көче белән сугарылып, гаять колоритлы әдәби образларга әвереләләр, ягъни, әдәбият фәне теле белән әйтсәк, язучы тормыш материалын үзенең күңел лабораториясендә эшкәртеп, зур сәнгать дәрәҗәсенә җиткереп бирә.

Унбер яшендә Мәхмүт Галәү Казанга килеп, андагы мәдрәсәләрнең берсенә укырга керә. Монда да аңа үз көнен үзе күрергә, үз икмәген үзе табарга туры килә.

1903 елда ул, мәдрәсәне тәмамлап, Астраханьга китә һәм анда мөгаллимлек итә башлый.

Астрахань чоры Мәхмүт Галәүнең тормышында һәм иҗатында зур роль уйный. Бирегә ул РСДРПның Астрахань комитетына член булып керә, күренекле татар революционеры Ибраһим Моратов белән комитетның эшендә актив катнаша.

1907 елда комитет каршындагы татар төркеменең органы булган «сәяси әдәби, сатирик» «Туп» журналы чыга башлый. Мәхмүт Галәү «Туп»ның актив хезмәткәре һәм фактик редакторы була. Бу журнал, бик кыска гомерле булуына карамастан (аның бары өч кенә саны чыгып кала), зур иҗтимагый мәсьәләләр күтәрүе һәм аларны гаҗәп кыю чишүе белән әһәмиятле.

Революцион эшчәнлеге, укучылар арасында дингә каршы агитация алып баруы өчен Мәхмүт Галәүне эшеннән чыгаралар. Ул туктаусыз полиция күзәтүе астында яши.

1907 елда ул Оренбургка күчеп килә. Бирегә типографиядә хәреф җыючы, корректор булып эшли, төрле урыннарда хезмәт итә.

Мәхмүт Галәү 1915 елдан «Кармак» исемендә әдәби-сатирик журнал чыгара башлый.

«Кармак» татар тормышының һәр ягын яктыртып, төрле мәсьәләләр күтәрә. Семья, мәктәп-мәдрәсә, китапханә, театр, депутатлар эшчәнлеге (дөресрәге: эшлексезлеге) — берсе дә аның күзеннән читтә калмый.

Журнал әдәбият мәсьәләләренә гаять зур урын бирә, әдәбиятка күзәтү алып бара.

Оренбургта яшәгән чорында Мәхмүт Галәү журналистлык эшчәнлегеннән тыш шигырьләр һәм хикәяләр дә яза башлый. 1912 елда Хөсәеновлар типографиясендә аның «Ник язылганнар» исемле беренче шигырьләр җыентыгы басыла. Җыентыкка кергән шигырьләрнең беренче тәҗрибә генә булуын автор үзе дә кереш сүзендә искәртеп әйтә: «Әдәбиятыбызның тарихы белән шөгыльләнүче затлар өчен мисал булырга ярар дип бастырдым», — ди.

Мәхмүт Галәүнең шигырьләре турында сөйләгәндә ике зур художникның аңа ясаган йогынтысы турында әйтеп китми мөмкин түгел.

Бер яктан, Галәүне С. Рәмиев поэзиясенең романтикасы, көчле рухы дулкынлан-

дыра, аның аллага, күкләргә каршы күтәргән бунты мавыктыра. Рәмиев шигырьләренең нәфислеге, эмоциональ көче, чын татар телендә язылган булулары да йогынты ясый.

Мәхмүт Галәүнең поэзиясендә генә түгел, гомумән аның бөтен иҗатында тирән эз калдырган икенче зур художник, язучының замандашы Габдулла Тукай була.

Тукай йогынтысында аның беренче шигырьләре языла. Укучы балалар өчен ул Тукай шигырьләреннән хрестоматияләр — «Уку китабы» төзи. «Тукай шагыйрьме, түгелме?» дигән бәхәстә ялкынланып Тукайны яклап чыга. Галәүнең сатирасында да шагыйрьнең шифалы йогынтысын күрәбез. Һәм, ниһаять, иҗатының иң өлгергән җимешләре — романнарында Тукай белән гаҗәп аваздаш яңгыраган идея бу ике әдипнең үз халкына кайнар мәхәббәтен, халкының зурлыгы, бөеклеге белән горурлануларын исбатлый. Башлангыч чорындагы иҗаты ук Галәүнең киң эрудицияле, белемле язучы булып формалаша башлавы турында сөйли. Бу уңайдан бигрәк тә аның Пушкин, Лермонтов, Толстойны тәрҗемә итүен күрсәтергә кирәк. Бу инде турыдан-туры рус әдәбиятының җәүһәрләрен татар укучысына җиткерү, пропагандалау дигән сүз. Галәүнең русча яхшы белүе, тәрҗемәчелек эшенең беренче тәҗрибәләре анда соңрак үз әсәрләрен дә русчага тәрҗемә итәрлек сәләт үстерә.

Бөек Октябрь революциясе Мәхмүт Галәү иҗатында да яңа чишмәләр ачып җибәрә. Ул, әдәбиятның гаять көчле идея коралы икәнен яхшы аңлап, совет әдәбиятын үстерүгә үзенең талант көчен, акылын җигә.

1926 елдан башлап Мәхмүт Галәү тулысы белән иҗат эшенә кучә. Галәүнең бу чор иҗатына халкыбызның тарихына игътибар арту, революцион һәм тарихи вакыйгаларга тәҗрибәлерәк күз белән карап бәяләү хас. Галәү «Саламторханнар»[1] исемле пьесасында татар интеллигенциясенең бер төркемен тасвирлый. Газетачы, милләтче Хәлим үзен милләт каршында гаять зур хезмәт күрсәткән кеше итеп исәпли, чынлыкта исә аның кебек кешеләрнең «хезмәте» мәҗлесләрдә «милләт, милләт» дип авыз суы корытудан узмый, хәлиткеч момент килеп җиткәч, алар ни эшләргә белми калтырап төшәләр.

Тарихи вакыйганы сурәтләү, халыкны киң планда күрсәтүгә омтылыш ягыннан шул ук 1926 елны язылган «Пугач явы» пьесасы да (Мәскәү, СССР халыкларының үзәк нәшрияты) кызыклы. Бу пьесада характерлар да бөтенрәк, сюжет агышы да кызурак, жанр буларак та сәхнә әсәре таләпләренә күбрәк җавап бирә. Пьесада төп герой — Пугачев. Аннан башка тагын 46 персонаж бирелеп, казак крестьяннарының образлары тудырылган.

Беренче пәрдә. Пугачевның Җаекка кайтып барышы. Ул гадел тормыш өчен көрәшергә карар итә, үз тирәсенә ышанычлы кешеләр туплый. Аның эчке дөньясы, кеше буларак характеры да шактый тулы ачылган. Дөрес, аның аң-фикере үзе мәрхәмәтле патша булу, шул юл белән халыкны иреккә чыгару, җирле итү турындагы утопик хыял белән генә чикләнгән. Ләкин Пугачевның халыкны көрәшкә күтәрү факты самодержавие тәхетен бер тетрәтү була. Ул үзенең үлеменә дә оптимистларча карый: «Тотылганыма үкенмим, кулымнан килгәнне эшләдем. Калганын бездән соңгылар тәмамлар! Уңышлы җирне бер кат сөреп чыктык инде без. Сөрелгән җиргә табылыр игенчесе: орлыкның чәчелер икенчесе! Ул чагында үзебез булмасак, телгә алынырбыз!» — ди ул.

Мәхмүт Галәү иҗатында хикәяләр үзенчәлекле бер урын алып торалар. Язучы иске тормышның кешеләр аңын никадәр тирән агулавын, яңа белән искенең катлаулы көрәшен, бу көрәшнең кешеләр психологиясенә нинди йогынты ясавын сурәтли. Дөрес, хикәяләр барысы да бердәй уңышлы түгел. Авторның каләм шомалыгы да, реалистик образлар тудырудагы осталыгы да, гомумиләштерү көче дә ачылып бетми әле. Ләкин язучы яңа тормышның котылгысыз җиңүен, шәһәр — авыл мөнәсәбәтләрен, геройларының психикасын ача алган.

1927 елда Казанда аның «Каяу» исемендә хикәяләр җыентыгы чыга.

«Төеннәр»[1] җыентыгына тупланган хикәяләр дә шулай ук җитди, заманында зур бәхәсләр куерткан мәсьәләләрне күтәрә. Автор: «Совет семьясы нинди булырга тиеш? Ир белән хатынның тигез хокуклы булуы семьяда ни рәвешле чагылырга тиеш? Ана булу вазифасы белән җәмагать эшен ничек бергә сыйдырырга?» — дигән сорауларга җавап эзли.

Күргәнебезчә, Мәхмүт Галәүнең иҗаты гаять күп яклы һәм киң. Ул иҗатын журналист буларак башлап җибәрә һәм романтик рухта язылган шигъри тәҗрибәләрдән зур эпопея дәрәҗәсендәге романнар язуга үсеп җитә.

Утызынчы елларда Мәхмүт Галәү «Канлы тамгалар» исемендәге роман-эпопеясын яза башлый. Бу әсәр дүрт кисәкле итеп уйланыла һәм автор ул кисәкләрне «Ил тыныч чакта», «Ил әреккәндә», «Сабак», «Өермәләр» дип исемли.

Роман киң планлы итеп уйланыла һәм аңа татар халкының тормышын ерак тарихтан башлап, мөмкин кадәр тулы итеп, һәр яктан тасвирлау максаты куела. Һәр кисәкнең үзәгенә зур бер тарихи вакыйга алына һәм вакыйгалар тарихи эзлеклелек белән үстереләләр. Уйланылышы буенча роман XIX гасыр ахырындагы татар тормышын сурәтләүдән башлап, татар халкының язмышында гаять әһәмиятле роль уйнаган зур вакыйгалар аша Октябрь революциясенә килүен күрсәтергә һәм революция вакыйгалары белән тәмамланырга тиеш була. Ләкин романның беренче ике кисәге генә язылып кала, шәхес культы елларында язучының гомере фаҗигале рәвештә өзе-

---

[1] М. Галәү. Саламторханлар. М., 1926 ел.

[1] М. Галәү. Төеннәр. Хикәяләр җыентыгы. Казан. 1928 ел.

лә. Язылган өлешләре дә татарча басылмый калып, кулъязма хәлендә югалалар. Галәүнең иҗаты гаҗәп кырыс сыйнфый көрәш елларына туры килүе, язучының иҗатына да, әсәрләренә карап түгел, аның анкетасына, социаль чыгышына карап бәя бирүләр Галәүнең тормыш шартларында да, романнарының язмышында да чагыла. Язучыны Шиһап Мәрҗәни нәселеннән булган өчен, мулла нәселеннән дип, аңа «вак буржуа язучысы» дигән мөһер сугарга тырышу да була. Бу хәл романнарның татарча басылып чыгуына да комачаулый.

Романның беренче кисәге «Муть» (Болганчык еллар») 1931 елда Мәскәүдә басыла. Тәрҗемәчесе Гайшә Шәрипова була. Икенче кисәге — «Мухаджиры» («Мөһәҗирләр») — авторның үз тәрҗемәсендә 1934 елда чыга. Романнарда татар тормышының зур бер тарихи чоры алына. Вакыйгалар XIX йөзнең соңгы елларында һәм 1905 елгы революция алдыннан бара. XIX гасырның 80 елларындагы ачлык, 1897 елда Россиядә үткәрелгән халык санын алу татарлар тормышында зур чуалышлар китереп чыгара.

Патша самодержавиесенең бетмәс-төкәнмәс салымнары, рус булмаган халыкларны кысуы өстенә, авылда бөтен властьны үз кулларында тоткан мулла-мөәзиннәр, ярым-ярты грамоталы старосталар да авыл халкының тәнендә сөлек булып яшиләр.

Менә шундый типик бер татар авылын сурәтләүдән башлый язучы. Беренче карашка авыл тыныч кына яши кебек. Борынгыдан, ата-бабадан килгән гореф-гадәтләре, мир белән идарә итәргә дип җәмәгать белән сайлап куйган муллалары, патша хәзрәтләренең әмерен җиткереп торучы староста, становойлары бар. Ярлы-ябагайга Сабирҗан мөәзиндә көн яктысы күрмичә, күзләре чиләнгәнче чыпта сугарга мунчала да, авыл кызлары өчен Әсмабикә абыстайда күзләрнең нурын, сылу гәүдәләрнең зифалыгын ала торган чигүле сөлге-ашъяулыкка җитәрлек җеп тә бар.

Ашарыңа юк икән, рәхим ит, Сабирҗан мөәзин алдагы уңыштан өчләтә кайтарып бирү шарты белән он да биреп тора, аның рәхим-шәфкате киң.

Байларның мал-мөлкәт арттыру мәшәкате, ярлыларның үз моң-зарлары. Барысы да алладан дип, риза булып яши бирәләр.

Ләкин бу беренче карашка гына шулай күренә, авыл тормышы тын инештәй, бер дә болганмыйча ага төсле. Чынында исә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр бик киеренке. Бу киеренкелек вакыйгалар кискенләшкән саен арта бара. Язмышлар да шундый тыгыз булып бер йомгакка чорнала, җепләрен өзгәләмичә бу йомгакны сүтү, ипкә китерү мөмкин түгел.

Тарихка зур афәт булып кереп калган 1880 еллар — ачлык еллар башлана. Табигать стихиясе китергән бу бәла моңа кадәр дин пәрдәсе, гореф-гадәтләр белән капланып яткан каршылыкларны өскә тартып чыгара. Ялангачланып калган авыл фонында мулла-мөәзиннәрнең комсызлыгы да, байкуштаннарның ерткычлык дәрәҗәсенә җиткән рәхимсезлекләре дә «мөселман агай-энегә ярдәмле булырга» тиешлек фәлсәфәсеннән арынып шәрә килеш кала. Диннең дә, самодержавиенең дә черекләре ташудан соң калкып күтәрелгән чүп кебек өскә чыга. Моңа кадәр астыртын гына эшләнгән явызлык, законсызлык, ярлы крестьянны талау ачыктан-ачык эшләнә башлый. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр дә киеренкеләнә бара. Авылда әле өч катлау аерылып тора иде: байлар, урта хәллеләр һәм ярлылар. Ачлык елдан соң исә урталык калмый: я ул үзенең туганын, якынын, күршесен алдау, талау хисабына баеп китә, яисә бөтенләй бөлеп, ярлы-ябагайлар рәтенә баса.

Галәүне халыкның барлык физик көче, рухи кичерешләре соң чиккә җитеп киеренкеләнгән вакыт, зур вакыйгалар кызыксындыра. Нәкъ шул вакытта инде тамыр сәбәпләр ачылып китә, кешеләр характерының да нигезе, асыл сыйфатлары гына кала. Ачлык елы, халык санын алу вакыйгалары, Төркиягә күчеп китүләр — болар Галәүне тарихи вакыйга буларак кына кызыксындырмый, әлбәттә. Бу вакыйгалар татар халкының тормышында нинди роль уйнаганнар, халыкның милли характерын ачуда, аның аңын үстерүдә рольләре нинди — язучы өчен шунысы әһәмиятле.

Бөтен бер халыкның үткән тормышы гаять киң планда, бик нечкәләп, детальләп тасвирланган. Бу тасвирлауларның әдәби көче гаҗәп җанлы картиналар тудырган, бөтен бер заманны укучыга җиткергән. Язучы татар тормышының һәр ягын сурәтли: авыл халкының төрле катлаулары, шәһәр байлары, приказчиклар, асраулар тормышы, мәдрәсәдәге шәкертләр, дин әһелләре, татар чиновниклары, интеллигенция — берсе дә читтә калмаган. Сюжет җепләре бу катлауларның барысына да үтеп керә. Язучы оста хирург кебек катламнарны күтәрә барып вакыйгаларны җәелдерә, характерларны киңәйтә бара.

Әйткәнебезчә, роман тәмамланмаган, шулай ук татарча кулъязмасы да сакланмаган (әсәрнең язылган ике кисәге 1968 елда, татарчага тәрҗемә ителеп, аерым китап булып басылып чыгачак). Ләкин бу хәлендә дә ул язучының иҗат принцибын, үзенчәлекләрен белгеләргә мөмкинлек бирә һәм Мәхмүт Галәүнең талантлы әдип булганлыгын раслый.

**Флера ГЫЙЛМАНОВА.**

Мәхмут Галәү

# БОЛГАНЧЫК ЕЛЛАР

РОМАННАН ӨЗЕК

## Ирдәүкә



Көтү күптән кайткан инде. Тавыклар да кунакчаларында йоклыйлар. Картлар да йокларга яткан. Бары тик яшь киленнәр генә йокламаган — он илиләр, ипи изәләр.

Күктә ай калка.

Авыл уртасындагы бер йорт янында лапастан җырлый-җырлый тукмак суккан тавышлар ишетелә: анда кызлар киндер тукмаклыйлар. Кечкенә-кечкенә дүрт каен тукмак лапас өрлегенә сүс бау белән тарттырып бәйләгән киндерне тукмыйлар. Салмак кына дөпелдәгән тукмак тавышы картларны йокыга талдыра, яшьләр йөрәгендә тынгысыз дәрт кузгата.

Сыздырып гармун уйнаган тавыш яңгырады. Кызлар су ташый торган елга буендагы сукмактан ашыкмый гына егетләр менеп килә иде. Менә алар урамга да чыктылар. Гармунчы уртада. Ул, башын бер якка кырын салып, киерелеп-киерелеп гармун тарта. Ике егет җыр башлады:

Урамнардан узган чакта
Капкаң булсын кагарга.
Әгәр картлар чыгармаса,
Чык тәрәзә ябарга.

Җырга кушылып әче итеп сызгырып та җибәрәләр. Төркем ишәя бара. Янадан-яңа егетләр, яшүсмерләр килеп кушыла тора. Тавыш көчәя бара.

Мулла йорты белән мәчет турысына җиткәч, егетләр тындылар. Тавышлар бераз басылып торды һәм, ул турыдан узгач, яңадан яңгырый башлады.

Егетләр тар тыкрыкка борылдылар һәм арткы стенасы урам ягына караган салам түбәле лапас турысына җиткәч, туктап калдылар. Лапаста, стенаның теге ягында, кызлар эшли, егетләр аларның киндер тукмаклавын, җырлавын ишетеп килгәннәр иде.

Егетләрне чакырган кебек, тукмаклар ешрак дөпелди, кызларның нәфис куллары тырышыбрак эшли башлады. Җыр-гармун тавышлары катырак яңгырады.

Тәрәзәңне ачып куеп
Кемгә күлмәк кисәсең?
Кашың кара, буең зифа,
Сылуым-иркәм,
Кем бәхетенә үсәсең?

Пыяла муенса бөртекләре чылтырашкан сыман тавыш белән каршы жырлап җавап кайтардылар:

Ишегеннән келәсен
Элә белми эләсең.
Картлар да йоклап бетмәгән,
Бигрәк иртә киләсең!



Егетләр моңа сөенештеләр. Жыр, гармун тавышы тынды. Егетләрнең беришеләре тәмәке төрергә кереште, беришеләре ярык аша кызларга сүз куша башлады.

— Исәнмесез, кызлар!

— Кискән-кискән, киссәләр дә исән!

Егетләр көлешеп алдылар.

— Телегезгә салынып тормагыз!.. Йосыф абзый йокламаган әле!..— дип кычкырдылар тегеннән.

— Нишли ул?

— Тире жыеп күн эшли.

— Бәлки, иләк белән су ташый торгандыр өенә?

Егетләрнең берсе, сүзне бүлеп:

— Йосыф абзый кем ул безгә? Чыксын, әйтербез үзенә: без карга түгел, чебешләрегезне алып китмәбез! — диярбез. Ботыбыздан асып куймас ич безне! — диде.

— Әй, куян йөрәк! Мактанган була тагын!.. Йосыф абзый чыкса, иң элек син элдертерсең әле...

Көлешә башладылар. Егетләр, шаярып, стена ярыгыннан салам суздылар.

— Мәфтуха, мә, тот!

— Сабира, кил әле!

— Галимә, кунарга кайчан чакырасың?

Кызлар ярыкка су, туфрак сиптеләр. Жыр, гармун тавышлары бозылды. Тукмаклар да салмак дөпелдәми башлады,— алар үсмер кызлар кулына күчте.

Тонык кына ай яктысында ике як та бер-берен күзли башлады.

Шул вакыт кызлар кинәт стенадан читкә тайпылыштылар. Көтмәгәндә тыкрык ягындагы кечкенә капка ачылып, өстенә озын җилән, аягына киез итек, кашларына чаклы батырып мех бүрек кигән бер кеше килеп чыкты. Кулына зур гына күсәк тоткан иде. Егетләр тиз генә як-якка йөгерештеләр.

Күсәк күтәреп чыккан әлеге кеше егетләрне әллә ни ерак кумады, ашыкмыйча, эрәеп кенә, лапаска таба кире кайтып килгәндә, сукмак буена үскән биек әрекмән арасыннан берәү аның күсәген эләктереп алды. Күсәкле кеше туктады. Егет әрекмән арасыннан чыкты. Икесе дә, бер-берен танып, сүзсез генә, үк шикелле очлы күз карашлары белән карашып тора башладылар. Якын-тирәгә поскан егетләр, ни булыр икән дип, тынnарын кысып көтеп яталар иде. Күсәкле кеше шунда көтмәгәндә:

— Исәнме, Сафа абый! — диде.

Әрекмән арасыннан чыккан егет.

— Кара, нинди үскәнсең! Бөтенләй зур кыз булгансың! — дип куйды.

Кыз, күсәкне егет кулында калдырып, капкага таба китте.

— Сажидә, туктале, сүзем бар...

Сажидә туктамады.

— Икенче бер тапкыр, Сафа абый! — дип, капкадан кереп китте.

Егетләр, поскан җирләреннән чыгып, яңадан элекке урынга җыелдылар.

— Мин аны Йосыф абзый дип торам, Сажидә мәлгунь икән ул!

— Тәмам котны алды, мөртәт!

— Кыз түгел, егет ул Сажидә! Чын ирдәүкә!

Мондагыларның барысының да котын алган Сажидә Иосыф картның төпчек кызы иде.

Иосыф карт авылдашлары арасында үзенә аерылып тора торган бер кеше иде. Ул ел саен ашлыкны күп чәчә, ашыкмый гына эшли, чәчүгә иң соңгы кеше булып чыга һәм чәчүне иң соңга калып тәмамлый иде. Уракны тиз ура, ләкин көлтәләре бик озак җыелмый ята. Басуда көзге яңгырда калган көлтәләр булса, болар Йосыфныкы дип тәгаен әйтергә мөмкин иде. Урылмыйча ятып, терлекләр таптап бетергән ашлык та аныкы була иде.

Кызлары үсә төшкәч, инде Йосыфның басуда көлтәләре үреп ятмый башлады, шулай да ул үзе һаман да әкрен кыймылдый, бөтен эштә дә башкалардан артта кала иде. Йосыф карт моның үзенә күрә зыянын да күрә, тик артык хафаланмый иде.

— Калганын ходай кабул кылсын,— дип кенә әйтә иде.

Һәм чыннан да аның теләге кабул була кебек. Ул бераүгә дә бурычка керми, булган ашлыгын бәрәкәтләп кенә тота һәм, кышны таза гына чыгып, икмәген яңага чаклы җиткерә иде. Йосыфның калын иреннәре әледән-әле ярылгалап тора. Җәй көне ул иреннәренә кәгазь яисә яфрак ябыштырып йөри. Авыр сөякле, гаҗәеп кире беткән Йосыф авыр холыклы бер кеше булса да, үзе бик гадел иде. Аның очраган бер кеше белән сөйләшеп-гәпләшеп торырга яратуын да яхшы беләләр иде.

Йосыфның атлары да әкрен кыймылдаулары белән хуҗасына охшаганнар. Каршыга кеше очраганда кычкырып сәлам бирү белән атлар шундук туктап калалар. Әгәр Йосыф карт көн буе сөйләшеп торса, атлары да көн буе басып торырлар иде: әйтерсең, аларның ашыйсылары да, эчәселәре дә килми; чебен-черки, кигәвен тешләгәнгә дә исләре китмичә, алар сәгатьләр буе селкенмичә тик торалар.

«Аллага тапшырдык!» — дигән сүзне ишеткәч инде, ул атлар, чеңгергәнне дә, сукканны да көтмичә, кузгалып китәләр иде.

Кайвакыт Йосыф үзе өйдә калып, эшкә кызлары гына барганда да бу тискәре хайваннар ирләр сәлам биргәнне ишетүгә шып туктыйлар һәм «Аллага тапшырдык!» дип кычкырмый торып, урыннарыннан кузгалмыйлар иде.

Бу хәл Йосыфның кызларын шактый кыен хәлдә калдыргалый иде. Әгәр каршы очраучы кеше, атларның гадәтен белеп, әлеге сүзне әйтмәсә, кызлар аларны урыннарыннан кузгата алмыйча елар дәрәҗәгә җитәләр иде.

Йосыфның беренче кызы үсеп җиткәч, аларга яучылар килә башлады. Ләкин Йосыф, кызын кияүгә бирергә теләмичә, төрле сәбәпләр таба торды.

— Алай бик тиз биреп җибәрергә тавык чебеше түгел лә ул, — дип җавап кайтара иде ул.

Икенче кызына яучылар килгәч тә, Йосыф аны апасыннан узып кияүгә бирергә теләмәде. Шулай итеп, аның өлкән кызлары картая, ә кечеләре үсә торды.

Шуннан соң инде алар йортына яучылар да килмәс булды.

Өлкән кызының битенә җыерчыклар чыга башлады, аның яшьтәшләре күптән инде бала-чага үстереп, әби булырга җыеналар иде. Ул инде тормышка чыгып бәхет табудан өметен өзде, иннек-кершән дә ягынмый башлады. Йөрәгендә хисе сүнде.

Сеңелләре дә картаеп барганлыкларын сизәләр, тик бер дә үзләрен сазаган кыз дип танырга теләмиләр иде.

— Безнең әле өлкән апа да кияүгә чыкмаган,— дип, алар үзләренең әле яшь икәнлекләрен күрсәтергә тырышалар һәм, бөтен бәхетсезлекнең башы өлкән апабызда дип, аның йөрәк ярасына тоз салалар иде.

Бертуган кызлар:

— Миңа әле күптән түгел генә унжиде тулды!

— Минем апаның яше егермедән аз гына арткан,— дип бер-берен яшәртергә тырышалар иде.

Сафа, Йосыф картның төпчек кызы Сажидәне очраткач, соклануын яшерә алмыйча:

— Бөтенләй зур кыз булгансың! — дип әйтеп куйган иде.

Әйе шул, Йосыфның алтынчы кызы да үсеп буйга җиткән иде инде...

* * *

Йосыф картның кызлары турында сүз чыкканда, һәр кеше аларны «Йосыф чебиләре» дип кенә атый иде. Әмма көлеп әйтелә торган бу кушаматны Сажидәгә карата да әйтергә беркемнең дә теле бармый иде. Бөтен кеше аны башка кызлардан аерып куя. Сажидәнең «Ирдәүкә» дигән үз кушаматы бар иде.

Әгәр Йосыф карт хасталабрак торса яки вакыты булмаса, ирләр хәленнән генә килердәй эшләрне Сажидә эшли иде. Ул җир сөрә, иген чәчә, печән чаба, арбага көлтә төйи, шундый оста итеп, төйи белеп төйи, олау ава-нитә калса да, көлтәләре чәчелеп-таралып китми, аларны янадан тезеп саласы булмый. Ул кибән дә куя, әвендә ашлык та киптерә, «эһ»тә димичә, аркасына бишәр потлы капчыкларны күтәреп ташый. Аның өчен ике арбага ике ат җигеп урманга бару, атларны тимерчегә илтеп дагалатып кайту, чалгы кайрау яки урак тешәү дә гаҗәп эш түгел.

Сажидә телгә үткен, сүзгә аптырап тормый иде. Берәрсе аның ирләр эше эшләвен күреп: «Әй, чүпрәк баш!» — дип көлсә, Сажидә югалып калмый: «Синең шикелле, тузандагы таш булганчы, чүпрәк баш булу яхшырак»,— дип, теге кешенең авызын каплый иде.

Сүгенгәнгә каршы Сажидә, уйлап та тормастан, шундый ук сүз белән җавап кайтара иде.

Әгәр кызның җиккән аты, гадәтенчә, туктагач, кузгалырга теләмәсә, Сажидә монда да югалып калмый. Ул арбага торып баса да, сызгырып, дилбегәне болгап торып атның сыртына китереп суга һәм «Аллага тапшырдык!» — дип кычкырып җибәрә. Ат дәррәү кузгалып чабып китә. Сажидә рәхәтләнеп шаркылдап көлә.

Хатын-кыз эшенә дә бик уңган, бик булган кыз ул Сажидә. Өй эчендәге эшләргә дә, хуҗалык эшләренә дә, тегү-чигү эшенә дә кулы ябышып тора аның.

Әйтәсе дә юк,— шомырт кара күз, кайтарылып торган керфек, озын толым, зифа буй, алсу ирен, тезелеп киткән ап-ак теш бик сирәк кызларда гына очрый. Сажидәдә әнә шул сыйфатларның барысы да бар, өстәвенә тагы, аның шаян холкы, яңгырап торган тавышы, гомергә күңелгә кереп кала торган сөйкемле, матур күз карашы да бар.

Егетләр аның тирәсендә бөтерелеп йөриләр. Әмма ул аларның берсен дә өметләндерми, үз тирәсендә әрсезләнеп йөри башлаган егетләрне: «Беләм мин сине, юкка вакыт әрәм итеп кенә йөрисең!.. Синең ишеләрне без бик тиз бөгеп салабыз!» дип, шундук суындыра.

Андый егетләр шүрләп, кире чигәргә мәҗбүр булалар.

Сажидә аулак өйләрдә дә утырырга ярата. Анда җырлый ул, бии, гармун уйный, төрле мәзәкләр сөйли. Аулак өйдә егетләр дә булса, аларны күлкегә калдырыр өчен, ул инде бер-бер кызык уйлап чыгармый калмый.

Сажидә әнә шундый кыз булганга күрә, күп кеше эченнән: «Бусы да апалары кебек сулып әрәм булыр микән?» — дип уйлый иде.

Сажидәнең дус кызлары үзеннән:

— Син дә этнең сүзенә карап, «чеби» булып калырсыңмы икән? — дип сорагач, ул мәгънәле генә итеп көлемсерәп куя да:

— Күрербез әле,— дип җавап кайтара иде.

* * *

Сафа, су эчертергә алып төшкән атын җитәкләп, әкрен генә сукмактан менеп килә иде.

— Сафа абый! — дип эндәшкән тавыш ишетте.

Биек булып үскән бәрәңге сабакларын аралап, буразна арасыннан аңа таба җирән чәче өстеннән каешланып беткән түбәтәй кигән, зәңгәр күлмәкле, сипкелле бер малай килә иде.

Сафа туктады.

— Сине ике көн каравыллап йөрим инде, үзеңне генә туры китерергә,— диде малай, Сафага якынлашып.

Сафа малайның үзен болай тотышына бер дә гаҗәпләнмәде. Ул аның егетләр һәм кызларның ышанычлы бер кешесе икәнен, аның аркылы бер-беренә хат-хәбәр йөрткәнлекләрен белә иде.

Малай башындагы түбәтәен иплап кенә салды да, аннан бөгәрләнеп беткән берничә язу алып, Сафага бирде.

— Бусы аксак Сәләхи кызы Мәфтуха ападан, ул сәлам тапшырырга кушты. Бусы, зуррагы, Йосыф карт кызы Кәримәдән, ә менә кызыл кара белән язганын Сәлимә апа бирде.

Сафа язуларны алып чалбар кесәсенә тыкты.

— Карале, энекәш, кызларга кемнән хат яздыралар хәзер?

— Сакау Галим яза.

— Миңа да язып бирмәс микән, әйбәтрәк итеп?

— Ник язмасын, язар... Аның әзер хаты да бар, бик матур, бизәкләп-бизәкләп язган. Тик бәясе бик кыйбат...

— Күпме сорый соң?

— Унбиш күкәй!

Сафа кесәсеннән янчыгын чыгарып егерме тиенлек көмеш алды да малайга сузды.

— Күкәй бирә алмыйм, менә шушы акчаны алсын. Ә бусы үзенә,— дип, малайның кулына бакыр акча да тоттырды.

Малай акчаны учлап, җиңе белән борынын сөртеп алды да:

— Ә хатны кемгә бирим соң? — дип сорады.

— Йосыф кызы Саҗидәгә.

Малай каушап ук китте:

— Саҗидә егетләр биргән хатны алмый, ачулана, бүләкләрен дә кире кайтара...

— Ачуланмас... Минекен алыр...

— Ай-һай! Ярый алайса! — дип, малай уйлана-уйлана гына риза булды.

Шуннан соң йөгереп китеп барды. Сафа, атын җитәкләп, өйләренә таба атлады.

Сакау Галим кызларга атаган хатларын: «Күктәге йолдызым, судагы кондызым, алтын бармагым, көмеш тырнагым», дип, гел бер төрле итеп яза иде.

Хатта шигырь никадәр күбрәк һәм бизәкләре чуаррак булса, бәһасе дә шулкадәр кыйммәтрәк була иде.

Сафа укый-яза белми. Ул кызлар хатының ниндирәк эчтәлекле булуын чамалый, шуңа күрә берәрсенә биреп укытуны кирәк санамый иде. Ул хат җибәрүчеләрнең үзләрен генә күз алдына китереп уйлый иде.

Йосыф кызы Кәримә аның күптәнге танышы иде. Сафаның аны күп тапкырлар кочып сөйгәне дә бар, кызның чәченнән нинди ис килгәнен дә хәтерли. Элегрәк Кәримә авылда матур кызлардан санала иде, хәзер инде ул сулыгып, ямьсезләнеп калган. Шуңа күрә Сафаның аның белән элекке мөнәсәбәтләрне яңартырга бер дә исәбе юк иде.

Сәлимә биш ел элек кенә әле үсмер бер кыз иде. Хәзер инде ул

ары чәчле, зәңгәр күзле, сипкелле, бүкән шикелле юан бер кызга илэнгәндер. Юк, ул кыз бер дә ошамый Сафага.

Сафа солдатка киткәндә Мәфтухага күп булса унөч-уналты яшь булгандыр. Чибәр кыз булыр төсле иде. Әгәр Сафа беркөн Сажидәне очратмаса, аның ялтырап торган шомырт кара күзләрен күрмәсә, ул, әәт, Мәфтуханың хатына каршы хат белән җавап та биргән булыр иде. Ә хәзер күңелендә аның Сажидә генә иде.

## Әнә тегесен алам...

Печән өсте житеп килә иде. Йортларда чалгы кайрый, чалгы саплларын жайлый, сынган тешләрен алмаштырып, тырмалар төзәтә башладылар.

Беркөнне төш вакытында Әкрәм карыйларга Сажидә килеп керде.

— Исән-сау гына торасызмы, абыстай? — дип сәлам бирде.

Жиһан, керүчене искәрмичә, сискәнеп китте, таныгач, елмаеп:

— Уф, котымны алдың, Сажидә! Уз, уз, әйдә! — диде.

Күрешкәч, сәке читенә утырышып, дога кылып алдылар.

— Абыстай, безне доганнан калдырма инде, шушы арада басуга чыгарга жыенабыз,— дип, Сажидә Жиһанга берничә йомгак жеп сузды да янадан дога кылып, битен сыпырды.

Жиһан самавыр куярга кереште.

— Зинһар, алай мәшәкатьләнмәгез, абыстай! — диде Сажидә.

— Юкны сөйләмә әле. Әллә нидә бер киләсең. Чәй эчермичә жибәрмим,— диде Жиһан.

Самавыр кайнаган арада алар бөтен авыл яңалыкларын сөйләштеләр, Сажидәнең бала чакларын искә төшерделәр. Шул еллардан бирле кыз һаман үзенең мөгаллимә абыстаен ярата һәм хәзер дә, киңәштабыш итәсе булса, аның янына килә иде.

Сафа белән очрашканнан соң, ул, үзенең шатлыгын, шик-шөбһәләрен уртаклашырга дип, гадәтенчә, Жиһан янына килгән иде.

Алар табын жәеп утырышырга да өлгермәделәр, өске каттан шакыган тавыш ишетелде,— Әкрәм карый хатынын чакыра иде.

— Карый мәчеткә жыена, ахры. Син утырып тор, озатып килим инде,— дип, Жиһан торып китте.

Сажидә үзе генә калды. Күптән булган бер хәл исенә төште.

...Ул чакта тышта төн буе жил уйнады, күз ачкысыз салкын буран булды. Иртәнге якта гына жил тынып, күк йөзе аязып китте. Сажидә йокыдан торып, юынгач, букчасы белән китапларын жилкәсенә асты да, култыгына чи усак агачы кыстырып, Әкрәм карыйлар йортына сабакка йөгерде.

Өйләрдә мичкә яккан чак иде. Пыяла урынына карындык тарттырылган кечкенә генә тәрәзәләргә әчке яктан кызгылт ут шәүләләре төшә — мичтә дөрләп-дөрләп салам яна иде. Өйләрнең күбесен түбәләре тиңентен көрт басып киткән. Аяк астында шыгырт-шыгырт кар шыгырдый иде.

Менә хәзер Сажидә утырган шушы бүлмә,— ул чагындагы сыйныф,— кызлар белән тулган иде; өйләреннән алып килгән утын белән мичне ягып жибәрделәр. Аслыкка куйган чыра уты тоныкын кына нур сибеп бүлмә эчен яктыртып тора иде.

Сажидә чабатасын салып, карын каккалады да чөйгә элеп куйды, аннары үз урынына, тәрәзә буена, менә хәзер Жиһанның малае таралып йоклап яткан төшкә утырды. Сыйныфка абыстай килеп керде. Кызлар сәкегә, мич буена, урын житмәгәч, хәтта идән уртасына да утырдылар. Берәм-берәм Жиһан янына килеп, өйгә биргән сабакларын сөйләделәр. Һәркайсының кулында китап булса да, алар китаптан

укымыйлар, ә узган дәресне яттан сөйлиләр иде. Берәр сүзне онытып төшереп калдырсалар, абыстай әйтеп җибәрә, алдагы дәресне яхшы ятлаганнарга яңа дәрес бирә иде.

Таң атып, яктырды. Берничә кыз, ишек алдына чыгып, тәрәзәгә сыланган карны чистарттылар. Бүлмәгә тонык кына булып көн яктысы саркып керде. Чыра утын сүндереп, мичкә ягып җибәрделәр. Кизү кыз көянтә асып суга китте. Калганнары бүлмә эчен җыештырып, иртәгесе көнгә чыра телеп куйдылар, сыерга азык салып, тавыкларны ашаттылар, самавыр куеп җибәрделәр. Шул эшләрне эшләп бетергәч, уйнарга керештеләр.

Көтмәгәндә ишек ачылып, бүлмәгә ялт-йолт итеп торган кара күзле, озын буйлы бер ир килеп керде. Өстенә ул лопырдап торган озын чикмән кигән, изүе ачылып, аннан йонлач киң күкрәге күренеп тора иде.

Кызлар:

— Газиз агай килгән! Газиз агай килгән! — дип сөенешеп шаулаша башладылар.

Бөтен тирә-якка билгеле бер дивана иде бу. Үзе ул юаш, беркатлы, башкаларга да усаллык кылмый, үзен мыскыллаганны, рәнҗеткәнне дә күтәрми иде. Җәен-кышын бер үк кием киеп, Газиз авылдан авылга йөри, теләсә кайсы йортка барып керә, биргәнне ала, бирмәгәнне сорамый иде.

Бигрәк тә аны балалар һәм хатын-кызлар ярата иде. Туры килгәндә алар аны туктатып, аның белән шаярталар, аның мәгънәсез сүзләреннән һәм кыланышларыннан рәхәтләнеп көләләр иде.

Менә бүген дә балалар аңа ябырылдылар:

— Газиз агай, сиңа ничә яшь?

— Ә?.. Тугыз ике тулды.

— Газиз агай, акчаң бармы?

— Бар, бик күп... Хи-хи!..

— Акчаң кайда соң?

— Чүлмәктә.

— Чүлмәк кайда?

— Саескан койрыгы астында... Хи-хи!..

Кызлар чыркылдашып көлеп җибәрделәр.

— Газиз агай, борыныңны сөрт!

Газиз, чикмән чабуын кайтарып, эре генә кыяфәт белән борынын сөртте. Шул чак аның керләнеп каткан ялангач ботлары күренеп китте. Кызлар тагы чыркылдаша башладылар. Көлешү басыла төшкәч, шуграк кызларның берсе:

— Газиз агай, өйләнәсең киләме? — дип сорады.

— Килә... Валлаһи, килә...

— Кайсыбызны аласың соң?

Газиз кызларга күз йөртеп чыкты да, бармагы белән Сажидәгә төртеп:

— Әнә тегесен алам! — дип кычкырды.

Иптәш кызлары Сажидәне үртәргә керештеләр. Сажидә гарьлегеннән, оялуыннан кып-кызыл булды. Ул Газизгә ташланып, аны ишектән төрткәләп чыгарып җибәрергә дә җитешкән иде инде, шул вакыт кайсысыдыр:

— Абыстай килә! — дип кычкырды.

Бүлмә эче тынып калды. Кызлар китапларын тотып, быдыр-быдыр килеп сабакларын кабатларга керештеләр...

Җиһанның улы Исмагыйл елап уянуга, Сажидә әлеге хатирәләреннән бүленеп калды. Кыз аны кулына алып, юатырга тотынды.

«Әнә тегесен алам»,— дигән сүз кабат аның колак төбендә яңгырады. Әгәр шул сүзне дивана Газиз түгел, бәлки Сафа әйтсә? Ачуланыр иде микән ул аңа?

Сажидә малайны итләч тәненнән сыйпап иркәләде.

Бәлки, Газиз дә бала чагында шушының шикелле матур бер бала булгандыр... Менә бу Исмәгыйл, үсеп житкәч, нинди кеше булыр икән? Жиһан әйтә, кешенең тәкъдире үзе туганчы ук күктә язылып куелган, ди. Исмәгыйлнең тәкъдирен ничек беләсең? Ә Сафаныкын?.. Ул да Газиз шикелле куркыныч бер кеше булмасмы? Тәкъдирендә аның ни язылган? Әгәр ул да чикмән чабуы белән борынын сөртә торган булса? Аннары Сажидә нишләр?

Кыз, күңелендәге шул ямьсез уйларны куар өчен, авыз эченнән дога укып, «тфү-тфү!» — дип төкеренеп куйды. Нишләргә соң,— йөрәгендә уянган хисләренә ирек бирергәме, әллә аны хәзер үк тыярга, сүндерергәме?..

* * *

Шул ук көнне төштән соң Әкрәм карыйларга Сафа да килде, ул, карыйга биш тиен садака биреп, аны үзенең догаларыннан калдырмавын үтенде.

Сафа белән Сажидәнең, сүз беркеткән кебек, икесе бер көнне килүләре Жиһанга сәер тоелды.

«Моның берәр төрле хикмәте юкмы? Алар арасында бер-бер хәл булмаганмы?» — дип уйланды.

* * *

Печән өсте дә үтеп китте.

Кышын алган бурыч исәбенә бирише ярлылар печәннәрен муллага, биришеләре мәзингә яки Гыймадига илттеләр, берәр көн аларга эшләделәр. Урак өсте житте, яңадан бөтен авыл басуга агылды. Көннәр бик эссе иде, арышның кибеп коела башлавы бар иде.

Арыш урагының беренче атнасында ук Жиһан өмә жыярга булды. Яшьләр аларга бик риза булып киләләр, чөнки Жиһанның ашы һәрвакыт тәмле, мул була иде. Бу юлы да әйтелгән көнгә Әкрәм карыйлар өенә иртәнге чәйгә байтак кызлар, егетләр жыелды. Анда Миңлебай Сафасы белән ирдәүкә Сажидә дә бар иде.

Чәйләр эчеп, майлы бәрәңге ашаганнан соң өмәчеләр кырга киттеләр. Яшьләр жыр жырлап, гармун уйнап, көлешә-көлешә шаян сүзләр әйтешеп, Әкрәм карыйларның мари зираты буендагы жиренә килделәр.

Бу зират дигәннәре мариларның гыйбадәт кылу урыны яисә каберлекләре булгандырмы,— моны берәү дә анык белми. Хәзер инде аннан куе үлән каплаган кечкенә-кечкенә калкулыклар, ниндидер кабер ташы кисәкләре һәм артыш куаклары гына калган. Шул тирәдән узган чакта кеше яки җәнлек кыяфәтенә кереп, менә җен куды, яисә ут тавы күрдем дип карганып сөйләүчеләр дә була иде. Шул тирә халкы бу урынны сихерле бер урын дип саный иде. Бирегә бала тапмый торган хатыннарны, төзәлмәс гарип кешеләрне, авыру атларны алып килеп, аларны әфсенләү — өшкерү бик күптәннән бер ырымга әйләнгән иде.

Әкрәм карыйлар жире нәкъ әнә шул каберлек белән елга арасында иде. Биредә бу ел арыш аеруча куе, биек, эре башаклы булып уңган иде.

Өмәчеләр атларын туарып, су буена утлаурга жибәрделәр. Шаяракөлә, беләкләренә ак жиңсәләр кия-кия, эшкә керешергә хәзерләнә башладылар.

— Егетләр! Бирегә килгән-килгән, зират янында берәрсен сихерлибез! — диде егетләрнең берсе.

— Әйтегез, кызлар, кайсыгызны сихерлик,— диде икенчесе.

Гадәттәгечә, кызларның барысы өчен Сажидә жавап кайтарды:

— Карап карарбыз әле: кемне сихерләрбез, сезнеме, безнеме! — диде ул.

Икенче бер кыз:

— Чынлап, Фәхри, су буена барып, белеп кил әле: синең атың конфет ашый беләме икән? Белмәсә, сине сихерлибез,— диде.

Көлешә башладылар. Фәхри ни дип җавап бирергә белмәде, уңайсызланып дәшми калды.

— Телеңне тыя белмәсәң, шулай була ул. Оста капладымы үзенне кызлар! — дип кайсысыдыр көлеп кычкырды.

Бер-берен шулай шаярта-көлә, кызлар, егетләр, аралашып, эшкә керештеләр.

Саҗидәнең уң ягына Фәхри, сул ягына Сафа басты, ә Сафаның икенче ягында Мәфтуха иде.

Фәхри Сафаның яшьтәше иде. Бик яшьли әтисез калып, ул байтак нужа күрде, берничә ел батраклыкта эшләп йөрде. Әнисенең уңганлыгы, тапканны бик бәрәкәтләп тота белүе аркасында гына ул аякка баса алды. Байтак еллары авырлык белән дөнья күтәреп үзды. Әнисенең бердәнбер улы булганга, Фәхрине солдат хезмәтеннән азат иткәннәр, ләкин шулай да ул һаман өйләнә алмый йөри иде әле.

Ул күптәннән бирле тол Тажи белән дус, җыеннарда да гел аны яклый иде. Моның өчен авылдагы күп кеше Фәхрине яратмый иде. Шулай да Йосыф карттан бүтән берәү дә аның яучыларын кире борып җибәрмәс иде. Фәхри авылда әйбәт егетләрдән санала, төскә-биткә дә чибәр иде.

Усал телләр аксак Сәләхи кызы Мәфтуха белән Фәхри арасында нидер бар дип сөйләсәләр дә, соңгы вакытларда Фәхри күбрәк Саҗидәгә күз төшереп йөри иде. Шуңа үч итеп булса кирәк, Мәфтуха солдаттан кайткан Сафага аеруча игътибар күрсәтә башлады. Сафа исә аның бу тырышуына әһәмият итмәсә дә, Мәфтуха өметен өзми иде. Менә бүген дә ул, Сафаны үзенә җәлеп иттерер өчен, аның белән янәшә басты.

Сафаның Саҗидәне яратып йөрүен берәү дә белми иде әле. Бу нәрсә Мәфтуханың да күңелендә юк иде.

Баштарак өмәчеләр әкрен урдылар, тора-бара эшкә күнегеп китеп, чын мәгънәсендә ярыш ясадылар.

Саҗидә белән Сафа тигез баралар. Көлтәне бер үк вакытта урып, бер үк вакытта кысып бәйлиләр дә төп ягы белән җиргә утырталар. Мәфтуха да алардан калышмый. Тик аның көлтәләре бушрак бәйләнгән һәм кечерәк була иде.

Фәхри исә баштарак, Саҗидә минем оста уруымны күрсен дип, көлтәне аннан алдарак урып өлгерә, әмма кыз моны күрмәгәнгә салыша иде. Озакламый Фәхри калыша башлады.

Шунда егетләрнең берсе:

— Карагыз әле Фәхригә! Артында каравылчылар калдырып бара, үзен җеннәр алып китүдән курка, ахры! — дип кычкырды.

Чыннан да, Фәхри кишәрлегендә анда-санда урылмаган арыш башаклары калып бара иде.

— Чистарак ур, Фәхри абый, юкса шадра хатын туры килер үзеңә! — дип кычкырды Саҗидә.

Егет бу юлы да ни дип җавап бирергә белмәде. Сүзне икенче якка бору өчен, ул ниндидер кызык бер хәл турында сөйләргә кереште һәм сүз белән мавыгып китеп, уруын да онытты, башкалардан бик күп артта калды. Ул сөйләп бетергәндә төрле яктан кәҗә булып кычкыра башладылар.

— Кемнәрнеңдер кәҗәсе көтүдән калган, ахры? — дип көлеп сораган булды берсе.

— Саҗидә! Кәҗәне куып китер әле, артта калмасын! — дип кычкырды Мәфтуха.

— Фәхри дус, бүген син ипине бик зур телеп ашагансың, ахры —

урыныннан кузгала алмыйсың,— дип Сафа да сүз кыстырды. Фәхри, башын иеп, иптәшләре артыннан житешергә кереште.
Сажидә белән Сафа үз алларын бетерделәр дә, билләрен дә язып тормастан, икесе берьюлы борылып, Фәхригә каршы аның өлешен урып килә башладылар.
Ара якыная төшкәч, Сажидә:
— Фәхри абый, юл бир! Таптыйбыз! — дип кычкырды.
Фәхри оятыннан жир тишегенә кереп китәрдәй булды. Егетләрнең берсе, аны кызганган булып:
— Фәхри, синнән рәт чыкмас, ахры! Һич булмаса, Мәфтуха янына күч,— дип куйды.
Төшкә бу басуны урып та бетерделәр. Уракчылар жыр жырлап, шаяра-көлешә, Жиһаннарга кайтып тамак ялгадылар да яңадан басуга, Әкрәм карыйларның икенче басуына киттеләр.
Яшьләр арышны урып бетереп, көлтә куеп, авылга кайтканда көтү кермәгән иде әле.
Жиһанның аш бүлмәсендә тирә-күршедән жыйган, төрле зурлыктагы унлап самавыр кайнап утыра иде. Уракчылар сөт, ипи, йөзем белән чәй эчтеләр. Аннары егетләр елгага су коенырга төшеп киттеләр, кызлар кием алыштырырга дип өйләренә кайтып киттеләр.
Алар әйләнеп килүгә, тышта яшел чирәм өстенә табын әзерләп куелган иде. Барысы табын тирәли тезелешеп утырдылар. Иң элек итле тары өйрәсе китерделәр. Аннары зур агач табак белән тураган ит һәм ташаяк белән керән чыгардылар. Табынга ит белән пешергән зур-зур бәлешләр дә килде. Бу кадәр тәмле сыйны барысы да яратып ашадылар.
Иң азактан, өстенә куе каймак салып, сөзмә китерделәр. Күбесенең инде кабарлык та хәле калмаган иде.
Кайберәүләр:
— Яхшы ризык торып калганчы, яман корсак шартласын! — дип көлә-көлә, тәмле сөзмәне ашарга керештеләр.
Аннары амин тотып, хужаларга тыныч тормыш, бәхет, муллык теләп, өмәчеләр таралыштылар.
Караңгы төште.
Сафа белән Сажидә Әкрәм карыйларның ишек алдында тоткарланган булып, иң азактан диярлек чыктылар. Йосыф карт өенә чаклы икәү бергә кайттылар. Сажидә Сафаның әйтергә кыймаган теләген аңлап, тар тыкрыкка таба борылды. Шунда алар, биек эрекмән арасына кереп, үләнгә утырдылар.
Сафа белән Сажидә аулак урыннарыннан кузгалганда инде кояш чыгышы ягы агарган, өченче әтәчләр кычкыра иде.

## Илчегә үлем юк

Көз дә житте. Бәрәңге, чөгендер, кишерне казып алып, жилдә киптерделәр, базларга, идән асларына кертеп салдылар, ындыр артларында яңа ашлык эскертләре, солы, арпа кибәннәре калкып чыкты. Ашлыкны сугып амбарларга салдылар, салым түләү, йорт кирәк-яраклары алыр өчен базарга илтеп саттылар. Ирләр абзар-кураларны төзәттеләр, искергән салам түбәләрне яңа салам белән ябып чыктылар. Хатын-кыз өй жыештырды, моржа агартты, мич ярыкларын балчык белән сылап чыкты, тәрәзәгә куяр өчен яңа карындыклар әзерләделәр.
Солдатка каралган егетләр, билләренә кызыл билбау буып, муеннарына ак шарф урап, сөйгән кызлары белән аерылышасыларын белгергеп, бөтен авыл буйлап гармун уйнап, жырлап йөрделәр, кызларның йөрәкләренә сагыш салдылар.

Миңлебайныкылар йортында Сафаны өйләндерү турында сүз кузгаткалый башладылар. Кайсы кызга яучы җибәрәселәрен берәү дә әле атап әйтми, ләкин килен нинди булырга тиешлеген, кемнәр белән туганлашу яхшырак икәнлеген барысы да сөйләшәләр иде. Патый да, Вафа да умартачы кызын мактыйлар. Алар икесе дә Сафаны юан, шадра Сәлимәгә өйләндереп, умартачыны үзләренә бер таяныч итәргә, Миңлебайлар йортының элекке данын кайтарырга телиләр. Кодаларының байлыгына таянып, Вафага да авыл куштаннары арасына керергә юл ачарга хыялланалар. Ә Сафа үзенең теләгәнен әйтергә һаман кыймый йөри иде әле.

Беркөнне Әсма Патыйны үзләренә кунакка чакырды. Иң кадерле кунак алдына гына куела торган тәмле ашамлыклар белән сыйлап, чәй эчкәннән соң, Әсма болай дип сүзгә кереште:

— Малаең, аллага шөкер, исән-сау йөреп кайтты, Фатыйма җиңги. Аны башлы-күзле итәргә җыенмыйсызмы соң?

Патый мулла хатынының сүзне кай якка таба борганын аңлап җиткермәде. Шуңа күрә сагаеп кына:

— Алла боерган булса, үзебезнең дә исәп юк түгел, малаем бик уңган, бик булган, вакыты да җиткән...— диде.

— Әйе шул. Бик әйбәт егет, диләр. Әйбәт кенә кыз да табарга кирәк инде үзенә. Күздә тоткан берәр кызыгыз бармы соң?

— Хәзергә юк әле.

— Әһә, алай...— дип, Әсма үзенең әзерләп куйган планын тиз генә уйларга керешге. Әйтергә бик вакыт иде шикелле.

— Кичә без хәзрәт белән дә шул хакта сөйләшеп утырдык әле,— диде ул.— Мин әйтәм, Сәләхи кызы бик тә чибәр, бик тә тырыш кыз булып чыкты. Шуны димләргә кирәк, мин әйтәм. Аның турында бер начар сүз ишетмәссең, авылда бер дигән кыз, мин әйтәм... Мулла да шул фикердә...

Әсма әйткән кыз теге Мәфтуха иде. Кызның атасы аксак Сәләхи таза хәлле крестьян булып, бүген-иртәгә авылның куштаны булып китәргә тора иде. Мулла белән остабикә, Сәләхине Миңлебайныкылар белән туганлаштырып, аларны үз йогынтысына алырга, мәзин белән умартачы Гыймадига каршы көрәштә үзләренә корал итәргә ниятлиләр иде.

Мондый сүзне көтмәгән Патый анык берни дип тә җавап кайтармады.

— Белмим инде, билләһи, ничек булыр...— дигән сүзне генә кабатлады.

Әсма кызның уңганлыгын, булганлыгын, җитезлеген, сабырлыгын әйтеп, мактарга керешге, чибәрлеген дә әйтми калмады. Аннары Сәләхинең хатынын мактарга тотынды. Сәләхинең хатыны яхшы гаиләдән чыккан, йортны да бик тота белә, ашка-суга да бик оста, диде. Патый әгәр шундый хатынның кодагые булса, ниләр отачагын барысын да санап чыкты. Кызның бирнәсен дә әйтми калмады. Иң ахырда Әсма Сәләхинең үзен мактарга кереште:

— Алла боерса, Сәләхи кызын берсүзсез бирәчәк, шундый уңган кияүне кулдан ычкындырамы соң, җүләр түгел лә ул,— диде. Аннары, үзләренең дә бу эштә читтә калмаячакларын сиздереп:

— Мулла киңәшен дә истә тотыгыз,— дип куйды.

Патый Әсманың тәмле теленә дә бирешмәде, аның сүзенә каршы да килмәде.

— Яхшы, уйлашырбыз... Балалар ничек диярләр менә... Кызны берәү дә яманламый,— диде.

Шуның белән сүз бетеп, Патый өенә кайтып китте.

Сабирҗан мәзин, бу хакта ишеткәч, Әсманың ниндидер план корганын аңлады. Ул Әсманың Миңлебайныкыларны кем белән туганлаш-

тырырга ниятләгәнен белми иде әле, шулай да мулла хатынының бу хәлдән файдаланып, аңа каршы көрәшергә үзенә ярдәмче әзерләвен бик яхшы сизенә иде. Мәзин йоклап калмаска булды. Дөрес анысы, Сабирҗан мәзин Вафа белән Патыйның ярдәменә мохтаҗ түгел, тик шулай да аларның бөтенләй мулла йогынтысына күчүләрен теләми иде. Шуңа күрә ул Вафаны үзләренә чакырып, баллап чәй эчертте һәм үзен кызыксындырган әлеге эш турында туп-туры сүз башлады.

— Туй ясарга вакыт бит... Егетнең яше җиткәндер инде? — диде ул.

— Ярыйсы иде дә бит, мәзин абзый, менә кемнең ишеген барып ачарга белмибез әле,— диде Вафа.

— Кемгә барсаң, шул кертер. Әгәр инде үзегезнең күздә тоткан кызыгыз юк икән, ул чагында мин әйтим.

— Әйт.

— Безнең Гыймади кызының кай җире килмәгән? Үзем яучы булырмын... Бирми калмас, алла боерса.

— Ярый, сөйләшербез.

Сүз икенчегә күчте. Утырдашчылар, яңа гайбәтләрне уртаклаша-уртаклаша, бер самавыр чәй эчеп бетерделәр. Амин тотып, бит сыпырганнан соң, Вафа, хуҗалар белән саубуллашып, кайтырга кузгалды. Сабирҗан аны капка төбенә хәтле озата чыкты. Аерылышканда тагы бер кат искәртеп куйды:

— Озакка сузмагыз! Тимерне кызуында сугарга кирәк,— диде.

Иртәгесе көнне үк бөтен авылда, Сафа өйләнергә җыена икән дип, ачыктан-ачык сөйләшә башладылар. Берише кешеләр Саҗидәнең исемен телгә алдылар.

Әсма Патыйны янадан кунакка чакырып, тагы чәй белән сыйлады. Аның артыннан Сабирҗан да, Вафаны чакырып, җавабын сузмаска кушты. Хәзер инде бөтен авылның телендә мулла белән мәзиннең ярышына әйләнгән Сафаның өйләнү мәҗлесе генә иде.

Вафа өчен Сабирҗан тәкъдиме кулайрак иде. Ул, Гыймади белән мәзин ярдәмендә, бик тиз арада куштан булып китү мөмкинлеген күреп, бу тәкъдимне бөтен көче белән якларга тырышты. Патый исә, вакыты җиткәч, Вафа алардан башка да куштан булыр дип уйлый иде, шуңа күрә Шәмси мулла хатынының тәмле теленә һәм дәлилләренә ышанып, Мәфтуха бик әйбәт килен булачак, аның анасы кебек хатын кодагыең булса да бик күңелле, дип сөйләнә башлады.

Хәзер инде Сафа үз сүзен әйтергә тиеш иде. Ул кайсы якка кушылса, шул як җиңәргә тиеш иде. Бер көнне иртән чәй эчеп утырганда бу мәсьәләне туп-туры Сафа алдына китереп куйдылар. Иң элек Патый сүз башлады. Сафаны Мәфтуханың уңганлыгы, чибәрлеге белән кызыктырырга ниятләп, кызны мактап сөйләргә кереште. Аннары инде Вафа, матур сыйфатларны бик юмарт әйтеп, Гыймади кызын мактады. Сафа исә әнисе белән абыйсы сөйләгәнне башын иеп кенә тыңлап утырды да:

— Ул шадра бүкәнгә әтисе бай булганга өйләнәсем килми. Миңа Мәфтуха да кирәкми,— диде.

Патый белән Вафа бер авыздан:

— Алайса, кемне алмакчы буласың соң? — дип сорадылар. Сафа җавап бирергә ашыкмады. Ул әнисенең дә, абыйсының да үзенең теләгенә каршы киләчәкләрен белә иде. Әмма гадәттәге күндәм, юаш Сафа бу юлы үз сүзендә торырга карар итте. Саҗидә белән теләкләре уртак булуы аңа көч бирде. Күңеленнән Саҗидәгә биргән вәгъдәсен кабатлады һәм әнисе белән абыйсының бу соравына каршы:

— Йосыф карт кызы Саҗидәне алам! — дип җавап кайтарды.

Сафаның бу сүзе Патый белән Вафага яшен суккан кебек тәэсир итте. Алар аның Саҗидә белән йөргәнен беләләр, тик моңа гадәттәге бер мавыгу — шаяру дип карыйлар иде, Гыймади шикелле бай кеше

бер сүзсез кызын бирергә торганда, Йосыф карт ише бөлеп беткән кешенең кызын алуны Вафа уена да китерми иде. Ул Сафаны үзенчә күндерергә, ышандырырга кереште:

— Дөнья булгач, нинди көннәр булмас. Бай туганнарның бик кирәк булып куюы бар. Ул Иосыфның алты кызыннан гайре бер нәрсәсе дә юк бит. Уйла әле син! Шыр-ялангач булу мунчада гына яхшы ул! — диде.

Бу сүзләрнең Сафага тәэсире булмады. Ул чәен тыныч кына эчеп бетереп, чынаягын каплап куйды, чәчелгән икмәк валчыклары җыеп алып, кабып җибәрде һәм амин тотып, урыныннан кузгалгач кына үзеп әйтте:

— Әгәр син, абый, күбрәк байлыкка кызыгасың икән, ул чагында шул Гыймади бүкәнен үзеңә икенче хатынлыкка ал. Миңа Саҗидәдән бүтән берәү дә кирәкми,— диде.

Сафаны үгетләп тә, хәтта куркытып та карадылар. Аны Шәмси мулла да үз янына чакырып сөйләште, Сабирҗан да үгет биреп карады. Сафа һаман үзенекен итте.

— Әйткән сүземнән кайтмыйм. Егет сүзе бер булыр,— диде ул.

— Атаң синең бу кадәр тискәре кеше түгел иде! Кемгә охшап тугансың син? — диделәр аңа.

Сафа эндәшмәде.

Ниһаять, Сабирҗан мәзин, Миңлебайныкыларның мулла кулына төшмәячәкләрен аңлап, кул селтәде дә Сафаны җилкәсеннән кагып:

— Ярар алайса, сүзеңдә нык тор,— диде.

Вафа да энесеннән чигенде. Сафаның кирелеген җиңеп булмаячагын мулла белән хатыны да аңладылар. Патый, бер ялгызы калгач, улы белән берни эшли алмады.

Хәзер инде өйләндерү мәсьәләсен озакка сузуның мәгънәсе юк иде. Әмма алда әле аның бик кыен бер ягы бар — кызның атасы Йосыф карт белән сөйләшергә кирәк иде. Аның риза булачагына берәү дә ышанмый. Хәзер үк яучы җибәрсәң, эшне бөтенләй бозып куюың бар иде. Шуңа күрә иң элек Патый үзе ахирәте янына барып кайтырга булды.

— Атасының андый эшкә риза булырына бер дә ышанмыйм. Шулай да тәвәккәлләп карагыз. Яучы итеп берәр дәрәҗәлерәк кешене җибәрегез,— диде ахирәте.

Бу эшкә Әкрәм карыйдан да кулайрак кеше табып булмас иде. Шуңа күрә Сафа аның янына үзе барып кайтты. Әкрәм карый ризалык биреп, икенче көнне иртүк Йосыфларга яучы булып китте. Ул килгәндә Йосыф карт ишек алдында эшләп йөри иде, карыйның сәламенә каршы ачык йөз белән сәлам кайтарды да, кызларның берсенә:

— Кызым! Кунак килде. Чәй әзерләгез,— дип кычкырды.

Йосыф карт Әкрәм карыйның тикмәгә генә йөрмәвен сизде.

Хатыны белән кызлары, аның нинди эш белән йөргәнен белеп, карый белән картны тәрәзәдән күзәтеп тора башладылар. Баштарак алар вак-төяк тормыш хәлләре турында сөйләштеләр. Йосыф картның бер кызы, яулык очы белән авызын, борынын каплап, баскычка чыкты да самавыр булды дигән мәгънәне аңлатып, этисенә кул изәде. Шуннан соң Әкрәм карый белән Йосыф карт өйгә керделәр. Сәкегә табын әзерләгәннәр иде. Шакмаклы ашъяулык өстенә агач савыт белән атлан май, телем-телем итеп яңа ипи турап куелган иде. Карый түргә менеп, төрле чүпрәк кисәкләреннән җыеп тегелгән көрпә өстенә утырды. Йосыф карт, сәке кырыена урнашып, чәй ясарга кереште.

Әкрәм карый үзенең ни йомыш белән килгәнлеген берничә чынаяк чәй эчкәннән соң гына сөйли башлады. Йосыф карт күптән инде үз өендә яучы күрү өметен җуйган иде, шуңа күрә кунагы аның кызлары

хакында сүз чыгаргач, минем кызларга да күз төшерүчеләр бар микәнни әле дип, гаҗәпләнә калды.

Әкрәм карыйның Миңлебайныкылар исеменнән яучы булып килгәнлеген белгәч, Иосыф картның чырае тагы да яктырып китте. Әмма Сажидә исемен ишеткәч, карт бөтенләй каушый калды. Пөзенә кан йөгерде, куллары дерелди башлады, гадәтенчә, кәгазь кисәге ябыштырылган калын ирене ачылып китте.

Әкрәм карый җавап көтә иде.

Иосыф карт, каушавын җиңеп, болай дип сорады:

— Карый! Синең атаң әйбәт кеше иде. Син мөхтәрәм хәзрәтебезнең улы, үзең дә динне беләсең, китаплар, коръән укыйсың. Зинһар, әйт әле: биш апасын калдырып, төпчек кызны кияүгә бирергә ярый дип кайсы китапта язылган?

Әкрәм карый мондый сорауны көтмәгән иде.

— Китаплар да, коръән дә андый эшкә катнашмый, Иосыф агай! Кыз яучылау — хосусый эш,— диде ул.

Мондый җавапка картның ачуы килде. Шуннан соң карый:

— Мин сине хөрмәт итеп, үземнең тиңем санап килдем. Башка берәүгә булса, бармас та идем,— диде.

Иосыф картның чырае йомшара төште. Әкрәм карый куркынычның узганын аңлап алды, тик шулай да болай дип әйтүне кирәк тапты:

— Мин — илчемен, Иосыф агай. Картлар әйткәннәр бит: илчегә үлем юк, дигәннәр... Минем бурыч — синең җавабыңны тиешле кешеләренә кайтарып тапшыру.

— Тавык чебиен дә тиктомалга чыгарып ташламыйлар. Ул да җан иясе бит... Кешеләр өчен кыз бала тавык чебиеннән дә кадерсезрәк, күрәсең,— дигәндә Иосыф картның тавышы калтыранып китте.

## Хурлыгы әтигә булыр

Биек-биек ярлар, агач коймалар буена җил-буран киртләч-киртләч кар көртләре өеп китте.

Ярлы өйләрдә көндезен — карындыклы кечкенә тәрәзә өлгеләреннән саркып кергән тоныкк кына көн яктысында, озын кичләрне — пыскып янган тычкан уты яктысында — мәзингә чыпта сугалар. Кызлар станокта мулла хатыны өчен сөлге, ашъяулыклар әзерлиләр.

Иосыф карт Миңлебайлар яучысын кире борып җибәргәннән соң, Сафаның өйләнү мәсьәләсе хәзергә калып торды. Шул мәсьәлә тирәсендә мулла белән мәзин арасында яңадан көрәш башланды. Әмма Сафа ниятеннән кире чикмәде. Сажидә белән арасын өзмәде.

Бер көнне Иосыф карт калага солы сатарга киткәч, кызлары аулак өй ясарга булдылар. Кич җиткәч, өй эче кызлар белән тулды. Һәркайсы үзенең эшен алып килгән — кайсы тегеп бетерәсе күлмәген, кайсы чигеләп бетмәгән алъяпкычын, кайсы киерге белән палас алып килгән. Беришеләре башлаган бәйләүләрен яисә бәйләү башларга җеп алып килгәннәр иде.

Өй хуҗалары да эшсез утырмадылар. Ишекнең ике ягына ике туку станогы куйдылар. Мич буендагысына Кәримә утырып, шакмаклы ашъяулык тукырга кереште. Ян тәрәзә буендагысында Сажидә кичә башлаган чупләмле сөлгесен эшли иде. Аңа энисе булыша. Өлкән кызлары тукыр өчен буй сару калыбына җеп чолгый. Өйдә ике лампа янып тора. Кызлар, һәркайсы үз эшенә бирелгән хәлдә, моңлы бер көйгә сузып җыр җырлыйлар иде. Беренче булып Кәримә сүз башлады:

— Нигә болай җебем өзелә, мин әйтәм, бактым исә: сусамның өчы ярылган икән. Җафаланып беттем! Сажидә, акыллым, шушыны юынып кына бирче.

Сажидә, торып, әтисенең чәч китәрә торган пәкесен алды да сусаны юынырга керепте. Эшсез калган Сылу өй алдыннан әвернә тактасы алып керде, идән уртасындарак утырып, киләпне сүтеп чолгарга тотынды.

Эшләре бер дә алга бармый иде. Шуннан соң сөйләшә, шаярыша-көлешә башладылар, табышмак әйтештеләр, аннары такмак әйтештеләр, әкият сөйләделәр. Гармун уйнап, җырлап тәрәзә төбенә егетләр килде. Кызлар аларга ымлап кына Сылуның әле йокламаганлыгын аңлаттылар. Шуннан соң егетләр тындылар.

...Озакламый Сылу киләпне сүтеп бетерде дә, тәмле итеп иснәнә-иснәнә:

— Балалар, бик шауламассыз инде, озак утырмагыз, лампаларның кәрәчине әз,— дип, мич башына менеп китте.

Бераздан, аның йоклавын белдереп, каты гына гырлаганы ишетелде. Кызлар эшләрен ташладылар. Күңелле ыгы-зыгы башланды. Башта шырпы чөеп уйнадылар. Әйбер эзләгән булып, бер-берсенең битенә корым сөрттеләр. Аннары «Кем сукты?» уенын уйнарга керештеләр. Монда иң күп эләккәне Сажидәгә булды, хәер, ул үзе дә бурычлы булып калмады. Ул һәрбер «гөрләү»чөнең аркасына шап иттереп китереп суга. Ә тегесе: «Ай, авырттырды! Сажидәдер бу!» — дип, танып ала да аны аркасы белән идереп, бар көченә дөпелдәтеп суга иде.

Аннары барысы сәкегә ятып, бишмәт җиңе аша йолдыз карадылар, битләрендәге корымны тагы да җәя төшеп, су бөркештеләр.

Аулак өйдә иң кызыклы уен — шамакай уенын Сажидә башлап җибәрде. Ул мич артына кереп, шамакай булып киенде дә әкрен генә атлый-атлый идән уртасына чыкты. Башына яулык өстеннән иске бүрек кигән, бүрек өстеннән ертык җилән бөркәнгән, корсагына сөлге белән зур мендәр бәйләгән. Кашларын куе итеп күмер белән каралткан, битләренә җыерчыклар сызган, кулына озын табагач тоткан иде. Бу чын Сажидә түгел, бәлки нинди дер ямьсез, коточкыч бер нәрсә иде.

— Кем син? Каян килдең? — дип кычкырдылар кызлар.

Сажидә тешен ыржайтып, телен чыгарып, әкрен генә иреннәрен ялап алды да ямьсез итеп, усал итеп акайган күзләре белән барысына да карап чыкты һәм сакауланып:

— Минем йортым — кара урман, минем ирем — урыс, исемем — Шамакай.— диде.

— Кая барасын?

— Бала табарга җылы урын эзлим.

— Баланның атасы кем?

— Белмим, бик күбәү алар.

— Кайсы мулла никахлады сезне?

— Урмандагы аю.

— Баланның кендеген кем кисәр?

— Убырлы карчык.

— Ник болай йөрисең? Иргә чык.

— Минем каккан казыгым да юк. Барлык сакаллы ир-ат — минем ирем, бөтен дөнья — минем илем, кара урман — торган җирем... Башыгызда тырнак очы кадәр генә дә акылыгыз булса, миңа иярегез, сылуларым.

Җен кызының өстенә йон йомгаклары очты. Кызлар аны кулларына ни эләксә, шуның белән: бөтереп ишкән сөлге, җеп йомгаклары, мендәр, чабаталар белән дөмбәсләргә керештеләр. «Шамакай», чинап-ынгырашып, суктырмаска тырышты һәм ахырда, ике кулы белән эчен тотып, мич артына кереп китте.

Бу шау-шуга Сылу йокысыннан уянып:

— Ятыгыз инде, кызлар! Җитәр, уйнап туйгансыздыр! — диде.

— Хәзер, әни,— диде Сажидә.

Кызлар тиз генә өй эчен жыештырып, битләренә буялган корымны юдылар. Өйдә булган бөтен кием-салымны, эрләргә дип әзерләнгән йон, сүсне сәкегә салып, шуның өстеннән ак киез җәйделәр. Урын әзер булды. Барысы да бергә тезелешеп ятарга жыена башладылар.

Шул вакыт әкрен генә тәрәзәгә чирткән тавыш ишетелде. Сажидәгә өлкән апасы:

— Бар! Солдатың килгән, ахры,— дип пышылдады.

Сажидәнең апалары аның бәхетеннән беркадәр көнләшәләр, ләкин ана начарлык теләмиләр, киресенчә, ярдәм итәргә генә торалар иде. Әтиләре Сафаның яучысын кире борып жибәргәннән соң, алар Сажидәгә тагы да игътибарлырак була башладылар. Аны кызгансалар да, Сажидә кияүгә чыга алса, әтинең яучыларны кире борып жибәрергә төп сәбәбе калмас дип өметләнәләр иде. Хәтта яше утыздан узган иң өлкәне дә күңеленнән кияүгә чыгу хыялына бирелгәләп китә иде. Хәзер дә ул:

— Бар, бар! Сафа дәшәдер...— дип, Сажидәгә теләктәшлек итеп баш какты.

Сажидә, әнисенә сиздермәс өчен, күлмәкчән генә тышка чыгып китте, баскычта туктап, як-ягына каранды.

Инде төн уртасы житкән иде. Биек, аяз күктә йолдызлар жемелдәшә. Кар, тузан кебек бөтерелеп, өй нигезенә сырыша иде.

Өй чатыннан карамчык бер шәүлә килеп чыгып, сакланып кына баскычка таба атлый башлады. Сажидә әкрен генә тамак кырды. Карамчык кызурак килә башлады. Кыз, баскычтан сикереп төшеп, Сафаның кочагына килеп керде. Егет аны киң тун чабулары белән әйләндереп төреп алды. Бер-беренә сыенышып, дөньядагы бар нәрсәне онытып, берничә минут тын тордылар.

Ах, бу үз киресенә каткан Йосыф карт булмаса! Мулла белән мәзин, умартачы кызы Сәлимә, куштан кызы Мәфтуха булмаса! Үз сүзле Патый белән комсыз Вафа булмаса!

— Үз теләгебезгә ирешергә бирмәсләр микәнни алар безгә? Берберебезне сөеп яшәргә язмаган микәнни безгә? — ди Сафа, пошынып.

Сажидә бу хәл белән килешергә теләми. Ул үзенең көченә ышана:

— Әти каладан кайткач, әвенгә ягачак. Синең вакытың буш, кил дә тагы бер тапкыр сора. Мин дә сөйләшермен.

— Шуннан?

— Шуннан соң да ризалык бирмәсә, үзенә үпкәләр...

Сафа моның мәгънәсен бик тиз аңлап алды һәм дулкынланудан йөрәге типкән хәлдә:

— Нишләмәкче буласың? — дип сорады.

— Киемнәремне төйним дә сезгә киләм... Хурлыгы мина булмас, әтигә булыр... Кире куып җибәрмәссез бит?

Сафа аны каты итеп кочып, иреннәннән үпте.

* * *

Өй түбәләренә тия язып, күктән авыр кар болытлары агыла. Аратирә шул болытлар арасыннан кызгылт кояш нурлары ялтырап китә. Озакламый буран кузгалырга җыена иде.

Сафа, өстенә иркен тунын киеп, беравык капка төпләрендә уйланып басып торды, аннары якындагы тыкрыкка борылып, ындыр табагына китте. Йосыф карт әвенennән бөтерелеп төтен чыга иде. Сафа әвен янына килде. Әвен ишегенең бер ягы ачык иде. Сафа шунда «Керимме, юкмы?» — дип икеләнеп калды. Аннары, тәвәккәлләп, ишектән атлады да төтен болыты эченә килеп керде.

Башта төтен әчесеннән күзен ача алмый торды, аннары тонык кына елтыраган ут яктысы күрде. Сафа утка таба атлап, базга күз салды.

Базда нарат тамырлары, коры-сары ботак өстендә киндер күлмәктән Иосыф карт утыра иде. Мичтән ялкын телләре сузылып, шуларның очыннан бөтерелә-бөтерелә төтен күтәрелә. Башаклары белән утка таба салган солы көлтәләре чытыр-чытыр итә иде.

Сафаның күз алдына Шәмси мулла вәгазьләрендә сурәтләнгән тәмуг күренеше килде. Иосыф карт үзе шундагы тәмуг капкасын саклаучыны хәтерләтә иде.

Сафа: «Баздан чакырып чыгарыргамы, әллә үзе чыкканны көтәргәме? Ничек итсәм, яхшырак булыр?» — дип уйланып торганда, Иосыф карт урыныннан кузгалып, кышкы йокысыннан буленгән аю шикелле мүкәйләп, өскә менә башлады. Сафа ихтыярсыздан бер читкәрәк тайпылды.

Карт, баздан чыккач, Сафага әйләнеп күз дә салмады. Әвен өстенә куйган озын нарат колганы уң кулы белән әкрен генә тартып алды да сул кулы белән бер башыннан икенче башына таба капшап бара башлады. Бу нарат колгасы әвен эченең күпме кызганлыгын чамалый торган термометр сымак бер нәрсә иде. Иосыфка әвен эче җитәрлек кызган, эссесе тигез булып күренде, ахры. Таякны кире урынына куйды да яңадан төшмәкче булып баз читенә килде. Карт базга аягын сузам дигәндә генә Сафа кычкырып сәлам бирде һәм аңа таба атлады.

— Кем бу?

— Мин идем, Иосыф абзый... Миңлебай Сафасы.

— Ни кирәк?

— Тыңласаң, йомышым бар иде сиңа.

Иосыф карт Сафаның ни йомыш белән килгәнен сизде. Беравык дәшми генә үз алдына карап торды, аннары ашыкмыйча.

— Һе, алай... әйт соң йомышыңны...— диде.

Киң ыштан бөрмәсеннән ниндидер бер әйбер алды һәм, Сафаны тыңларга әзерләнеп, янып торган мич катына чүгәләде. Сафа да аның янына урнашты. Ул сөйләгән чакта Иосыф карт кулындагы әйберсен искиткеч бер акрынлык белән әйләндергәләп торды. Бу — матур гына юнылып, кулда йөри-йөри шомарып беткән куыш агач тамыры булып, аның нечкә башы тишелгән, шуңа бөке тыгып куелган иде. Тәмәке савыты булып хезмәт итә иде ул. Карт аның бөкесен алды, сул кулының баш бармагы тырнагы өстенә ипләп кенә бер чеметеп тәмәке салды һәм тәмәке савытын яңадан ыштан бөрмәсенә кыстырып, Сафаның сөйләп бетергәнен көтә башлады.

Ниһаять, Сафа сүзен әйтеп бетерде.

Иосыф карт, баш бармак тырнагын борын төбенә китереп, тәмәкене исни-исни:

— Алай, алай,— дип куйды һәм бик кәефе булган бер кыяфәт белән каты итеп төчкереп җибәрде.

— Сәламәт булыгыз! — диде Сафа.

Карт тагы төчкерде, аннары башын читкә борып, борынын сеңгерде һәм җиң очы белән әйбәтләп борынын сөрткәч кенә басынкы бер тавыш белән сүзгә кереште:

— Эх, энем! — диде — әгәр бу сүзне миңа синең урында башка берәү сөйләсә, мин аның кабыргаларын санап җибәрер идем. Акыллы егет син, сүзгә дә оста! Була торган булса, мин сиңа бер кызымны гына түгел, өч кызымны бирел җибәрер идем. Әмма син булмастайны сорыйсың. Карт көнемдә мин үз өстемә андый эш башлауны ала алмыйм. Йортыма яучы да җибәрмә, бу турыда бүтән сүз дә чыгарма. Мин сүземнән кире кайтмыйм.

Бу кадәр тискәре картны үгетләп маташуның мәгънәсе юк иде. Шуңа күрә Сафа китәргә кузгалды. Иосыф базга төшеп китте.

Шул көнне үк Сафа теге сипкелле малай аркылы Сәҗидәгә әтисе белән сөйләшүнең нәтиҗәсе булмавы турында хәбәр иттерде.

* * *

Иртәгесе көнне Йосыф карт әвендә киптергән солыны бергәләшеп сугып бетерделәр. Төштән соң карт өйгә бер кочак юкә кертеп, тар гына тасмаларга телде дә чабата ясарга утырды.

Кич житеп килә иде. Сажидә әйбәт күлмәген киеп, башына зур француз яулыгын бәйләде. Өйдә үзенә урын таба алмыйча әрле-бирле йөрде. Мич тирәсендә кайнашкан икe апасы Сажидәнең нинди хәлдә булуын күреп, дәшми генә ни буласын көтә башладылар.

— Әти! — Сажидә үз тавышыннан үзе сискәнеп китте.

Әтисе, башын күтәрмичә генә:

— Ни әйтмәкче, кызым? — дип сорады.

— Синең янга кичә Сафа килдеме?

Йосыф карт дулкынланган Сажидәгә ялт кына күз төшереп алды, дәшмәде.

Сылу белән башка кызлары авыз ачарга да куркып торалар иде.

— Я, килде... Анда синең ни эшең бар? — диде карт, ниһаять?..

— Эшем юк. Тик әйт әле: аңа син ни дип җавап бирдең?..

— Минем ни дип җавап бирүемдә синең ни эшең бар? Әллә оятыңны җуйдыңмы, атаң белән кияү хакында сөйләшмәкче буласыңмы?.. Чыгып кит моннан!.. Күземә күренәсе булма. Минем сиңа да, Сафаңа да көчем җитәр...

Кыз урыныннан селкенмәде дә. Сак булырга кирәклекне бөтенләй онытып, тагы телгә килде:

— Әнә синең аркада апаларым кибеп-корып беттеләр инде!.. Синең кирелегең аркасында!.. Мин алар шикелле булырга теләмим, теләмим!..

Сылу, Йосыфның калып алырга үрелүен күреп, Сажидәне ишеккә таба этеп җибәрде. Кыз, исенә килеп, ялт кына өйдән атылып чыгып китте. Авыр агач калып ябылып өлгергән ишеккә килеп бәрелде.

— Ах, оятсыз! — дип кычкырып калды Йосыф карт. Аннары бөтен ачуын хатыныннан алырга керешге:

— Син балаларга тәрбия бирә белмәдең! Син аларны сүз тыңламаска өйрәттең, кызларны син узындырдың! Оят, хурлык!! — дип тузынды.

Сылу:

— Атасы, Сажидәнең нindиleгeн беләсең бит! Бөтен халык алдында хур булмыйк,— дип әйтеп караса да, карт дулавын гына белде. Сылу өстенә зур агач табак, чабата калыплары очты. Үз гомерендә мондый әйбер атуларны байтак күргән хатын тиз генә мич артына кереп качты.

* * *

Сажидә, өйдән исән-сау чыгып качкач, бер әйберсез Миңлебайларга барып керергә яхшысынмады. Аның хәлен аңларлык бердәнбер кеше Җиһан гына иде, ул Җиһаннар йортына барып кына кеше гайбәтеннән качып калачак иде. Кыз шунда китте.

Җиһан, әле яңа гына бер кичке намазны укып бетереп, намазлык өстендә, икенче намазга керешер өчен кояш баеганны көтеп, тәсбих тартып утыра иде.

Вакытлы-вакытсыз, шушындый каты салкында күлмәкчән килеп кергән Сажидәне күргәч, ул борчыла калды. Исәнләшү белән үк:

— Бер-бер хәл булдымы әллә? — дип сорады.

Сажидә «юк» дип әйтә алмады, җавабы бугазы төбендә утырып калды, күзләренә яшь төелде, һәм ул үкереп елап җибәрде.

Җиһан каушап калды. Сажидә янына йөгереп килеп, ике куллап аның башыннан кочты да ябык күкрәгенә кысып, чәченнән сыйпарга керешге.

— Абыстай, жаным, нишлим икән? Хәзер миннән бөтен кеше көләчәк бит...— диде Сажидә, яшьләренә буылып.

— Елап кайгыңны жиңеләйтә алмассың...— Жиһан һаман да кызның ни сәбәптән елавын аңлап житми иде әле.— Әйт әле, ни булды? Хәлемнән килсә, ярдәм итәрмен...

Өй эченә кичке караңгы иңә башлады. Жиһан намазын бөтенләй онытты. Әллә елап кайгысы жиңеләйде, әллә абыстаеның ягымлы, йомшак итеп башыннан сыйпавына тынычлана төште,— Сажидә әкренләп хәлгә килде.

— Әти мине Сафага бирергә теләми... Мине дә апаларым шикелле харап итмәкче була... Миңа бер генә чара кала: Сафага ябышып чыгам.

— Үзең белгәнчә эшлә инде... Берничек тә киңәш итә алмыйм сиңа, балам,— диде Жиһан.

Сажидәгә киңәш кирәкми иде инде. Сафага ябышып чыгам дип карар кылган иде ул. Тик качып чыккач, азгын кыз дигән исемне күтәрүе генә авыр иде. Шуны уйлагач, гарьлектән күзләренә яшь килә иде. Шулай да сөйгән егетенә чыкмый калып, апалары шикелле картаеп сулуга караганда теләсә нинди хурлыкка да түзү жиңелрәктер кебек иде.

Берәр сәгать вакыттан соң Әкрәм карыйларга, сеңелесен эзләп, Кәримә килеп керде.

— Хәзер нишлисең инде? — дип сорады ул.

Сажидә катгый итеп өзеп әйтте:

— Бишмәтем белән әйберләремне төйнәгән төенчегемне китер. Төенчегем чормадагы кәрзин эчендә. Кара аны, әти сизмәсен,— диде. Һәм өстәп:— Башкаларга сабак булыр... Хурлыгы әтигә булыр!..— диде.

## Туй

Миңлебайныкылар йортының капка-ишекләре бикләнмәгән әле. Сәке түрендә Зөһрә карчык, аякларын бөкләп, бөртекләп-бөртекләп кенә тәсбих тартып утыра. Аның янында Вафа балалары тәгәрәшеп йоклап яталар. Сәкенең ике кырыена урын җәеп куелган.

Вафаның хатыны мич янында зур гына жилпучка он или. Патый чыра телә. Вафа, бер аягын сәкедән салындырган килеш, икенче аягының тырнакларын кисә. Ә Сафа сүзсез генә, ишек катындагы бүкәндә утырып тора, ул нидер көтә иде шикелле.

Тышта шыгырдап ян капка ачылганы ишетелде. Берәү тиз генә тәрәзә буеннан узып, ашыга-ашыга өй алдына керде. Сафаның йөрәге катырак тибәргә тотынды, битләре кызышып яна башлады.

— Хәерле кич!

Тикмәгә көтмәгән икән Сафа: Сажидә иде бу. Сафа бүкәннән сикереп торды да бер кулы белән Сажидәнең беләгеннән тотты, икенче кулына аның төенчеген алды.

— Менә килдем,— диде Сажидә, тынлыкны бозып.

— Бик әйбәт иткәнсең.

Сафа, аптырашып калган туганнарына таба борылып:

— Менә сезгә яңа килен булыр бу!..— диде.

Вафаның хатыны, башын кашып куеп, читкә борылды да, тагы да тырышыбрак, бүленеп торган эшенә керешә. Вафа, әкрен генә аягын идәнгә төшереп, әнисенә текәлде. Патый, пычак, чыралык агач һәм чыраларны кочагына җыеп, мичкә таба ташлады, кулларын корсагына кушырып, ике бил кырыеннан бөрелеп төшкән алъяпкыч итәкләре белән каплады да тыелып кына:

— Хәерле сәгатьтә, хәерле сәгатьтә! — диде һәм шундук тавышын үзгәртеп:— Картлык көнебездә безне хур итмәкче буласызмы? Йосыф

абзыйны әдәм көлкесенә калдырдың... Бөтен нәселебезне хурлыкка калдырасың! — диде. Соңгы сүзләрен ул Сафага әйтте.

— Ярабби, мәрхәмәтеңнән ташлама! — дип куйды Зөһрә карчык.

Патыйга һәм Вафага бу хәл белән килешүдән башка чара калмады. Әмма халык арасында гайбәт сүзе таралудан ничек котылырга соң?

Туган-тумача, бергә җыелышып, бик озак киңәштеләр. Ахырында Сафа, Сажидәне иртәгә чаклы Җиһаннарда торып торырга күндереп, шунда илтеп куйды.

Миңлебайныкылар белән Йосыф карт йорты арасында тыз-быз хәбәрчеләр йөри башлады.

Җиде төн уртасында, бөтен авыл йоклап беткәч, Сажидәнең язмышы хәл ителә. Моның хурлыгыннан ничек котылу хакында да киңәш алып баралар иде. «Ирдәүкә» Сажидә түземсезләнеп сөйләшүләр беткәнне көтә иде.

Йосыф картны үгетләп тә, хурлыгы нинди бит, дип куркытып та карадылар. Кире беткән карт үз сүзеннән чигенергә теләмәде.

Ахырында ул, Сафаны бу уеннан кайтарырга кирәк, дип мыгырдаңып куйды.

Патый белән Вафа бер авыздан:

— Безнең сүзне ишетергә дә теләми ул! — диделәр. Карт ышанмады.

Ахырында Патый, ачуы килеп:

— Менә үзең кызыңны җиңә алмагансың ич әле! — дип кычкырды.

Каршы килерлек урын калмаган иде. Йосыф эндәшмәде. Бүген берәү дә аны тыңларга да, аңларга да теләми иде. Хәтта ничә ел бергә гомер иткән Сылуы да, ачыктан-ачык Сажидәне яклап, иренә каршы төште... Бу хәлгә шаккатарлык кына иде.

— Муеннары белән чәнчелеп, җәһәннәмгә олаксыннар! Моннан ары бер нәрсәгә дә катышмыйм. Теләсәгез ни эшләгез! — диде карт ачу белән.

Үз башына гөнаһ алмас өчен, кеше күзенә күренмәс өчен, ул иртүк торып, карт җирән биясен җикте дә солы төяп калага китте, хатынына, өч-дүрт көнсез кайтмам, дип әйтеп калдырды.

Иртәгесе көнне иртән Сафа Җиһаннарга Сажидәнең хәлен белергә килеп, картларның эшне ничек хәл иткәнлекләрен әйтте. Озакламый Кәримә килеп, Сажидәне үзләренә алып китте. Патый төш җиткәнче үк ахирәте янына барып, туй итү хакында сөйләште.

* * *

Йосыф карт каладан кайтканчы бөтен мәшәкатьләрне бетереп, яшь киленне кияү йортына төшерү өчен, туйны икенче көнне үк ясарга булдылар: Йосыф картның холкын белмәссең, әллә нинди көтелмәгән хәлләр китереп чыгаруы бар иде.

Мәһәрнең күләме, бүләк-санак, ничә пар кунак чакыру хакында төгәл генә сөйләшергә вакыт та булмады. Бу юлы инде вак-төяк өчен сатулашып тормадылар: ике як та бик тиз килештеләр. Ахирәт дуслар кайнап торган самавыр янында барлык туй мәшәкатьләрен сөйләшеп хәл иттеләр. Сылу хәзинәсендә булган барлык нәрсәсен әзерләргә, Патый исә аңа ярдәм итәргә булды.

Иртәгесе көнне өйлә вакытында Миңлебайлар йортына кызның туганнары кодаларын алырга җибәргән җигүле атлар килде. Озакламый киенешеп-ясанышып чаналарга утырган кодалар урау юллар белән Йосыф карт капкасы төбенә килеп туктадылар.

Кодалар өйгә кереп, йорт эче тулы кунакларга вәкарь белән генә сәлам бирделәр:

— Исәнмесез, кода! Исән-сау килеп җиттегезме?

— Ни хәлләрдә яшисез, кодагый?

— Шатлыклы туй белән котлыйбыз сезне!

Шуннан соң мулла белән мәзинне алырга ат җибәрделәр.

Шәмси мулла, өйгә килеп кергәч, шундагы халыкка сәлам биреп, шатлыклы көн белән тәбрик итте һәм бик эре генә итеп түргә менеп утырды.

Кыз ягыннан вәли-вәкил итеп Иосыфның энесе Ильяс чакырылган иде.

Ул, йоланы башларга вакыт икәнен белдереп:

— Кунаклар килеп бетте, мулла абзый,— диде.

— Кияү ягыннан кем вәли-вәкил? — дип сорады мулла.

— Мин,— диде Вафа.

Мулла, кунакларга күз йөртеп, чак кына көлемсерәде дә:

— Бирелә кызның атасы күренми икән,— дигән булды.

Ильяс ашыгып кына:

— Абзый калага киткән иде, кайтып өлгермәде... Шул сәбәпле вәли-вәкил булуны миннән үтенделәр,— диде.

Кунаклар күзгә-күз карашып алдылар.

— Яхшы алайса. Күпме мәһәр сорыйсыз? — диде мулла.

— Егерме сум көмеш.

— Тулысынча алдыгызмы?

— Тулысынча, тулысынча!

— Кыз ризамы?

— Риза!

Кунаклар елмаешып куйдылар.

— Ул чагында керешәбез,— диде мулла.

Кулларын тез өстенә салып, күзен йомды, йөткеренгәләп, тамак кырып алды да гарәпчә коръән сүрәсен укый башлады. Кодалар, кунаклар тын да алмый тыңлап утырдылар. Кызларның җыелып торган ситсы чаршау артыннан гына ара-тирә чулпы тәңкәләре чыңлаштырганы ишетелеп китә иде.

Мулла укып бетерде дә, тавышын үзгәртеп, татарча:

— Син, хөрмәтле Ильяс агай, Иосыф кызы Сәҗидәне Салих улы Әхмәтсафага пәйгамбәребез Мөхәммәт кушканча егерме сум көмешкә риза булып бирдеңме? — дип сорады.

— Бирдем!

— Син, хөрмәтле Вафа агай, Иосыф кызы Сәҗидәне Салих улы энең Әхмәтсафага хатынлыкка риза булып алдыңмы?

— Алдым!

Шуннан мулла тагын коръән укыды. Барысы да дога кылдылар. Егет белән кызның туганнары муллага, мәзингә һәм Әкрәм карыйга садакалар бирделәр. Хатын-кызлардан берәү ширбәт салган кувшинны тотып, кияү янына никах беткәнлеген әйтергә йөгерде.

Ашарга китерделәр. Сабирҗан мәзин гадәтенчә кунакларга аш бүлде, бәлеш турады, Сылуның аш-суга осталыгын мактый-мактый, бик тырышып кунакларны сыйлады. Аштан соң, яшь кияүләргә тыныч, бәхетле тормыш теләп, өйләренә таралыштылар. Аннары ирләр урынын хатыннар алдылар. Аларга да аш ашатып, чәй эчерттеләр. Бигрәк тә Сәҗидәнең апалары тырышып йөрделәр. Алар үзләрен үз туйларындагы кебек хис иттеләр.

Туй үпкәсез булмас, ди мәкаль. Ләкин бу юлы алай булмады.

Кич белән Иосыф карт йортына, никах түшәге әзерләү һәм киендерү өчен Сәҗидәнең дус кызлары җыелды. Дөрес, кызның туй өчен дип атап тектергән күлмәге дә, яңа түшәге дә юк иде, шулай да барысы да йола кушканча әзерләнде, Сәҗидәгә иң яхшы киемнәрен кидерделәр. Сәкегә йомшак түшәк җәеп, яшь кияүне алырга ат җибәрделәр.

Бу вакытта Миңлебайлар йортында яшь кияүне кыз янына озатырга әзерлиләр иде. Егетләр Сафаны бәйрәмчә киендереп, биленә кызыл билбау будырдылар, билбау очларын, кыз чишә алмасын дип, суга чылатып, бик каты төйнәп-төйнәп эчкә яшерделәр. Караңгы төшеп, күз

бәйләнгәч, көтелгән ат килеп житте. Кунаклар ашадылар, эчтеләр, яшь кияүне алмага килгән кучерны сыйладылар һәм, ниһаять, юлга җыендылар. Иң беренче булып ишеккә Сафа китте.

— Улым, кара аны, йоклап торма, хатының аягыңа басмасын! Бүрегеңне да сакла, башыңнан алып кимәсен! — дип калды Патый.

— Безнең солдат үткен ул, бирешмәс! — диде кайсыдыр.

Борыннан калган ышану буенча, әгәр кыз беренче кавышканда иренең бүреген алып башына кисә яки аягына басса, семьяда ул баш булып, ирне үз кулында тотачак, имеш. Шуңа күрә ир моңа юл куярга тиеш түгел. Шулай да, әгәр кыз алай эшли калса, егет, ырымны кайтарыр өчен, шундук хатынына сугарга тиеш.

* * *

Йосыф картларның ишек төбендә бер малай басып тора иде. Малай Сафаны җыр такмаклап каршы алды. Сафа аңа акча тоттырды. Шуннан малай ишекне ачты. Сафа, дога укып, бусагадан эчкә узды.

Мунча кебек эссе итеп ягылган өй эче буп-буш иде. Кучкарда Әкрәм карыйлардан алган бишле лампа янып тора иде. Ситсы чаршау артыннан Сажидә йөгереп чыкты. Күрештеләр. Яшь кияү тиз генә ишек катындагы бүкәнгә утырды да хатынына аякларын сузды. Сажидә ике куллап аның итекләрен салдырды. Кияү бүкәннән тора башлауга, кыз аның бүрегенә үрелде, ләкин Сафа йоклап калмады, шундук кызның кулын читкә этеп җибәрде. Бүреген үзе салып, чөйгә элим дип борылуга, чая кыз аның аягына китереп басты. Сафа, җиңелеп каласы килмичә, Сажидәнең яңагына сугып алды.

Сажидә рәнҗемәде моңа: ырымы шундый икәнен белә иде ул. Тиз генә Сафа янына килеп, билбавын чишәргә кереште. Чиләндереп бетергән төенне кулы белән генә чишә алмаслыгына ышангач, нелде дә, тешләре белән йолыккаларга тотынды. Кыз билбауны тиз генә чишеп ташлап, бик канәгать төс белән, сәке почмагына ыргытты.

Намазлыкка икәү янәшә басып, намаз укып алдылар һәм әзерләп куйган табынга килеп утырдылар.

Яшь кияүләрнең булышчысы итеп куелган күрше хатыны, өйгә кереп, тирәли күз йөртеп чыкты. Бөтен нәрсә үз урынында икәнен күргәч, кияү белән кызның икесен генә калдырып, чыгып китте.

* * *

Иртән торгач, Сафа урынын җыярга киләсе кызлар өчен дип, мендәр астына бер сум көмеш куйды. Кияү белән кыз мунчага киттеләр. Сафа анда да тәрәзә төбенә бер сум акча куйды. Чәй янына күршеләрдән кайнар коймак керттеләр. Тәлинкәне хуҗаларына, бер сум көмеш салып, кире кайтардылар. Яшь кияүләрне күрергә килүче кунакларга да бүләкләр тиде. Кич кырын Сафа яшь хатынын үзләренә алып китте.

Миңлебайларның өй эче тулы хатын-кыз иде. Яшь кияүләрне каршы алырга җыелганнар иде алар.

Бу туй әнә шулай бернинди үпкә-талашсыз узды. Йосыф картның төпчек кызы, биш апасын калдырып, кияүгә чыгып китте.

— Менә туй итеп күңел дә ачтык!

— Сажидәне бөтен шартын китереп кияүгә бирдек! — диде дуслары.

— Миңлебайлар солдаты Йосыф картның төпчек кызын ябыштырып алды,— дип сөйләделәр дошманнары.

Патый башта ук Сажидәгә карашын болай дип белдерде:

— Өлкән киленем — киңәшчем, кече киленем — көндәшчем,— диде.

Сафадан күреп, Фәхри дә Сәләхиләргә яучы җибәрде. Сәләхи бер сүзсез кызын Фәхригә бирергә риза булды. Шулай итеп, Сафа туеннан соң берничә көн үткәч, Фәхри туен ясадылар.



## Сакен Сәйфуллин

*Күренекле казакъ шагыйре, фидакарь җәмәгать эшлеклесе, революционер Сакен Сәйфуллин 1894 елда Караганда өлкәсенең Җаңаарка районында туа. 1914 елда, Омск шәһәрендәге Учительская семинариядә укыган чагында, егерме яшьлек студент Сакен үзенең «Узган көннәр» дигән беренче шигырьләр җыентыгын Казан шәһәрендә бастырып чыгара. Революция елларында үз илендә Советлар власте урнаштыру өчен көрәштә зур эшчәнлек күрсәтә. 1918 елдан коммунистлар партиясенә керә һәм Акмолада «Тормыш» исемле революцион газета чыгаруны оештыра.*

*Аның 1917 елда иҗат иткән «Без атларны җитез иярләдек», «Әйдәгез, егетләр», «Далада», «Зинданнан», «Яшь казакълар марсельезасы», «Эшчеләргә», «Иптәшләр» һәм башка әсәрләре революцион пафос белән сугарылганнар, азатлык һәм бәхет өчен көрәшкә өндәү булып яңгырыйлар.*

*Сакен Сәйфуллин Казагыстанның мәгариф халык комиссары урынбасары, республиканың Халык Комиссарлары Советы председателе, «Эңбәкше казак» (хәзерге «Социалистик Казагыстан») газетасының, «Әдәбият майданы» журналының редакторы булып эшли. Абай исемендәге techинститутта укыта.*

*«Асау толпар», «Кызыл лачыннар», «Домбра», «Советстан», «Альбатрос», «Күкчәтау», «Кызыл ат» һәм башка бик күп әсәрләре Сакен Сәйфуллинның зур иҗади уңышларыннан санала.*

*Сакен Сәйфуллин прозаик буларак та казакъ совет әдәбиятын баетуга бик зур өлеш керткән әдип. Аның атаклы «Тар юл, тайгак кичү» исемле романыннан тыш, «Җир казучылар», «Безнең тормыш», «Айша» һәм башка хикәяләре игътибарга лаек.*

*Сакен Сәйфуллин казакъ совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе. Иҗтимагый-политик эшчәнлеге һәм казакъ сәнгатен үстерүдәге зур казанышлары өчен ул 1936 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.*

*Түбәндә урнаштырылган «Укҗитмәс» легендасы Сакен Сәйфуллинның «Күкчәтау» исемле поэмасыннан бер өзек. Без укучыларыбызга аның кыскартылган тәрҗемәсен тәкъдим итәбез.*

### Укҗитмәс

Таш кыя басып тора күл буенда,
Онытып бар дөньяны, уйга калып.
Менсә менәр ул кыяның түбәсенә
Мәргән дусты ак карчыга, канат кагып.
    Җәя тартсаң таш кыяга угың җитмәс,
    Бер тауга да ул баш иеп тәгъзим итмәс.
    Бер кеше дә меналмаган шул кыяның
    Түбәсеннән дала күрке — бөркет китмәс.
Бу кыя Бурабайның итәгендә,
Масаеп, күлгә карап, басып тора.
Урта йөз, Аблай хан заманында
Бу җирдә онытылмаслык бер хәл була.

Казакъ, калмык ул вакытта күрше булган,
Үзара җәнҗаллашып, сугышып торган.
Кан эчәр байлар, биләр сыеша алмый,
Ил өстенә төрле-төрле тозак корган.
Меңләгән ат тоягы дөбердәгән,
Тузан-туфрак, төтен баскан авылларны.
Калмык иле зар елаган һәм каргаган:
«Җир йотсын, — дип, — каһәр төшкән
Аблайны».
Янган, көйгән һәм тапталган калмык җире,
Кан белән аралашкан атның тире.
Кызларны, хатыннарны әсир итеп,
Суйганнар каршы килгән һәрбер ирне.
Аблай, ач бүредәй, алдан барган,
Ул йөкле хатыннарның карынын ярган.
Бишектә елап яткан сабыйларны
Чырылдатып сөңгесенә чәнчеп алган.
Кызларның сылуларын сайлап алып,
Чәчләреннән бер-берсенә бәйләп алып,
Куй кебек көтү итеп «улҗабыз [1]» дип,
Киткәннәр кан эчәрләр әйдәп алып.
Аблай хан җыйган барлык батырларны,
Өләшергә диеп талап алган малны.
Шунда бер сылу өчен гауга купкан,
Һәркем үзе өчен даулый икән аны.
Ул кызның унҗидегә җиткән яше.
Биленә төшеп тора икән чәче.
Чем-кара, карлыгачның канатыдай,
Кыйгачланып киткән икән ике кашы.
Шау-шу тынмый, кызганнан-кыза барган,
Ахырда батыр батырга кул салган.
Башкача юл калмагач, мондый боерык
Булган икән диләр явыз Аблай ханнан:
— Батырларым колак салсын фәрманыма.
Бу җәнҗал инде минем каравымда!
Үзе тапсын үз батырын арагыздан,
Тапшырдык әсир кызның сайлавына.
Батырлар риза булган моны ишетеп,
Тезелгәннәр кызның сайлаганын көтеп.
Тоткын кыз үзе кемгә барам дисә,
Сылуны шул алачак хатын итеп.
Әйтерсең лә, кулга төшкән бала киек,
Әлсерәгән кебек мәргән угы тиеп,
Баштан ашкан хәсрәтен яшерә алмый
Кыз торган хан алдында башын иеп.
Кашын җыерып, төбәгән хан кызга күзен,
Әйткән аңа болай үзенең боерык сүзен:
Сылу, менә басып тора батырларым,
Арадан иң батырын сайла үзең.
Кыз әйткән: — «Мин кол, тәкъсир, үзегезгә.
Тәкъдирдә язган эшне күрү — безгә.
Адәмне җиде карап сынамыйча,
Бер күрүдә дөрес бәя бирербезме?
Мин чыгармын шуңа — оста мәргәненә,
Аткан угын төз тидерә белгәненә.

[1] Улҗа — ганимат, трофей.

Эленсен бу кыяга ефәк яулык,
Риза шуны атып алып биргәненә.
Риза булган Аблай кызның теләгенә, —
Сынау бу чын батырларның беләгенә,
Күл буенда басып торган биек кыя
Шөбһә салган һәр батырның йөрәгенә.
Кыз чишкән урамалын [1] билендәге,
Сөйгәненең бүләге ул илендәге,
Бер-бер артлы күз алдыннан үткән шунда
Гамьсез көннәр туып-үскән жирендәге.
Урамалның чит-читләре челтәр икән,
Язуы бар «һәрвакыт син истә» диган,
«Әгәр бер көн вәгъдәләрең бозар булсаң,
Ертып ташла, я утка ат, чиш тә», дигән.
Табышмаклы язуларга карап алып,
Ташлаган кыз хан алдына ефәк яулык.
Батырлар жәяләрен тарткалаган,
Хан белән тоткын кызны урап алып.
Аблай хан жайлап утырган жиреннән
Гаскәренә карап шунда болай дигән:
— Батырларым, шау-шуларга сәбәп бетте,
Шобаганы сайлап алыр вакыт житте.
Ун егет, билгә бәйләп озын bayны,
Үрмәләп таш кыя башына менгән.
Истәлекле сүзләр чиккән кыз яулыгын
Шул кыяның иң биек төшенә элгән.
Элеп куйган яулык жилфер-жилфер иткән.
— Атыгыз! — дигән Аблай хан биеклектән.
Ә батырлар жәя тарткан берәм-берәм,
Һәм кыяга атылган ук очып киткән.
Атылган ук ташка тиеп ялтыраган.
Бала бөркет тау өстендә саңкылдаган,
Укларын житкерә алмый шул яулыкка,
Батырлар хәлдән таеп аптыраган.
Бу сынауны үтәү кая батырларга!
Калмык кызы шулай итеп исән калган.
Атылган ук житмәгәнгә түбәсенә,
Кыя да «Укжитмәс» дип исем алган.

Казакъчадан кыскартып тәрҗемә итүче
ИБРАҺИМ САЛАХОВ.

[1] Урамал — яулык.

**Габдрахман Әпсәләмов**

# КӨН ДӘ УЙЛЫЙ ТОРГАН УЙЛАР

Соңгы вакытларда идеология эшенең тагын да җанланып китүе, сугышчан, килешмәүчән төс алуы шатландыра. Дөньяда ике идеология бар — социалистик идеология һәм буржуаз идеология. Алар ут белән су шикелле бер вакытта да янәшә тыныч яши алмыйлар. Кайчандыр буржуаз идеология хакимлек иткән, гүя ул дөньяга мәңгегә килгән кебек булган. Ләкин революцион эшче сыйныф эчендә, көрәш ялкынында, яңа идеология туа башлагач, буржуазиянең итәгенә дә ут капты, чөнки яңа идеология аңа кабер казучыларның идеологиясе иде. Бу идеологияне ул тамырында ук бетерергә маташты, бик күп явызлыклар эшләде, бик күп кан койды. Әмма сыйнфый көрәш кыза барган саен аның яңа идеологиясе дә канат җәя барды. Һәм, ниһаять, Октябрь социалистик революциясе җиңгәч, бу яңа идеология дә безнең илдә тантана итә башлады. Совет власте, Коммунистлар партиясе аны эзлекле рәвештә тормышка ашыра барды. Революцион үзгәрешләр барышында совет идеологиясе үзенең яңадан-яңа якларын ачты. Ул безнең тормышның бөтен тармакларына үтеп керә башлады, культура, әдәбият, сәнгать өлкәләрен дә эченә алды. Рухи тормыш һәм акыл өчен дә көрәшә башлады.

Тарих бер туктаусыз үзенең елъязмаларын яза бара. Мәгълүм булганча, империалистлар Совет властен бәреп төшерү өчен әллә ничә мартәбәләр корал көчө кулландылар. Үзләренең иң турылыклы һәм иң явыз этләре — гитлер фашистларын, бәйдән ычкындырып, безнең азат Ватаныбызга өстерделәр. Канлы көрәш нәтиҗәсендә моннан нәрсә килеп чыкканы һәркемгә дә билгеле.

Тарихи сабак — бик зур сабак. Империализм Совет властен корал көче белән юк итә алмагач, тешләрен кысып, аның белән килешергә мәҗбүр булдымы? Үзенең барлык яшертен позицияләрен ачтымы? Юк, империализм тарих тарафыннан бетәргә хөкем ителгән булса да, ул актык минутына кадәр сугышырга, якалашырга тырышачак, көрәш кискенләшә барган саен аның мәкерлеге дә артачак. Хәзер ул безгә каршы иң кабахәт төстә идеологик диверсия алып бара, безнең төрле йомшак якларыбыздан файдаланып, төрле тотнаксыз элементларны эшкә җигеп, аларның ачык авызлыгыннан бик оста һәм явыз файдаланып, Ватаныбызны эчтән какшатырга маташа. Соңгы вакытларда Польшада, Чехословакиядә булып үткән чуалышлар шул ук идеологик диверсиянең бер күренеше. Ә Кытайдагы маочылар империализмга турыдан-туры хезмәт итәләр. Мондый шартларда безгә үз идеологиябез өчен көрәштән туктарга ярыйсы, тынычланып, аны йомшартырга нигез бармы? Юк, әлбәттә. Моны безнең һәрберебез тирәнтен аңларга, идеология өлкәсендә принципиаль, килешмәүчән булырга тиеш. Империалистларның идеологиясе тыштан гына бизәлгән, ә асылында, мең төрле төскә керсә дә, әшәке, явыз, канлы идеология ул. Шуңа күрә буржуаз идеологиянең көчен киметеп карарга да, аның мәкерлеген исәпкә алмаска да хакыбыз юк безнең. Көрәш бик кискен, бик үткен. Социалистик идеология — социалистик тормышның асы-

лы булса, буржуаз идеология — империализмның асылы. Ике идеологиянең үзара үлем көрәшендә әһәмиятсез, икенчел дәрәҗәдәге нәрсәләр юк. Бүген ул хуҗалык өлкәсендә барса, иртәгә культура, сәнгать, әдәбият өлкәсенә күчәргә мөмкин. Дөресрәге, ул бер үк вакытта алып барыла. Аның фронты бик киң. Безгә һәр өлкәдә уяу булырга кирәк. Көрәштә йокламыйлар!

Әдәбиятның үзәгендә дә идеологик көрәш ята. Әдәбият нәрсәнедер яклый, нәрсәнедер кире кага. Бу аның табигате, шуннан тыш ул яши дә алмый. Ләкин әдәби әсәрләрдә фикерләр ачыктан-ачык, шәррән-яра әйтелми, образлар аркылы бирелә. Идеологик диверсия алып баручылар кайчагында әдәбиятның шул үзенчәлеге артына яшеренергә дә маташалар. Мәсәлән, хәзер: «Мин — кызылланмыйм, мин — битараф», дип ачыктан-ачык әйтүчеләрне очратмассың. Хәзер совет кешеләре битарафчылыкның нәрсә икәнен бик яхшы аңлыйлар: ул буржуаз идеология тарафыннан безгә каршы кулланыла торган бер диверсион алым гына. Ләкин кайчак бу медальнең икенче ягын күреп бетермибез шикелле. Вакыты-вакыты белән киракcезгә «кызылланабыз», ягъни буш сүз сөйлибез, битарафсызлыкны кычкырып тәнкыйть иткән булабыз, ә алар урыннарында кала бирәләр. Мактану, бугаз еру — идеология эшенә зарар гына китерә. Чөнки мактанганда көрәшнең төп максатын — буржуаз идеологияне фаш итүне, үз принципларыңны кискен яклауны онытып җибәрәсең.

Аннары шуны да истән чыгарырга ярамый: идеология эше гомумән бик нечкә эш, аны сак һәм тиешенчә алып бармаганда намуслы кешенең күңеленә тию, аның саф хисләрен мыскыл итү мөмкин. Нәтиҗәдә объектив рәвештә дошман тегермәненә су коясың. Безнең шартларда, ягъни милли республика шартларында, таякны чак кына бегеп җибәрү дә хәзер кешенең иң нечкә — милли хисләренә барып бәрелә. Шуңа күрә бу өлкәдә аеруча сак эш итәргә кирәк, кешене урынсызга рәнҗетү, аның милли хисләрен таптау — социалистик җәмгыятькә булышмый, киресенчә, зарар гына итә.

Мәгълүм ки, милли хисләр, әгәр алар коммунистик мөнәсәбәтләр интересларына юнәлдерелсә һәм шуңа хезмәт итсә, бик зур файда китерәләр. Коммунистлар партиясе яклаган СССР халыкларының дуслыгы үзәгендә әнә шул ята бит. Әгәр без бүген коммунизмны уңышлы төзибез икән, әгәр социалистик лагерь бүген җиңелмәс бер көчкә әверелгән икән, без монда СССР халыклары дуслыгына, социалистик илләр дуслыгына бурычлы. Шул ук вакытта бу һәр милли республиканың яшәве һәм чәчәк атуы өчен дә кирәк. Мәсәлән, безнең Татарстан республикасында алтмышка якын милләт вәкилләре бар. Аларның үзара дус, тату булуы безнең һәр өлкәдәге планнарыбызны, ахыр килеп, арттырып үтәүгә китерә. Тагын шунысы бик күңелле: бездә бер милләт вәкиле дә үзен башкалардан өстен итеп куймый, һәр җирдә интернациональ дуслык идеяләре хөкем сөрә, һәр халыкның җырларына, биюләренә, музыкасына, әдәбиятына юл куела. Икенче төрле әйтсәк, бу безнең илебездә ленинчыл милли политиканың чәчәк атуы, милли аерымлыкларның бетә баруы дигән сүз. Моның никадәр әһәмиятле булуын безнең һәрберебез күрә: интернационал дуслык шартларында һәр милләтнең культурасы, әдәбияты, сәнгате үсә, байый, тормыш яхшыра бара.

Әгәр, киресенчә, интернационал дуслыкны санламасак, бозсак, һәр милләтне аерым алып карый башласак, аның милли тойгыларында җавапсыз уйнасак, бу — бик күңелсез нәтиҗәләргә, милләтчелек калдыкларының кабынып китүенә китерер иде. Бәхеткә каршы, мондый күңелсезлекләрнең социал җирлеге безнең илебездә бетерелгән. Монысы шулай. Тик, әйткәнебезчә, милләтчелек калдыкларына күз йомып карарга ярамый, чөнки алар белән тиешле көрәш алып барылмаса, алар, караңгы, тынчу урыннардагы пәрәвезләр кебек, бик тиз үрчеп китүләре бар. Шуңа каршы рәвештә без хезмәт ияләрен интернационал рухта тәрбияләүгә зур игътибар бирәбез. Бу эштә культура, әдәбият чараларының роле бик зур. Алар СССР халыкларын рухи яктан якынайтуны күздә тоталар. Бу эштә алар ярты гасыр буе тәҗрибә җыйдылар. Моннан соң да аларның шул юлдан тайпылмыйча барасында шик юк. Чөнки без бүтән юлны эзләмибез дә, ул безгә кирәкми дә. Безне аеруча шатландырганы шул: хәзер һәр милләтнең культурасы, сәнгате, әдәбияты гомум совет культурасының, әдәбиятның, сәнгатьнең олы, интернационал юлыннан бара, торган саен социалистик эчтәлеккә байый, башка тугандаш халыклар ирешкәннең иң яхшы үрнәкләрен үзендә бул-

дыра бара. Бу үз чиратында бөтен совет культурасын, сәнгатен, әдәбиятын яңа үсүләргә күтәрә.

Без Идел буе халыклары белән бик күп әдәби атналыклар үткәрәбез. Алар — безнең Татарстанда, без — аларның республикаларында. Бу — бик яхшы эш. Чыннан да, үзеңне киң Иделгә чыккандай хис итәсең. Безне башка республикаларда якты чырай белән каршы алулары, әдәбиятыбызны белүләре, яңа әсәрләр белән кызыксынулары күңелне күтәрә, сиңа яңа рухи көч бирә, син үзеңнең киң милләтле укучылар каршында җаваплы булуыңны тагын да ачыграк тоясың. Совет язучылары үз кабыкларында бикләнеп ятмыйлар, бикләнеп яту — иҗади канатларны бөтен көченә җилпергә мөмкинлек бирми. Иҗат кешесенә гомумән киңлек кирәк, киңлектә зур, якты уйлар туа.

Муса Җәлил күптән инде барлык совет кешеләренең уртак сөекле шагыйре булып әверелде, аның иҗатын һәм батырлыгын белмәгән кеше юк, һәр җирдә аның рухи бөеклегенә, искиткеч талантына баш ияләр. Шундый бөркетне тудыра һәм үстерә алуы өчен татар халкына да, тәрбияләве өчен татар әдәбиятына да хөрмәт бирмәбер арта. Муса Җәлилнең ялгыз Ярулла булмавы, аның тирәсендә ил батырларының күп булуы, язучыларның актив катнашуы безне тагын да горурландыра. Ләкин батыр Мусалар татар халкының ниндидер артыклыгыннан яки өстенлегеннән килми, бәлки Коммунистлар партиясенең гүзәл эшчәнлегеннән, халкыбызның интернационал рухта тәрбияләнүеннән туа.

Бер уңайдан шуны да әйтим: безнең халкыбыз тарихында интернационал дуслык идеяләрен алга сөргән батырлар да, язучылар да бик күп. Кызганычка каршы, без, язучылар, аларны тиешенчә күрсәтеп биргәнебез юк. Интернационалист булу — үз туган халкыңны яратуны да таләп итә. Үз халкын тиешенчә хөрмәт итмәгән кеше — ул интернационалист була алмый. Бу — бик табигый нәрсә. Әмма көндәлек тормышта, эш арасында, без шуны онытып җибәргәлибез түгелме?

Язучы буларак та, патриот буларак та зур батырлыклар күрсәтеп безнең арадан киткән кешеләрне алыйк. Алар хәзер җисми яшәмиләр, ләкин батырлыклары, иҗатлары белән халык күңелендә яшәүләрен дәвам иттерәләр. Алар калдырган мирас — исемнәренең рухи байлыгы. Без аннан файдаландык, файдаланабыз, моннан соң да файдаланачакбыз. Шулай булгач, аларны «онытырга» безнең хакыбыз бармы? Мәсәлән, Мулланур Вахитов дип без еш сөйлибез. Аның исемендә безнең Татарстанда колхозлар да, китапханәләр дә, урамнар да бар. Җырлар, пьесалар да бар. Монысы бик яхшы. Без батыр Мулланурыбыз белән хаклы рәвештә горурланабыз. Ләкин Мулланур Вахитовны республикабыздан тыш киң масса беләме? Аны безнең милли героебыз итеп таныймы? Аның революцион эшчәнлеген генә түгел, Владимир Ильич Ленин белән бергә эшләвен, кайбер документларга Ленин белән бергә кул куюын беләме? Ленин Мулланурны хөрмәт иткән, аңа ышанган. Шул кеше бүгенгә хәтле Союз күләмендә тиешенчә билгеле түгел. Кем моңа җаваплы? Фәкать үзебез генә.

Яки Бөек Ватан сугышында батырларча сугышып һәлак булган шагыйрь Фатих Кәримне алыгыз. Рус телендә аның берике кечкенә шигырь китабыннан башка бер нәрсәсе дә юк. Алар да күп китаплар арасында ничектер күзгә ташланмый калдылар. Билгеле, киң укучылар массасы, бу урында моны аеруча басым ясап әйтәбез, күп милләтле укучылар массасы аны күренекле совет шагыйре итеп белми. Димәк, без патриотның истәлеге алдында гына түгел, күп милләтле укучылар алдында да бурычлы: шундый талантлы патриот шагыйрьне аңа җиткермибез. Икенче төрле әйтсәк, без үзебезнең рухи байлыгыбызны үзебез киметеп күрсәтәбез. Моңа тыныч кына карарга ярыймы? Юк, ярамый. Фатих Кәримне күп милләтле укучыларга күрсәтеп бирү — безнең интернационал бурычыбыз.

Мин, билгеле, мисаллар гына алдым. Чынлап тотынганда аларны бик күп санарга мөмкин булыр иде. Монда шуны гына өстәп әйтәсе килә: халыкның рухи хәзинәсенә бик тә игътибарлы булырга кирәк. Ул безгә генә түгел, киләсе буыннарга да кирәк. Бу — язучылар өстенә төшкән кадәресе, билгеле. Интернационал дуслык, интернационал тәрбия бездән матур сүзләр түгел, конкрет эш көтә. Лыгырдау — изге эшкә зыян гына.

Быел Идел буе республикаларының — мари, чуваш, удмурт, мордва, башкорт һәм татарларның әдәби радиофестивале булып үтте. Бу, минемчә, бик мөһим чара. Ул интернационал дуслыкны ныгытуга ярдәм итә. Мәгълүм булганча, бу халыклар гомер гомердән аралашып янәшә яшиләр,

аларның тарихларында да, тормышларында, сәнгать, әдәбият һәм көндәлек эшләрендә дә уртак яклар, үзенчәлекләр бик күп. Алар моңарчы да бер-берсенең культурасына тәэсир итешеп, аны баетышып килделәр. Әдәби радиофестиваль шул мөһим эшне тагын да җанландырып җибәрүнең бер күренеше.

Әлбәттә, интернационал дуслыкның колачы бик киң, ул Идел буе республикалары белән генә чикләнми. Ул РСФСР һәм СССР күләмендә дә бара. Былтыр Казанда яшь язучыларның РСФСР күләмендәге киңәшмәсе булып үтте, аннары Ленинград сәнгать осталары һәм язучылары безгә килеп китте, үзебез дә Ленин шәһәренә барып кайттык. Союздаш республикалар белән дә кара-каршы дуслык бәйләнешләре бар. Алда торган зур бәйрәмнәр — юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинның тууына йөз ел тулу көне һәм Татарстан республикасының данлы илле еллыгы бу эшкә тагын да ярдәм итәр.

Башка халыклар белән даими алып барылган культура хезмәттәшлеге, шул нигездә бер-береңә йогынты ясау, бер-береңне баетышу, ахыр килеп, совет кешеләренең эстетик зәвыкларын да формалаштыра, интернационал дуслыкны тирәнәйтә, хезмәттә активлаштыра. Бер-береңне яхшырак белү исә үзмаксат түгел, ул безнең бөек эшкә — коммунистик төзелешкә кирәк.

СССР халыкларының культуралары якынаюы, аларның бер-берсенә тәэсир итешүе милли культураларны бер-берсенә каршы куюны китереп чыгармый, аларның кайсына булса ясалма өстенлек бирми, киресенчә, алар арасында искедән калган барлык киртәләрне бетерә, юкка чыгара бара. Шул ук вакытта милли традицияләрнең, милли культураларның үзенчәлекләрен дә дөрес аңларга кирәк. Әгәр теге яки бу халыкта гомуми эшкә каршы килә торган традицияләр була икән — аларны, милли традициябез дип, яклауда ни мәгънә? Киресенчә, һәр халыкка да аңлашыла һәм рухи якын традицияләр бездә тирән яклау таба. Менә безнең яз бәйрәме — сабан туе. Аңа безнең республикадагы алтмыш милләт вәкилләренең барысы да катнаша, чөнки ул барысына да аңлашыла һәм рухи якын. Кайсы милләт хезмәтне олыламый да, зурламый. Ә сабан туеның нигезендә шул ята, ә милли бизәкләр аны матурлый гына.

Хәзер һәр халыкның художество зәвыклары бик нык үсте. Моның идеясе әйбәт дип кенә шыр ялангач нәрсәләрне халык кабул итми. Аннары художество әсәрләрендә идея белән форма аерым яшәми дә. Бары тик халтурщиклар гына аларны аерым караулары мөмкин. Интернационал дуслык бәйрәмнәрендә һәр халык чын сәнгать күрсәтергә, шул нигездә үзенең нинди рухи хәзинәгә ия булуын башкаларга ачык аңлатырга тиеш. Башкалар да соклансa — шул иң югары бәя. Бер-береңнең белән яхшы мәгънәдәге ярышу, шул нигездә барыңның да алга китүе — менә интернационал дуслыкның әһәмияте.

Коммунистлар партиясе милләтләрнең һәрьяклап якынаюын да, шуның белән бергә милли аерымлыкларның саклануын да исәпкә ала, ул бу мәсьәләдә бер генә яклы эш итми. Милләтләр һәм халыкларның торган саен якыная баруының объектив процессын яклап, Коммунистлар партиясе милли үзенчәлекләрне санламауга да, шулай ук аларны күпертүгә дә юл куймый. Без, язучылар, моны һәрвакыт истә тотарга, каш ясыйм дип күз чыгармаска тиешбез. Мәсьәлә ачык та, катлаулы да. Ул уйлап эш итүне сорый.

Безнең культура эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли, дип һәрвакыт кабатлап киләбез. Бу сүзләрне белмәгән, танымаган кеше бездә юк. Ләкин форма мәңге үзгәрешсез бер нәрсә түгел, еллар үтү белән аның кайбер яклары искерә, яңа тормышка, яңа шартларга туры килми башлый. Менә шул искергән нәрсәләрдән ул арына бара, үзгә төс ала, камилләшә. Бу турыда КПСС Программасында бик ачык әйтелгән.

Хәлбуки, кайбер язучылар һәм сәнгать эшлеклеләре милли үзенчәлекләрнең әһәмиятенә артык югары бәя бирәләр, аны асылда төп нәрсә итеп карыйлар, ә яңа шартларда халыклар тормышында килеп туа торган үзгәрешләрне исәпкә алмыйлар яки күрмәмешкә салынаалар. Икенче төрле әйткәндә, әлеге дә баягы, милли форманы үзгәрешсез итеп санап, төп игътибарны аңа юнәлтәләр, ә эчтәлек икенче дәрәҗәдәге мәсьәлә булып кала. Нәтиҗәдә, искергән, хәтта зарарлы булган традицияләрне, гореф-гадәтләрне күтәреп чыгуга юл ачыла. Моның бары тик милли эгоизмга, милли чикләнгәнлеккә китерүе мөмкин. Ә милли эгоизм, милли чикләнгәнлек, Владимир Ильич Ленин әйтмешли, вак буржуазия калдыкларының иң тирәне.

Хәзер безнең илдә КПСС Үзәк Комитетының апрель Пленумы карарларын тирәнтен өйрәнү бара. Безгә, язучыларга, бу Пленум карарлары аеруча кагыла. Без аннан үзебез өчен принципиаль бер нәтиҗә ясарга тиешбез. Карарларда татар әдәбияты телгә алынмаган дип тынычланырга нигез юк. Әлбәттә, йөз кызартырлык идея чатаклыкларының бездә булмавы күңелле хәл. Бу безнең оешманың гомуми политик аңы шактый югары икәнен күрсәтә. Ләкин принципиальлекне югалтсак, идеологик көрәшне йомшартсак, кычытканнар безнең басуларда да үсеп китүе бик ихтимал. Игътибарсыз булсаң, чүп үләне һәр җирдә чыгарга гына тора бит. Әнә Мәскәү язучылары арасына тыкшынган бер төркем антисоветчикларны Көнбатыш пропаганда ничек күккә чөя. Ул бәндәләрнең совет әдәбиятына да, чын совет язучыларына да һичбер катнашы юк, моны чит илләрдә дә беләләр, ләкин совет тормышын каралтырга ярагач, алардан шатланып файдаланалар.

Кайчагында безнең агай-эне бер генә яклы фактлар белән мавыгып, аларны безнең тормышка хас күренешләр, дип күтәреп чыга, ә күренекле әдипләрнең интернациональ эшчәнлеген кечерәйтеп күрсәтә. Бу — зур, принципиаль мәсьәләләрне сай аңлаудан, примитивлык күрсәтүдән килә булса кирәк. Бөтен язучылар коллективы мондый иптәшләргә түземлелек белән аңлатырга тиеш, ләкин аларның хаталарын күпертү дә, аларны күрмәмешкә салыну да коммунистик стиль түгел. Үзәк Комитет Пленумы кабул иткән программа — ул безнең һәрберебезнең шәхси позициясе. Декларация төсендә түгел, ә чын мәгънәсендә идеология фронтының сугышчан көрәшчеләре булу — менә бездән нәрсә таләп итела. Совет әдәбияты — ул революцион әдәбият, коммунистик әдәбият. Аның башка максаты юк.

11. 5. 68 ел.

**Шамил Бикчурин**

# ТАМЫРЛАР



Тимәш халкы аны Чияле тау дип йөртә. Бәлки, кайчандыр, монда кып-кызыл чияләр пешкәндер, ә хәзер тау битендә, ап-ак кар кебек, исәпсез-хисапсыз ромашкалар гына чәчәк атып утыра.

Йөз еллар үткән, ләкин шушы Чияле тау астына, уй җитмәслек тирәнлекләрдә дистәләрчә чакрымнарга җәелгән нефть диңгезе ятадыр дип бер кем дә башына китермәгән.

Гади авыл кешесенең хыялы ерак китмәгән. Чәчәренә җире, җигәренә аты, ашарына кыш чыгарлык икмәге, кияренә бер кат киеме булса, аның өчен инде дөнья түгәрәк. Чишмә һәм Сок елгаларында салават күпере төсләрен чагылдырып яткан хикмәтле май тапларын күргәндә генә алар дөньяда «керәчин» белән яна торган лампа һәм җир астыннан алына торган дегет барлыгын белгәннәр.

Тирә-якларда, ач шакаллар урынына, нефть исен сизгән рус байлары һәм чит ил капиталистлары йөргән. Су өстендә йөзгән зәңгәрле-яшелле май таплары аларга алтын тәңкәләр булып күренгән. Шул тәңкә чыңнары бу тирәләрдә йөз ел элек бөгелмә купецы Малакиенкодан тирән коелар казытырга мәҗбүр иткән. Ә Шандор атлы бәндә ерак Америкадан Шөгер тауларына килеп скважина тиштергән. Англиядә «Казан ойль фильдес Лимитед» диган хикмәтле исемнәр астында акционерлар җәмгыяте оешкан.


Тик дәрт бар, дәрман юк, диләр. Кая инде Малакиенконың кәйлә-көрәкләр белән коралланган ялчыларына адәм башы җитмәс тирәнлекләргә төшү дә, җиде кат җир астындагы хәзинә сандыгын ачу!

Диңгез арты килмешәкләренә дә, «кара алтын» чыгарып, сары алтынга чумарга хыялланган башка капиталист һәм промышленникларга да насыйп булмаган ул нефтьне табу. Тешләре үтмәгән аларның бу җирләргә.

Чияле тау, буләген саклап, гасырлар буена үз кешеләрен, үзен җиңәрдәй баһадирларны көткән.

Бер вакыт килгән ул баһадирлар. Мускуллар көченә таянып түгел, акыл көченә, техника көченә ышанып килгәннәр. Һәм көннәрдән бер көн, матур җәй уртасында, Чияле тау итәгендә, кар кебек ап-ак ромашкалар арасында биек вышка калкып чыккан, тыныч авыл өстендә ротор гөрелтесе ишетелгән. Карт Бакудан, ерак Грозныйдан, чал Урал, киң Идел буйларыннан килгән егетләр тарихта беренче мәртәбә девон тирәнлекләренә юл салганнар. Бораулаганнар да бораулаганнар җир токымын. Моңа кадәр девон серләре мәгълүм булмаган бораулаучы егетләр өчен ике мең метр тирәнлек очсыз-кырыйсыз, исәп-хисапсыз булып тоелган.

Ә буровой Тимәш авылы басуларын, урман-кырларын яңгыратып, шаулаган да шаулаган, гүя ул ярдәмгә бу як кешеләрен — татар егетләрен дә чакырган.



*Өченче номерлы скважина.*

Нефтьче булу теләге бик күпләрне җилкендергән, байтак кешеләрнең йокысын качырган. Дулкынланып торган диңгез булып та күз алдына килгән ул нефть, үкереп аккан елга булып та, өскә ургыган фонтан булып та.

Йөрәгендә дәрте, беләгендә көче булганнар түзмәгәннәр, Чиялә тау итәгендәге 3 нче номерлы скважинага килгәннәр. Тимәштән Әхәт Гобәйдуллин, күрше Сугышлы авылыннан Муса Хөсәенов, Садыйк Хәбиров, Вәли авылыннан Касыйм Шәймәрдәнов кебек, данлы сугыш юлын үтеп, яңа гына илгә кайткан кыю егетләр булганнар алар.

Теләкләре изге булса да, аларга беренче көннәрдән үк идарә пультына басарга яки верховой урынына вышка башына менәргә насыйп булмый. Әхәтне слесарь, Садыйкны буровой эшчесе, Касыймны дизельче, Мусаны бораулаучы ярдәмчесе итеп алалар. Шунысына да шөкер итәләр егетләр.

Бер ел буена гөрли буровой, ел буена көтәләр нефть чыгуын. Җәйне жил-яңгырлы көз, көзне кар-буранлы кыш алыштыра. Гөрләвекләре, ташулары белән яз да үтеп китә, басу-кырларны яшелләндереп тагын җәй җитә. Чиялә тау итәге яңадан ап-ак ромашка чәчәкләренә күмелә. Борау һаман каты токымнарны кимереп аска төшә.

1948 елның 16 июль иртәсе. Башка җәйге иртәләр төсле үк, бу иртә дә җылы, кояшлы булып килде. Моннан күп еллар элек булган кебек үк, бу иртәдә дә Чиялә тау өстендәге иминлектә күкеләр кычкырды, кошлар сайрады, авыл буасында, берсен-берсе уздырып, бакалар бакылдашты. Таң белән уянган авыл хатыннары сыер саудылар, көтү кудылар. Салам түбәле өй морҗаларыннан багана-багана төтен күтәрелде.

Һич нәрсәсе белән аерылмый иде бу җәйге иртә.

Әмма бер нәрсә генә башка көннәргә караганда ятрак иде: Чиялә тау битендәге скважинада бу көнне ел буена үкереп торган ротор тавышы ишетелмәде. Бораулаучылар тирән девон катламына җиткәннәр, скважинага ашыгып-ашыгып торпедо төшерәләр — забойны шартлатырга җыеналар.

Яңа урында яңа нефть чыганагын бораулаучыларның үзләреннән дә түземсезрәк көткән «Татнефть» тресты управляющие Шмарев та, күп еллардан бирле шушы урыннарда нефть табу идеясе белән хыялланган баш геолог Мальцев та биредә.

һәм кинәт, хәтәр тынлыкны бозып, җир астында тонык шартлау ишетелә, Чиялә тау итәгендә шатлыклы авазлар яңгырый:

— Нефть чыкты, нефть!

Нефтьнең үзе кебек атылып чыккан бу куанычлы хәбәр тиздән авылга, районга, бөтен илгә таралды.

Тимәш авылында, ромашкалар үсеп утырган Чиялә ату итәгендә, җир асты хәзинәсе табылган бу көн тарихка дөньяда иң зур, уникаль Ромашкино нефть ятмасы ачылган көн булып керде.

Чиялә тау астында нефть диңгезе барлыгы беленгәч, 3 нче скважинаның ялгыз калмаячагы мәгълүм иде инде. Һәм тиздән алар ишәйде. Шул ук елны Чиялә таудан ерак та түгел, Вәли хуторы дип йөртелгән авыл кырыенда 10 нчы номерлы скважинадан фонтан бәрде. Ул да булмады, Зәй-Каратай авылының бәрәңге бакчалары артына ук салынган 8 нче скважина нефть бирде. Шул көзне Миңлебай авылы янында, моңа кадәр бакалар патшалыгы өчен генә хезмәт иткән сазлыктан «кара алтын» чыгуы турында хәбәр иттеләр. Бераздан Иске Суркино урманы эченә утыртылган 1 нче номерлы буровойдан рапорт алынды: «Нефть бәрде. Дебит — тәүлеккә 200 тонна». Китте эшләр ходка. Көн туа, көн туган саен яңалык: 2 нче скважина фонтанлый башлаган, 7 нче скважина сафка баскан, 4 нче, 1 нче, 6 нчы...

3 нче номерлы скважина — ул скважиналар анасы. Аннан соң туган кайсы гына скважинаны алсаң да, аның тамыры Чиялә таудан башлана. Ул тамырлар тармаклана-тармаклана Зәй-Каратай, Миңлебай, Әлмәт нефть мәйданнарына китә. Ямаш нефть ятмаларына, Яңа Елховой нефть чыганакларына таба юл ала. Икенче яклап, ул тамырлар Азнакайга, Бөгелмә һәм Баулыга таба үрмәлиләр. Сөләй, Сарман нефть чыганакларының да тамырлары 3 нче скважинага килеп тоташкан. «Кара алтын» чыккан һәр җирдә, маяклар урынына факеллар кабызып, разведчиклар плацдармнарны һаман киңәйтәләр, үстерәләр. Вышкалар Сөләйдән Минзәләгә, Минзәләдән Кама буйларына атлый һәм бу җирләрдә Чиялә тау тамырлары үзенең икенче зур туңдәше, Кама буе ятмалары белән очраша.

Киң елга да киртә була алмый тамырларга, алар көчле агымны кичеп, Алабуга, Әгерҗе якларына чыгалар, Татарстанның башкаласы Казанга, Идел буйларына сузылалар.

Чиялә таудан чыккан тамырлар Татарстан белән генә дә чикләнми. Алар, Нурлат кырларын үтеп, Ульяновск өлкәсенә, Бөгелмә тимер юлын кисеп, Оренбург далаларына, Әгерҗе якларыннан Удмуртия басуларына таба эз салалар. Бернинди елгалар да, куе урманнар да, тау-ташлар да каршы тора алмаслык көчле алар Чиялә тау тамырлары.

Тамырлардан үрентеләр үсә, диләр. Скважиналар бригадаларны, бригадалар промыселларны, бораулау конторалары тудырды. Хәзер инде нефть чыганакларын промыселлар, конторалар белән генә түгел, идарәләр, трестлар белән йөртәбез. Егерме ел эчендә Татарстан территориясендә «Баулынефть», «Лениногорскнефть», «Әлмәтнефть» идарәләре кебек һәрберсе йөзләгән скважиналарны берләштергән эре нефть предприятиеләре, «Татбурнефть», «Әлмәтбурнефть», «Татнефтегазразведка» трестларыдай теләсә нинди капиталист монополияләрен көнләштерерлек бораулау трестларыбыз барлыкка килде. Моңа кадәр карталарда исеме күренмәгән Яңа Елховой, Әлки, Азнакай, Иркен авыллары, «Елховнефть», «Әлкинефть», «Азнакайнефть», «Иркеннефть» идарәләре бөтен илдә дан тота. Күптәнме соң Кама буйларында геологларның тилмереп нефть эзләп йөргән чаклары, разведчикларның, ышанырышанмас кына, Кама якларына беренче буровой салган көннәре? Хәзер ул җирләрдә Союзыбызда тиңе булмаган «Прикамнефть» идарәсе утыра.

Аларны күз алдына китергән саен, хатирәләр узганчарга, скважиналар анасы булган 3 нче скважинага кайтып кала. Егерме ел эчендә нинди генә яңалыкларның шаһите булмады Чиялә тау итәгендәге бу ялгыз скважина!

...Нефть чыккан көннәр. Мәңге шунда торып калырга җыенгандай, нефтьчеләр Чиялә тау итәген казып, бригада йорты әзерлиләр. Стеналары имән бүрәнәләрдән, түбәсе йомры имән агачыннан. Кем уйлаган берничә елдан соң ук нефтьчеләр бу җир-өйгә сыймый башларлар, аларга иркенлек, яктылык, масштаб кирәк булыр дип?! Моны кулына кирәк тотып, нефтьчеләр белән бергә тир түгеп эшләп йөргән

бригаданың беренче мастеры Корбан ага Вәлиев тә, зур орден тагып Баку промыселыннан кайткан атаклы нефть остасы Шәйхулла Мотыйгуллин да күңеленә китермәгәндер. Бәлки әле бу җир-өйнең «проектын» сызып бирүче, шушы скважинаның яшь инженеры, булачак министр урынбасары Рәфкать Мингәрәев үзе дә киләчәкне шушы кадәр зур итеп күз алдына бастырмагандыр.

Күп нәрсәләрне тудырды 3 нче скважина. Карагыз сез Әлмәт, Лениногорск, Түбән Кама, Муса Җәлил кебек өр-яңа шәһәрләргә, Баулы, Карабаш, Актүбә, Азнакай кебек зур-зур эшчеләр поселокларына. Аларның биек-биек йортларына күз салыгыз, киң урамнарыннан үтегез, иркен паркларында йөрегез. Керегез мәктәпләренә, техникумнарына, институтларына, культура сарайларына. Сез һәркайда нефть җирләгән, девон сулышын тоярсыз.

Барыгыз акчарлаклар очып йөргән Карабаш диңгезенә, Европада иң зурларның берсе булган Зәй станциясенә, мәрмәрдәй ташлары белән мактаулган Чупай тавына. Анда сезгә Чияле тау миражлары күренгәндәй, Ромашкинодан фонтаннар җыры ишетелгәндәй булыр.


Шома асфальт юллар сезне Кама, Идел буйларына илтер. Шул якларда күкләргә үрләгән гигант корпусларны — Түбән Кама һәм Казан химия комбинатларын күрсәгез, боларны да 3 нче скважинаның газиз балалары дип исәпләгез.

Ниһаять, 3 нче скважинаның җир астыннан киткән нечкә тамырлары, калын артерияләргә әверелеп, Бохара — Урал, Казан — Горький газ трубаларына тоташа, «Дуслык» дигән горур нефть магистраленә кушылып, ерактагы якын дусларыбызга барып ирешә.

Күп нәрсәләрне тудырды һәм шул ук вакытта күпләрне үстереп кеше итте ул 3 нче скважина. Нефтькә хөрмәт белән караган, аны үз байлыгы, ил бәхете итеп күргән байтак кешеләргә һөнәр бирде, дан, шөһрәт бирде.

Грозныйдан килгән атаклы мастер Корбан Вәлиев Чияле тау буенда Татарстан нефтьчеләренең яңа семьясын корып җибәрде, «кара алтын» осталарыннан беренче булып Социалистик Хезмәт Герое дигән югары исемгә лаек булды.

Беренче тапкыр татар егетләрен үз тирәсенә җыеп, нефть чыгару серләренә өйрәтүче, соңыннан шушы ук Ромашкино промыселыннан РСФСР Верховный Советына



*Чистартылган нефть менә шушы «Дуслык» магистраленә китә.*

депутат итеп сайланучы — карт Баку мастеры Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Шәйхулла Мотыйгуллин. Йөрәге ярып туктамаса, бик күпләрнең остасы булыр иде әле мәрхүм, безгә онытылмас тагын бик күп эшләр калдырыр иде...

3 нче скважина күп нәрсәләрне хәтерли. Ромашкинода 1950 елда оешкан 1 нче промыселны да, аның беренче мөдире Рәфкать Мингәрәевне дә, беренче геологы Минадора Ивановнаны да. Рәфгать Шәймәрдәнович хәзер Нефть промышленносте министрының урынбасары, Минадора Макаровна шул министрлыкның баш белгече, геология-минералогия фәннәре докторы. Алар икесе дә Ленин премиясе лауреатлары.

Нефтьтәге беренче адымнарын 3 нче скважинадан атлап үткән егетләр дә инде хәзер «зур үстеләр». Һөнәр мәктәбен тәмамлап, Корбан ага Вәлиев янына килгән 16 яшьлек Вилен Тютиев бүгенге көндә нефть чыгару мастеры булып эшли. 3 нче скважинаның беренче дизелисты Касыйм Шәймәрдәнов инде промысел диспетчеры. Ул хөкүмәтебезнең иң зур бүләге — Ленин ордены белән бүләкләнде.

Чияле тау буенда кузна уйнап үскән Тимәш авылы малайларына гына карагыз. Нефть чыккан елны Әгълим Мөхәммәтҗанов 3 нче скважинага оператор ярдәмчесе булып кергән иде. Өйрәнде, укыды, тырышты. Оператор булды егет, промысел мөдире урынбасары булды. Хәзер инде ул «Баулынефть» идарәсе начальнигы.

Авылдашы Әхәт тә уңган кешеләрдән. Армиядә пушкалар төзәткән бу егет, авылына кайту белән, скважиналар төзәтү эшенә керә. Слесарьдан бораулаучы ярдәмчесе була, бораулаучы була, аннан бораулау мастерына күтәрелә. Хәзер Әхәт Гобәйдуллин илебезнең танылган бораулау остасы, Социалистик Хезмәт Герое.

Галимҗан Әхмәдиев Тимәш авылына нефть инженеры булып кайтты һәм Чияле тауга мастер ярдәмчесе булып килде. Эшкә дәрте, белеме булган бу егет тә, берсеннән-берсе текәрәк баскычларны үтеп, «Әлкинефть» идарәсенең начальнигы булу дәрәҗәсенә җитте. Нефть эшендә күрсәткән хезмәтләре өчен аңа «Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде һәм ул Ленин ордены белән бүләкләнде.

Социалистик Хезмәт Герое, бораулаучы Фәсхетдин Шәрәфетдиновның язмышы да туган авылы, мондагы нефть яклары белән бәйләнгән. Сугышка кадәр үк Шөгер нефтен эзләгән бу егет фронттан да бораулаучылар сафына әйләнеп кайтты, Ромашкино нефтенә юл салучыларның берсе һәм бергәйлесе булды.



*Татарстан нефтенә беренче юл салучы бораулау мастеры Дмитрий Королев.*

Күп нәрсәләрне белә һәм күпләрне истә тота скважиналар анасы. Бораулау мастеры Ибраһим Харрасовны да, Дмитрий Королевны да, Сергей Егоянны да онытмый ул. Бу тирәләрдә көн саен фонтаннар аттыручы, Чияле тау өсләренә якты факеллар кабызучы алар. Хезмәтләре өчен хөкүмәтебез тарафыннан бирелгән орденнары да, шул факеллар кебек, күкрәкләрендә балкып-янып тора!

3 нче скважина ул — скважиналар анасы. Ана балаларын бертекләп санар, санаганда бөркетенә карар, ди. Скважинаананың да горурланып карарлык бөркетләре күп. Социалистик Хезмәт Геройлары Корбан Вәлиев, Мөгаллим Гыймазов, Александр Тимченко, Әхәт Гобәйдуллин, Михаил Гринь, Рәшит Саттаров кебек олы уллары гына ничәү аның! Ә Фәсхетдин Шәрәфетдинов, Гәрәй Баһманов, Николай Драцкий, Җәлил Зәйнагов кебек уртанчы һәм төпчек геройлары белән кем мактан-

мас. (Хәер, алар төпчек булмас әле.) Орденнар һәм медальләр алган батыр егетләре генә дә ничәмә-ничә мең!

«Корал эшләр, егет мактаныр», дигәннәр. Егет кулында корал булмаса, ул ни эшли алыр иде?

Ромашкинода нефть чыганагы ачылу бөтен ил халкын аякка бастырды, татар нефтьчеләренә ярдәмгә белгечләр генә түгел, күплән-күплән техника да килә башлады. Урал заводлары үзләренең иң чыдам бораулау станокларын һәм трубаларын, Сталинград эшчеләре иң яхшы тракторларын һәм вышкаларын, Белоруссия — иң көчле автомашиналарын, Куйбышевлылар — иң нык бораулау инструментларын җибәрделәр. Ромашкино кырына юл салу машиналары, җир казу, труба үткәрү өчен гигант экскаваторлар һәм күтәрү краннары килде. Нефть мәйданнарында вышкалар урманы куерды, авыллардан авылларга, шәһәрләрдән шәһәрләргә шома, тигез асфальт юллар сузылды, ул юлларда берсеннән-берсе куәтлерәк, житезрәк машиналар күренә башлады. Ромашкино яклары җанланды.

Ләкин җир асты байлыгы чамасыз күп, нефть алу мөмкинлекләре чиксез булган, кешеләрдә хезмәт дәрте кайнап торган бер вакытта нефтьчеләрне бу техника гына канәгатьләндерә алмады. Татарстанның нефть промышленносте кешеләрдән яңа техника, яңа технология, яңа алымнар һәм ысуллар куллануны таләп итте.

Менә шунда күренә инде егетнең корал белән ничек эш итә белүе, акылы, зирәклеге. Әйе, корал эшли, егет мактана. Ә кулында корал булып та, егет эшли белмәсә ни булыр иде?

Бер яктан, егеткә галимнәр, инженерлар акылы белән тудырылган яңа төр кораллар ярдәмгә килсә, икенче яклап, егет үзе ул коралларны оста куллана белергә, аны камилләштерергә тиеш.

Мөгаллим Гыймазов шундый егетләрдән. Совет галимнәре темпы әкрен, житештерүчәнлеге түбән булган роторлы бораулау инструментын турбина белән алыштырдылар. Дөньяда беренчеләрдән булып бу ысул белән бораулауга күчүче бригада — мастер Мөгаллим Гыймазовныкы иде. 1952 елда, башка бригадалар елына өчәр-дүртәр мең метр бораулаганда, аның бригадасы ике мәртәбә күбрәк җир тишеп үтә, ә ике елдан соң инде бораулау тизлеге буенча Татарстанда беренчеләр рәтенә чыга.

Ул елларны скважиналарны балчык измәсе белән бораулыйлар иде. Еракдардан махсус үзле балчык китертүләр, аларны озаклап-озаклап чистарту, әзерләүләр кайсы гына бораулаучының үзәгенә үтмәгән!

Ат бер баскан җиренә җиде кабат басса да, адәм баласы бер урында таптанып тора алмый. Скважинаны тоташ су белән бораулап карамакчы була Гыймазов. «Скважинаны харап итәрсең, авариядән башың чыкмас, җавап бирерсең»,— диләр кайберәүләр. Куркыталар, кисәтәләр, яныйлар.

Ә Мөгаллим оста курыкмый, бөтен җаваплылыкны үз өстенә алып, су белән бораулый башлый.

Эшнең нәтиҗәсе Татарстан бораулаучыларын гына түгел, бөтен көнбатыш районнары бораулаучыларын таңга калдыра: «Мастер Мөгаллим Гыймазов 256 нчы буровойда станок-айга 2000 метр тизлек биргән!» 1955 елны аның бригадасы 17 671 метр бораулый, тагын илне шаулата. Яңа, күрелмәгән рекорд!

Скептиклар әйтәләр: «һәр фантазиянең чиге була, инде табасы яңалыклар табылып бетте, резервлар тәмам, бораулаудагы метрлар саны үз чигенә килеп терәлде»,— диләр.

«Юк, диләр новаторлар, без бригадага елына 30 мең метр бораударга тиешбез!»

30 мең метрны кочәнеп, маңгай тире белән генә алдырып булмасын белә новаторлар. Моның өчен бораулауда яңа резервлар ачарга, яңа ысуллар кулланырга, эзләнергә, табарга кирәк!

Вышка төзүчеләргә мөрәҗәгать итәләр: «Безнең кулны сез тотасыз. Алтын вакытыбызны буровойлар көтеп әрәм уздырабыз. Юкмы шуны тизрәк төзү ысуллары?»

«Бар,— дип чыга вышка төзүчеләр бригадиры Александр Тимченко — без вышкаларны сүтмичә, трактор белән тарттырып күчерәчәкбез!»

Моңа кадәр югарыда, «кошлар хокукында» торып эшләргә күнгән Тимченко егетләре 1955 елның суык январь иртәсендә 45 метр биеклектәге вышканы үнлап

трактор белән сөйрәтеп, юлга чыгып китәләр, чокырлар, урманнар, елгалар, таулар аша үтеп, бораулаnасы яңа ноктага килеп туктыйлар. Шул көннән башлап Татарстанда «сәяхәтче вышкалар» барлыкка килә, нефть промышленносте тарихында яңа, гүзәл бер сәхифә ачыла.

Шушы елны ук Александр Тимченко бригадасы бораулаучыларга 69 буровой күчереп тапшыра. 1951 елда «Татбурнефть» трестының вышка-монтаж конторасы өч бригада белән дә нибары 10 буровой төзегәнен исәпкә алсак, Тимченко бригадасының яңалыгы чын революция! Бу ысул 1959 елда вышкалар төзү срогын 1952 ел белән чагыштырганда дүрт тапкыр кыскартырга мөмкинлек бирә.

Моңа кадәр Мөгаллимнең үкчәсенә басып килгән шәкертләре укытучысын уздыра башлыйлар. 1958 елда Михаил Гринь, техниканы бөтен көченә җигеп, бригадасы белән 24 мең метрдан артык бораулый. Икенче елны Гыймазов 26 мең җир үтә, ләкин аның шәкерте Гринь бу елны бораулаучылар күптән хыялланган чикне узып китә — 30 307 метр бораулап күрсәтә.

Вышкачылар да бурычлы булып калмыйлар. Буровойлар күчерү, ел саен ераклашканнан-ераклашуга карамастан, Александр Тимченко бригадасы 1958 елда 39 вышка күчерә. Аның шәкертләреннән Барый Бәһманов бригадасы 43, Нуруллин бригадасы 42 вышка утыртып, Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңүчеләр булып чыгалар.

Осталыклары артканнан-арта вышкачыларның. 1959 елны Ядъкәр Ваһапов җитәкчелегендәге Әлмәт вышкачылары, 59 буровой төзеп, рекорд куялар.

Икенче елны алдынгылык яңадан Тимченко бригадасына кайта. Вышка монтажлаучылар 1960 елны 82 буровой күчерү белән тәмамлыйлар.

1961 елның көзендә Александр Тимченко партиянең XXII съездына делегат булып китә. Ләкин ул белә: үзе юкта да аның дуслары сер бирмәячәк. Һәм шулай була да. Бу көннәрдә Лениногорскидан съездга телеграмма алына: «Съезд делегаты Александр Тимченко бригадасы буровойлар төзүдә яңа зур җиңүгә ирешә. Коллектив 1057 нче буровойны моңача тарихта күрелмәгән тизлек белән — 7 сәгатьтә төзеп бетереп, бораулаучыларга тапшырды».

Заманалар үзгәрә. Элек берничә айларга сузылган буровой төзү тора-бара көннәр белән исәпләнә башлый, көннәр сәгатьләргә күчә. Кайчандыр бораулаучылар вышка даулый иде, хәзер инде вышкачылар бораулаучыларны тиргиләр: «Озак кыймылдыйсыз, буровой күчерүне тоткарлыйсыз. Бораулауның тизләтелгән ысулларын эзлисе иде!»


•

Елына 30 мең метр. Көчләрен, мөмкинлекләрен барысын сыгып алып бетерделәр төсле иде инде бораулаучылар, алга атларга башка урын юк кебек иде. Әмма тынгысыз халык моның белән килешергә теләмәде. «Һәр бригадага елына 40 мең метр бурауларга!» дигән лозунг ташладылар. Ярдәмгә галимнәр килде. Зур диаметрлы бораулау инструментлары урынына кечкенә габаритлы бораулар, нечкә трубалар, бәләкәй күләмле турбиналар тәкъдим ителде. Инструментларны күтәрү-төшерү, трубаларны борып кертү, борып алу операцияләрен башкару өчен автоматлар һәм механизмнар уйлап табылды.

Бораулаучылар арасында елына 40 мең метр өчен көрәш дәвам итә. 36 мең. 38 мең. 39 мең... Я, кайсы мастерның бригадасы билгеләнгән финишка беренче булып килеп җитәр?

Ниһаять, җиңү! «Әлмәтбурнефть» тресты мастеры Николай Драцкий бригадасы 1965 елда станок-айга 3714 метр тизлек белән 40 мең метрдан артык җир бораулый!

Бу батырларның скважиналар бораулаудагы тәҗрибәләре нефть эзләүчеләрнең уртак байлыгына әверелде. Алар көче белән республикабыз территориясендә соңгы елларда гына да 120 яңа нефть чыганагы ачылды. Социалистик Хезмәт Герое Әхәт Гобәйдуллин җитәкчелегендәге разведка бригадасы Кама буйларында Советлар Союзында тиңдәше булмаган яңа нефть чыганаклары тапты. Ромашкино нефтен ачуга катнашкан Социалистик Хезмәт Герое, мастер Фәсхетдин Шәрәфетдинов бригадасы, 17 ел буе нефть эзләп, 250 мең метрдан артык җир тишеп үтте, 150 гә якын тирән скважина салды.



*Буровой үз хуҗалыгы белән яңа урынга килеп утырды.*

Без хәзер елына 30—40 мең метр бораулаучы алдынгыларны дистәләп саныйбыз. Вышкалар төзү — алдынгы бригадаларда елына йөздән артты. Социалистик Хезмәт Герое Гәрәй Бәһманов бригадасы бер ел эчендә 130—140 буровой куя. Бригаданың соңгы рекорды исә теләсә кемнең исен китәрерлек: вышка монтажлаучылар бер буровойны күчерү, корып бетерүне 3 сәгать 40 минутта башкардылар!

Шуңа күрә, бораулау күләме дә Татарстанда, 1950 ел белән чагыштырганда, 12 мәртәбә үсте. 1959 елда безнең бораулаучылар тизлек буенча Американың иң эре, мактаулы нефть штаты булган Техас бораулаучыларын куып җиттеләр. Җидееллык азагында Әлмәт һәм Лениногорск бораулаучылары техаслыларның борыннарына суктылар. Безнең бораулау тизлеге аларныкыннан бер ярым мәртәбә артык!

Һәр эшнең үз остасы, әйдәп баручысы, маягы була. Нефть чыгару эшендә мондый кешеләрнең берсе — Корбан Вәлиев.

Заманында Кавказда җир казучы, аннан ачкыччы, соңыннан җир асты ремонтчысы, нефть чыгару мастеры булып эшләгән кеше өчен инде «кара алтын» серләре мәгълүм. Авылларга барып, кичә генә үзе җыеп килгән колхозчы егетләргә ул скважинадагы механизмнарны күрсәтеп, аларны ничек көйләргә, алар белән ничек эш итәргә икәнен өйрәтеп йөри. Ә скважинада механизм дигәннәре бик гади: коеныкына охшаган чыгыр да скважина көпшәсенә тимер чыбык белән төшерелгән парафин кыргыч. Операторның эше: 3—4 сәгать үткән саен, кул белән чыгырны әйләндереп, скважина көпшәсен парафиннан чистарту.

Скважиналар саны ишәйгәннән-ишәя, нефть хуҗалыгы үсә, кешеләр саны арта бара. Бригаданың скважиналары берничә дистәгә җитә, мәшәкать күбәя. Операторлар өлгерә алмыйлар: кайсыдыр скважинада парафин тыгылган, кайдадыр, чан ташып, нефть аккан, кайдадыр труба ярылган...

Корбан Вәлиев күп нефть мәйданнарында булды, нефтьнең исен дә, төсен дә белмәгән күп яшьләрне укытып, оператор итте. Алты ел эчендә генә дә ул 300 дән артык кешегә нефтьче путевкасы бирде. Кайда гына булмасын, аның скважиналары идеаль чисталык, төзеклек белән, кешеләре белем, тәртип ягыннан аерылып торалар. Корбан ага — галимнәр уйлап тапкан автоматларны куюда да, скважиналарны ерактан идарә итүче аппаратлар һәм механизмнарны көйләүдә дә, бригадаларда капиталь

культбудкалар төзүдә дә инициатор. Аның кулы астындагы скважиналар ватылуны, туктауны белмиләр, аның эшчеләре мастерның йөзенә кызыллык китермиләр.

Скважиналар автоматлашып, эшче куллар бушый төшкәч, Корбан Вәлиев яңа бер тәкъдим белән чыга: «һәр оператор элекке 2—3 урынына 8—10 скважинага хезмәт күрсәтүгә күчсен!» Коры, нигезсез сүзләр генә булмый ул, мастер үзенең мөмкинлекләреннән чыгып эш итә. Аның бригадасында 31 скважина бар. Шуңа 70 оператор хезмәт күрсәтә. Эшче көчләрне акыл белән, дөрес урнаштырганнан соң, нефть чыгаручылар 22 кешегә кала. Хезмәт житештерүчәнлеге ике ярым тапкыр диярлек арта. 1960 елда Социалистик Хезмәт Герое, мастер Корбан Вәлиев бригадасы илебезгә планнан тыш 33 мең тонна нефть бирде.

Күп скважиналарга хезмәт күрсәтүгә күчү тәҗрибәсен республика нефтьчеләре хуплап каршы алдылар. «Кара алтын» табучылар арасында үзкыйммәт, экономия өчен яңа хәрәкәт башланды.

Татарстан нефтьчеләре, галимнәре дөнья практикасында моңача билгеле булмаган, беркайда да кулланылмаган бик күп яңалыкларны, прогрессив алымнарны керттеләр һәм үзләштерделәр. Шуларның иң зурысы һәм эффектлысы катламга су кудыру юлы белән нефть алу. Бу өлкәдә аеруча күренекле хезмәтләре өчен бер төркем галимнәргә һәм инженерларга 1962 елда Ленин премиясе бирелде. Алар арасында Ромашкино нефть ятмаларын үзләштерүдә эшләгән Фәйзрахман Гариф улы Бегишев, Рәфкать Шәймәрдән улы Мингәрәев, Павел Степанович Васильев, Минадора Макаровна Иванова һәм Александр Тихонович Шмарев иптәшләр дә бар иде.

Су биреп — нефть! Бу ысул вакытлар үтү белән арыган, сүнә барган нефть фонтаннарын җанландырып җибәрде, өстәмә рәвештә миллионнарча тонна «кара алтын» алырга мөмкинлек бирде. Җидееллык башында нефть чыгару 1950 ел белән чагыштырганда 37 мәртәбә, ә җидееллык ахырына 92 мәртәбә артты. Без моннан унике ел элек үк нефть чыгару буенча Бакуны узып киттек, бер эшчегә нефть алуда Америка Кушма Штатлары белән тигезләштек. Капиталистлар белән экономик ярышта бу зур казаныш иде. Хәзер нефть промышленностенда хезмәт җитештерүчәнлеге аларныкыннан югары, һәр нефть бирә торган скважинадан без американлыларга караганда 15 мәртәбә күбрәк нефть алабыз. Соңгы 17 елда Советлар Союзы биргән нефтьнең өчтән бере Татарстан өлешенә туры килә.

Чияле тауда шыткан беренче орлык әнә шулай үсеп китте, мәгърур имән агачы кебек ныгып, тамырларын җәйде.

Республикабыздагы яшь индустриянең киләчәге тагын да матуррак. Бу бишьеллыкта без 100 миллион тонна нефть алырга планлаштырдык. Димәк, илебездә йөри торган машиналарның өчтән бере безнең бензин белән туеначак, илебездә оча торган самолетларның өчтән бере безнең ягулык белән очачак.

Чияле тауда нефть чыкканга бары ике дистә ел. Шушы егерме ел эчендә беренче капиталистик ил дә хыяллана алмаган биеклекләрне алдык без.

Ромашкино якларыннан чыккан кешеләрне без Татарстанның нефть мәйданнарында гына түгел, Оренбург далаларында да, Мангышлак ярым атавында да, Себер тайгаларында да очратабыз. Алар булган һәр җирдә, Чияле тау итәгендәге кебек үк, нефть фонтаннары ата, тирә-якны нурга күмеп, газ факеллары кабына.

һәм яңа җирдә яңа тамырлар җәелә. Көчле, куәтле тамырлар.

※ ※ ※

**Альберт Хәсәнов**

# КОНТРИБУЦИЯ

ОЧЕРК



Гыйльметдин абзыйның үзеннән алда Чияле тауга зур ящик белән посылкасы кайтып төште. Аны Кләүле станциясенә пар ат җигеп барып алдылар. Шулкадәр чит җирләрдән килгән ящикны «борын кычыткан өлеше булса да» күчтәнәч өмет итеп ишек алдына җыйналышкан күрше-күлән арбадан көч-хәл белән генә төшерделәр. Аны күргән кешеләр барысы беравыздан:

— Үзең кереп ятсаң, үзең дә сыярсың. Гыйльметдин абзый, бичараны әйтәбез, киләр белән генә тутырып бетерде икән моны, үзе таш тутыргандай авыр тагын, — дип гаҗәпләнделәр.

Кыен заманнар кичерә иде халык ул чакларда. Авыр сугышларны, ут-суларны кичеп тә башлары исән калган агайлар авылга, семьясы, туган-тумачасы янына буш кул белән генә кайтмадылар. Берсе шунда бала-чагасына, хатынына күлмәк-алъяпкычлык ситсы юнәткән, икенчесе озак еллар хыянәтсез көткән кара кашына яулыклык ефәк туры китергән иде. Үзем кимәсәм, малайларга бозып төктерергә ярар шунда дип, Чияле тауга әллә нинди мәзәк немец киемнәре җыеп кайтучылар да булды. Ачлыктан бигрәк кием-салым җитешмәү газаплый иде халыкны ул елларда. Әмма әлеге посылкада мануфактура-фәлән, ситсы-сукно ише әйберләр булмавы баштан ук сизелеп тора иде. Кием-салым салынган ящик тимер тутырган төсле авыр булмый инде ул. Ни генә әйтсәң дә, серле күренә иде әлеге посылка. Тышына әллә нинди аркылы-торкылы хәрефләр белән ят тамгалар төшерелгән сандыкка хуҗа хатын Миңҗамал җиңги үзе дә, ишек алдына җыйналган күрше-күлән дә, авылның берәр олырак кешесе белән киңәшми-нитми үз белдекләләнеп, тиктомалдан гына ачарга батырчылык итмәделәр. Ящик тирәсендә түгәрәкләнеп торган хәлдә, һәркем үзенчә сөйләнде. Берләре, сандык эчендә, мөгаен, аяклы тегү машинасыдыр, диген булдылар. Икенчеләре, әллә сөт аерткыч сепарат микән, дип тә баш ваттылар. Авыр сугыш кичергән авыл халкы өчен хуҗалыкка боларның икесе дә муеннан кирәк иде, әлбәттә. Шуңа күрә аларның фантазиясе дә көндәлек тормышка иң кирәк әйберләр, эш кораллары тирәсендә йөзә иде. Шулай аптырашып, һәркем үзенчә хыялланып утырганда, тавык фермасында каравыл торучы Кыяметдин бабай ишек алдына килеп керде. Кыяметдин бабай, китап буенча укымышы зур булмаса да, дөньяның ачысынтөчесен күп татыган, «лаеш шулпалары»н күп эчкән карт иде. Әле япон сугышларында ук батырлык күрсәтеп, Георгиевский медале алган кеше. Менә шуңа күрә дә,

Чияле тауның тышкы политикасына кагылышлы мәсьәләләрдә элек-электән авылда аннан да узып сөйләүчеләр булмады. Ә сугыш елларында, бөтен ир-ат халкы фронтка китеп беткәнлектән, җыен хатын-кыз, мыек чыкмаган малай-шалай арасында аның авторитеты тагын да күтәрелде.

Кыяметдин бабай килеп керү белән башта ящик тирәли әйләнгәләп чыкты. Кулындагы кәкре башлы чикләвек таягы белән аның стенасына суккалап алды. Аннары читкәрәк китеп басты, ул килү белән урнашкан киеренке тынлыкны тагын да куерта төшеп, ике-өч тапкыр тамагын кырып куйды. Халык аннан җавап көтә иде. Әмма карт ашыкмады. Баскан урынында сүзсез тора бирде.

— Ачуым килмәгәе, япун императорының табуты кадәр бар. Ящигын каян тапкан диген син аның, ә? — диде ул бераздан. Әмма аның бу сүзләре мәсьәләгә һичбер төрле дә ачыклык кертмәде. Кулларын алъяпкыч итәкләре эченә яшереп торган хатыннарның берсе:

— Әллә алтын микән моның эчендә, Кыяметдин бабай, күтәрә торган түгел бит, — дип куйды.

— Юк, алтын дигәнегез ат дагасыннан да зур булмый ул, — диде карт.

Әле тик быелгы җәйдән генә кәләпүшләрен кыңгыртрак салып йөри башлаган малай-шалайлар да, авызларын яулык читләре белән каплап читтәрәк торган абыстайлар да алтын кадәр алтынның шулай кечкенә булуына ышанып бетәселәре килми төсле тоелды аңа. Кыяметдин бабай шунда ук сүзенә төзәтмә кертергә ашыкты. Як-ягына каранып алды, ләкин чагыштырырдай нәрсә тапмады.

Аннары:

— Иң зурысы да аның бригад йортындагы күкеле сәгатьтән зур булмый, — дип куйды.

Картның бу сүзләреннән соң ерак җирләрдән килгән посылка тагын да серлерәк күренә башлады. Халыкның кызыксынуы тагын да артты. Ахырдан Кыяметдин бабай балта сорап алды, ящикка якынрак килде.

— Шушы Кыяметдин абзагыз әйтте, диярсез, — моның эчендә я ярма яра торган тегермән, я такта яру машинасының пулный камплексиясе, — диде. Карт учына төкереп һәм бисмилласын әйтеп, иплән кенә ящикның бер почмагын каерырга кереште. Карт тирәсендә кайнашкан Миңҗамал җиңги, кем ни дисә шуның сүзен хуплап:

— Бирсен ходай, нәрсә генә булса да артык мал булмас әле, игелеге белән бирә күрсен, — дип кабатлап торды.

Кыяметдин бабайның ящик эченнән тартып чыгарган беренче нәрсәсе, кат-кат итеп төргән майлы кәгазен актарып карасалар, күмер соскычына охшашлы ике япьле тимер кисәге булып чыкты. Аннан соңгылары да сепаратка да, аяклы тегү машинасы кисәкләренә дә аз охшыйлар иде. Кыяметдин бабай ящик эченнән бер-бер артлы я бәләк озынлыгы игәү, я шунда урак кебек кәкре тимер тартып чыгарды. «Мәһәр сандыгы» эченнән пычкы-бораү, кадак суыргыч ише нәрсәләр дә, тагын шунда бөтенләй аңлаешсыз, беренче карауга бик сәер тимер-томырлар да чыктылар. Ящикны инде бөтенләй бушатып бетергәннән соң, Кыяметдин бабай гадәтенчә күп мәгънәле итеп: «Әһһә!» — диде. Картның берәр төрле сорауга җавап тапмаганда әйтә торган сүзе иде ул. Әлеге тимер-томырларны тиз-тиз генә кире тутыра башлады. Бабай, барысын да кире тутырып бетергәннән соң, ящикны шартлатып кадаклап та куйды. Аннары Шөгердән яисә район тирәсеннән килеп чыгып, ящикны требовать итсәләр, бер сүздә торырга, ачмадык-нитмәдек, тимәдек-күрмәдек дип барырга, кәк китерделәр, тәк шулай тора дияргә өйрәтеп, титаклый-титаклый китеп тә барды...

## Тимерче сандалга юлыга

1945 елның апрель урталары иде. Җиргә көлтәсе-көлтәсе белән нурын сибеп, күктә җиңү кояшы елмая. Югарыда-югарыда, нәкъ күк гөмбәзе астында, берсеннән-берсе уздырышып тургайлар сайрый. Миналар, снарядлар белән актарылган, танклар белән тапталган Германия кырлары өстеннән дулкынланып-дулкынланып рәшә күтәрелә. Кояшның җылы нурлары астында берничә көн эчендә тугаерга өлгергән тополь бөреләреннән һавага әчкелтем рәхәт хуш ис тарала. Инде сугыш бетәргә дә күп

калмаган. Совет гаскәрләре Берлинны камарга, дошманны оясында туздырырга әзерләнәләр. Гыйльметдин агай Низаметдинов хезмәт иткән кыр госпитале дә алгы сызыкка тагын да якынрак китереп, хуҗалар ташлап качкан бер зур гына завод эченә урнаштырдылар.

Авыл кешесе үзенә кушканны гына үтәп, тыныч, мәшәкатьсез генә йөри беләмени ул. Бу гадәтен ул авыр, кыен сугыш шартларында да ташламый, күрәсең. Менә санитар Низаметдинов та шулай. Яралыларны караудан бушаган кыска ял вакытларында да тик тормый. Я шунда госпитальгә дустының хәлен белергә дип килгән офицерларның атын дагалап бирә, я булмаса, җиңен сызганып, яралыларны ташый торган арбаларны төзәткәләргә, күчәрләрен ныгытырга, көпчәкләренә кыршау сугарга керешә. Бөтен хуҗалыкка баш булып, тегесен рәткә китерә, монысын тәртипкә сала. Әле менә яңа урынга күченгәч тә, шул эшләр белән мәшгуль булды. Повозкаларны сүтеп-җыйнарлык, яңабаштан рәткә китерерлек берәр алачык чамалап завод ишек алды буйлап әзләнеп китте. Шулай йөри торгач, зур гына бер бина эченә килеп керде. Бүкәннәрдә рәт-рәт тезелеп торган сандалларны күреп, ул башта бөтенләй әсәрләнеп китте. Чияле тауда калган үз алачыгы күз алдына килеп басты. Ул да бит сугышка сандал яныннан аерылып китте. Сандал өстендә теш сугып бетермәгән тырмасы калды.

...Тормышка зарланмый иде ул. Егет булып килгән чорларда аларның Чияле тавында да зур үзгәрешләр булып куйды — аерым крестьян хуҗалыкларын күмәкләштерү башланды. Әтисе, мәрхүм Зыятдин ага, үзен ярлылар исәбенә кертми иде кертүен. Начармы-яхшымы аның үз һөнәре, үз алачыгы бар. Шул җиргә иңеп беткән алачыгы белән горурланып, үзен байга санап йөри иде ул. Әмма колхозга беренчеләрдән булып язылды. Аталы-уллы тимерчеләр шул яздан икәүләп, чын дәрт белән күмәк хуҗалыкның эш коралларын ремонтлый, рәткә китерә торган булып киттеләр. Ә алачык тирәсендә эш гел муеннан иде. Сабаннарын көйләп бетерсәң, чәчкечләре көтеп тора, инде аларын тәртипкә китердем дигәндә, ургычлар, лобогрейкалар чиратка баса. Тимерченең эше тавык чүпләп бетергесез. Җәен-кышын дигәндәй, колхозның бөтен ат сбруе, арбасы-чанасы аның кулыннан үтә. Болары өстенә я шунда «аш салып кунак дәшәрмен диган идем, менә казаным тишелде, зинһар, ямый күр», — дип, я самовар торбасын күтәреп, зинһарлап-гозерләп алачыкка абыстайлар, яшь киленнәр килеп тора. Аларны борып җибәреп булмый. Авыл җирендә тимерчедән башка кая барсыннар?

Әйе, зарланмый иде ул тормыштан. Чияле тауның ут уйнатып, очкын чыгарып эшләргә ярата торган тырыш кешеләре күмәкләшеп яшәүнең беренче елларында ук бура тутырып икмәк ала башладылар. Уңыш бәлү көннәре зур бәйрәмгә әйләнә торган иде. Колхозның авызлык тотмый торган нәсел айгырын җигеп, капчык-капчык бодай, арышын-борчагын Гыйльметдиннәр капка төбенә дә китереп бушаталар. Үзе өйләре каршына гына яңа бура да буратып куйды. Күрше Ялтауда вәгъдәләшкән кызы — Миңҗамалы бар иде аның. Матур күзләрнең берсендә, каз өмәләренәрәк туры китереп, аны менеп алып төште. Алдагы көннәргә дә исәп-хисаплары зур иде әле егетнең. Менә шушы каһәр суккан сугыш чыгып бөтенесен җимереп ташлады, челпәрәмә китерде.

Тимерче ул көнне дә алачыгында иде. «Сугыш, сугыш чыккан!» — дип акырып елап, алачыкка Миңҗамал килеп керде.

Кичтән мунча яктылар. Ә иртән юл капчыгына чәй-шикәр, сабын-сөлге, җылы оекбаш салып Гыйльметдин военкоматка юл тотты.

Тимерчене разведкага билгеләделәр. Күп тә үтмәде, аның күкрәгенә бер-бер артлы ике медаль эленде. Әмма дошман тылына озак йөрергә туры килмәде аңа. Чираттагы заданиедән кайтышлый каты яраланды, контузия алды. Берничә айлар госпитальдә ятып чыккач, врачлар аны хәрби хезмәткә яраксыз дип таптылар. Кыр госпитальләренең берсенә санитар итеп билгеләделәр. Шушында ул баш врач майор Носов кул астына килеп эләкте. Бик кырыс, бик төгәллекне ярата торган кеше иде майор. Баш врачны исенә төшерү белән, Гыйльметдин татлы уйларыннан айнып, госпитальгә ашыкты.

— Кирәгем чыгып куймагае тагын. Кайтырга кирәк, — дип куйды ул. Ләкин алай да сандаллар яныннан тиз генә аерылып китә алмады. Җирдә яткан бер тимер кисә-

ген элэктереп, аларның һәркайсына суккалап, рәтләр арасыннан үтте. Суккан саен аңа бик таныш, бик якын һәм бик сагынылган моңнар цех эченә тарала торды.

— Шушыларның берәрсен безнең Чияле тауга кайтарып куйсаң, бер дә харам булмас иде әле, — дип уйлап куйды ул.

Әллә каян гына башына килеп кергән бу фикер санитарлар бүлмәсенә кайткач та тынгылык бирмәде аңа. Ахырда түзмәде, култык астына капчык кыстырды да кичкырынлатып тагын цехка китте. Сандалларның арадан күңеленә ошаганнарын сайлап алды да бүкәннән сүтә дә башлады. Үзе як-ягына каранды, күрмәгәйләре тагы дип тә шикләнде. Немец-мазар күрүдән бигрәк, Носовка эләгүдән шүрли иде ул. Беләнитә калса, наряд белән генә котыла алмассың, трибуналга ук озатыр...

Гыйльметдин кайту белән сандалны үзләре тора торган йортның подвалына төшереп, төрле чүп-чар арасына яшереп куйды. Эштән буш араларда төшеп барлый, аның янында татлы уйларга чумып, янәдән-янә авылын — Чияле тавын исенә төшереп утыра, онытылып-онытылып татлы уйларга бирелә иде. Инде сугыш бетәргә дә санаулы көннәр генә калып бара бит, шунда берәр җаен китереп ничек тә үзебезнең авылга алып кайтып китәрмен әле бу сандалны дип хыялланды ул.

## Хәйләкәр майор

Ләкин эш Гыйльметдин абзый уйлаганча җиңел барып чыкмады. Фашистларның оясын туздырып, инде өйләргә таралышабыз дип көнә торганда, аларның госпиталенә көнчыгыш чикләргә күченү өчен әзерләнергә дигән приказ килде. Анда әле япон самурайларын тар-мар итәсе бар икән. Барасы юл ерак иде. Майор Носов госпиталь өчен бирелгән платформага иң кирәкле әйберләрне генә төяргә кушты. Әмма инде авыр сугышларны кичеп, үз урынында һәр нәрсәнең кирәген, һәр әйбернең кадерен белергә өйрәнгән солдат халкыннан ни генә артсын. Алар тегесен дә, монысын да төйи тордылар. Юлга алынырга тиешле әйберләрнең әле яртысы да урнаштырылмаган, ә инде платформада урын да бетеп бара. Шунда Носов үзе килеп чыкты. Бу хәлне күргәч, ул бар әйберне бушаттырып, яңадан төятә башлады. Майорның шунда санитар Низаметдиновның капчыкка төрелгән ниндидер авыр әйберне көч-хәл белән генә куеп маташканын күреп алды. Шунда ук санитар янына килде, капчыгын капшап актарып карады. Аның эчендә тимер кыйный торган гади сандал иде.

— Монысы нигә тагын?

— Иптәш майор, бик кирәге чыгуы бар аның, — диде Гыйльметдин. Үзе уңайсызлануудан керер җир тапмады. Майор бирегә сандалның каян килүен, аны кайдан, кем алганны сорашып та тормады.

— Ник, анда тапмабыз дисез мәллә? — генә диде ул.

— Мондые юк инде аның, иптәш майор.

Гыйльметдин шунда итек балтырыннан кашыгын тартып чыгарды. Сандалга чаңчаң итеп сугып та күрсәтте.

— Тавышы ук икенче аның, иптәш майор!

Кашыкны үз кулына алып майор да сандалга сугып карады. Вагон көпчәкләренә, рельска, башка тимерләргә суккалап алды.

— Аерманы сизәсезме? — диде ул, кызыксынып алар тирәсенә җыелышкан солдатларга эндәшеп. Тегеләре ни дип әйтергә дә аптырап иңбашларын җыерыштылар.

— Менә шул шул, һәр эшкә үз остасы, үз белгече кирәк, — диде майор. — Әйдә, синеңчә булсын!

Шулай итеп немец сандалы еракларга, җир шарының икенче читенә, Манчжуриягә, Кытай, Корея чикләренә китеп барды. Бу җирләргә килеп чыккач, Гыйльметдин абзый сандалны яшереп маташмады инде. Аны ике көпчәкле аерым повозкага беркетеп куйды. Бөтен кирәк-яракны, берәр нәрсә төзәтәсе, ямисе көйлисе булса, гел шуның өстендә генә эшләде. Операцияләрдән, яралыларны караудан бушаган, ял иткән чакларында Гыйльметдин абзый янына майор Носов та чыгып утыргалый иде.

Шундый чакларда майор санитарның кайдан булуын, кем булуын, сугышка кадәр ни эшләвен — барысын да, барысын да сорашып бетерде. Ул үзе дә Идел буеннан булып чыкты. Сугышка чаклы зур больницаларның берсендә эшләгән икән.

Япон самурайларын тар-мар итү озакка бармады. Җиңү көненнән соң, туган якларына кайтырга җыенган Гыйльметдин абзый тагын майор янына килде. Аннан әлеге сандалны үзе белән алырга рөхсәт сорады. Майор күлүгә бик юмарт булмаса да, бу юлы түзмәде, рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Ләкин Гыйльметдин абзыйның нияте нык иде.

— Колхозда эш муеннандыр. Сандалсыз анда ике кулсыз инде мин, — диде.

Носов эндәшмәде. Ниндидер уйга чумып, байтак вакыт сүзсез утырды. Аннары кинәт кенә урыныннан торды, өстен киенде. Гыйльметдин абзыйны да үзе белән ияртеп, бүлмәдән чыгып китте.

Майор Носов Гыйльметдин абзыйны дивизиянең хуҗалык складына алып килде.

Нинди генә инструментлар, эш кораллары юк иде биредә. Ишләре-ишләре белән идәндә яталар, стеналарда да эленеп торалар. Балталар, пычкылар, чүкечләр һәм тагын күп төрле башка эш кораллары шүрлекләрдә дә күп. Баш врач әле берсен, әле икенчесен кулына алып, әйләндергәләп-әйләндергәләп карап озак кына йөрде. Аннары бер почмакта яткан өемгә күрсәтеп, гадәтенчә кинәт кенә:

— Болары нәрсә? — диде. Аларны күргәч, Гыйльметдин абзыйның хәтта күзләре очкынланып китте, беразга тотлыгып калды. Носов тимер әйберләргә резьба сырлый торган ачкычлар бәйләмен күрсәтә иде.

— Миндә булса, кадерен белер идем мин боларның! — дип кенә әйтә алды ул. Майор эндәшмәде, Гыйльметдин абзыйның сүзләренә әллә ни игътибар да итмәде бугай. Үзен озатып йөрүче старшинага әлеге ачкычларны бер читкә алып куярга кушты һәм алга атлады.

— Бу кәкреләре нәрсә тагын?

— Ат тоягын кисә торган пычаклар бит. Авыл җирендә бик кирәк нәрсә инде, иптәш майор.

— Читкә алып куегыз. Монысы?

— Борау бу, иптәш майор. Тимерне тишә торганы.

— Моны да читкә алып куегыз.

Майор Носов белән алар складта сәгатьтән артык актарындылар. Госпиталь начальнигының тикшермәгән, тотып карамаган инструменты калмады. Нинди генә эш коралына юлыкса да, аларның берәр данәсен читкә алып куйдыра барды. Тора-бара ул сайлатып алган эш кораллары бер өем булып өлгерделәр.

— Гражданкага кайткач, бу үзе дә я слесарьлык, я тимерчелек белән шөгыльләнмәк була инде, күрәсең. Шулай булмаганда бу кадәр инструмент җыймас, нинди тимер эш коралының нинди урында кулланылуын бу кадәр җентекләп төпченмәс иде, — дип уйланды эченнән Гыйльметдин агай. — Үзе тимерче була торып та, шундый кирәкле эш коралын әйтми калган дип, соңыннан миңа үпкәләсе булмасын тагын...

Өем һаман үсә, анда төрле эш кораллары арта, өстәлә барды...

Шуннан соң Гыйльметдин абзый озак хезмәт итмәде. Демобилизацияләнеп, туган якларына, Чияле тауга кайтып китте. Авылда аны, абзыйның үзеннән алда кайтып җиткән, бөтен халыкның исен китәргән әлеге серле посылка көтә иде. Монысын баш врач тырышкан иде инде. Шаян да кеше булган икән бу майор Носов! Складта бергәләп сайлап алган эш коралларының ник берсен калдырсын. Барысын да яхшылап майлатып, кат-кат кәгазьгә төрдереп салдырган. Рәхмәт яусын үзенә!

## Миңҗамал җиңги дә контрибуция таләп итә

Посылка килүгә атна-ун көн узмагандыр, кызыл йолдыз таккан пилоткасын кыңгыр салып, күкрәк тулы медальләрен зыңгылдатып, Гыйльметдин абзый үзе кайтып килде. Юл капчыгы авыр күренә иде аның, аттан төшкәч, ишек алдына көчкә күтәреп керде. Миңҗамал җиңгинең башта капчыкка күзе дә төшмәде. Яраланып, күп каннар коеп та иренең авылга исән-сау үз аягы белән кайтып керүе аның өчен чиктән ашкан шатлык иде ич. Инде бер кат күрешкәч, чәйләр эчкәч кенә һәм юл капчыгына Гыйльметдин абзый үзе барып тотынгач кына, нидер көткәндәй тынып калды. Әллә инде, күл-

мәклек ефәк, я шунда батист яулык чыгармы дип көтте. Ә хуҗа исә, үзе юкта тәмам кибеп, коргаксып, кагылмас борын янтаерга торган урындык өстенә бер башы чәйнек борыны төсле очлы, үзе шактый гына зур тимер бүкән чыгарып утыртты. Урындык бөтен буыннары белән шыгырдап куйды.

— Чү, монысы ни инде тагын, ходаем?

— Күрмисеңмени, сандал ич, анасы! — диде Гыйльметдин абзый, Миңҗамалының бик гаҗәпсенүенә исе дә китмичә.

— Нинди сандал? Әллә шул тимерне күтәреп кайттыңмы?

— Безнең алачыктагы төсле прастуй сандал, тимерче сандалы. Немецнекен алып кайттым. — Гыйльметдин абзыйның күңеле күтәренке иде. Ул хисләргә бирелеп сүзен дәвам итте: — Кайтышлый карап кайттым, авылда эш муеннан икән, бу сандалда тимер кыйныйсылар бар әле.

Миңҗамал җиңги сугыш кадәр сугыштан исән-сау котылып кайткан ирен тиктомалдан гына аптыратмады, әллә нәрсәләр сорап йөдәтмәде. Әмма шулай да атна ун-көн чамасы узгач, балаларның өс-башын ямаштырып утырган җиреннән кинәт кенә башын күтәреп:

— Җыен тимер-томырны, кеше ташлап калдырганны җыеп кайткансың. Шунда әзрәк өс-башыңны карарга ярамагандыр. Безгә булмаса, үзең турында кайгыртыр идең. Һаман яшел гимнәчтүркәң белән йөри алмассың бит, — дип беренче кичләрне әйтмәгән үпкәләрен белдерде.

— Менә йорт өстебезгә ишелергә тора. Алмашка өс-баш юк. Ә ул, тиле баш, поты-поты белән тимер-томыр күтәреп кайта. Утлар кичеп тә акыл кермәгән икән үзеңә. Әнә Кләуледә вагоннан орлык бушатырга баргач, без фатирга кергә торган кешене күрсәң син. Ул да германнан кайткан солдат. «Минем баш эшләде, ни очраса, шуны җыеп йөрмәдем. Куенга мең ыштук тегү машинасы энәсе тыктым да кайттым», — дип мактана. Шул кеше: «Германнан алып кайткан энәләр хисабына йорт өлгерттем», ди. Ак мунчасы да бар. Ишек алды тулы мал-туар. Бу сүзләрне үз колагым белән ишеткәнем бар. Кеше ирләре менә бит ул нинди. Ә бу тимер-томыр җыеп кайткан. Аларны киеп тә, ашап та булмый лабаса.

Гыйльметдин абзый, башын кашып, туза башлаган тез башларын уыштырып, хатынын бүлдермичә тыңлап утырды. Аннары, тегесе туктагач кына, кырыс итеп:

— Андыйлар белән рәттән куясы булма мине и бетте. Крахабур диләр иде аларны бездә, алар белән ызнаться не желаю, — диде ул.

Әмма Гыйльметдин абзыйга хатынының сүзләре бер дә тәэсир итми калмады, әлбәттә. Күпләрнең якын торын мәңгегә алып калган сугыштан икенче берәүләрнең баеп калу өчен файдаланырга маташулары аның йөрәген әрнетте. Ишек катында торган сандалны ул кабат каршысына алып куйды.

— Беләсең килсә, шуны әйтәм, — диде ул. — Мин бу сандалны контрибуция өчен алдым.

Миңҗамал җиңги иренең бу сүзләрен башта сагаебрак кына тыңлап торды.

— Анысы ни инде тагын? Сүләсәң, ачыклабрак сүлә! — дип сорап куйды.

— Шундый пүрәдеге бар аның, анасы, — диде Гыйльметдин агай, инде бераз тынычрак тонга күчеп. — Менә, ызначыт, мин әгәр күрше Гаптери абзыйларның тәрәзәсен кереп ватам икән, ул минем өстән авыл Советына барып жалу бирә. Совет карары буенча, мин аңа берсүзсез тәрәзәсен куеп бирергә, я ыштыраф тиеш булам. Германия дә безгә шулай. Сугышта китергән зыянын, ягъни контрибуция түләргә тиеш. Мин немецтән безнең Чияле тауга да контрибуция түләтәм. Мин фронтка киткәндә алачыкта сандалым калдымы? Калды. Ул кая китте? Сандалыңны алып танк коярга озаттык дип яздыңмы? Яздың. Ул танкны немец бәреп яндырдымы? Яндырды. Менә шулар өчен контрибуция түләттем мин алардан. Заводларының эченә кереп, иң яхшы сандалларының берсен сайлап алдым.

Миңҗамал җиңги, иренең сүзләрен бик килештереп бетермәсә дә, дикъкать белән тыңлады. Мәсьәләнең төбенә төшәргә тырышты, күрәсең.

— Кантр-мантр бусия, имеш. Ә миңа диган мантрибутсияң кая?

Кулындагы энәсен изүенә кадады да Миңҗамал җиңги инде аяк терәп сөйләп китте:

— Давай, кантр-мантрларын немецлар миңа да түләсеннәр. Әле җиргә дә басмаган чүсинкәмнә фронтка озаттыммы? Озаттым. Ничәмә-ничә кием җылы оекбаш, бармакчалы биялиләр бәйләп бирдемме? Бирдем. Иңбашымдагы соңгы шәлемне салып бер чиләк арышка алыштырып алдым. Шулай булгач, миңа да мантрибутсия тиешме? Тиеш. Андый пүрәдеге бар икән, бик әйбәтләп кенә миңа да түләсеннәр. Бер пәлтәлек плүш кыстырып кайтсаң, иллаһи әйтәм, миңа да бер дә хәрәм булмас иде. Бик рәхәтләнеп, бик киерелеп киеп йөргән булыр идем әле.

Политикага килгәндә Миңҗамал җиңги Гыйльметдин агайның үзеннән дә болайрак булып чыкты. Ул моны вакытында сизеп, сүзне озакка сузмаска булды.

— Ташлыйк әле булмаса, анасы, — диде ул. — Алачыкта шушы сандал чыңнары гына чыңлый башласын, барысы да җайланыр. Сиңа да плүш пәлтәлек юнәтербез. Колхозны да аякка бастырырбыз. Иң авыры артта калды инде.

Аннары урыныннан торды да, тәмәкесен кабызып, тышка чыкты.

## Тимерче һөнәре — изге һөнәр

...Чияле тауны икегә аерып кечкенә генә инеш ага. Авылдан чүт кенә өстәрәк, шул инеш ярына сыенып, башын шифер белән япкан тимерче алачыгы утыра. Лениногорск районының тимерчесе Гыйльметдин абзый Низаметдинов алачыгы инде бу. Еллар уза тора, алачык каршындагы инеш ага да ага. Гыйльметдин абзый алачыгында җәен дә, кышын да, иртәсен дә, кичен дә дигәндәй, тимер чыңы өзелми. Хәзерге катлаулы техника заманында, һәр колхозда төзекләндерелгән механика мастерскойлары барында да тимерченең эше күп. Колхозларда зур-зур токарь станоклары, автоген, сварка аппаратлары булуга да карамастан, тырма ясау, чәчкечләрне көйләү һәм башка күп төрле эшләр, арба-чана, ат сбруйларын карау әле һаман да тимерче өстендә. Болардан кала, авыл халкы үзе дә көн дә әлеге гап-гади тимерче ярдәменә мохтаҗ. Берсенә ишек тупсасы, икенчесенә капка келәсе кирәк. Алам дигәндә генә кибетендә булып тормый, тагын тимерчегә йөгерергә туры килә. Лениногорск районының «Дружба» колхозы җитәкчеләре дә шулай уйлыйлар, тимерченең кадерен беләләр бирәдә. Узган елны алар Гыйльметдин абзыйга башын шифер белән ябып яңа алачык салып бирделәр. Контрибуциягә Германиядән алып кайткан сандал әле хәзер дә җиңүчеләргә хыянәтсез хезмәт итә, бурычын түли.

Металл үзгәрми, кешеләр картая. Соңгы вакытларда сандал өстендә чүкечне күбрәк Гыйльметдин абзыйның уллары Марсель һәм Равил биетәләр. Тимерче һөнәре — изге һөнәр. Ата-бабадан килгән изге һөнәргә хыянәт итү юк ул Чияле тау халкында...

◇ ◦ ◇

**Гомәр Саттаров**

# ҖИРЛЕ ГЕОГРАФИК АТАМАЛАР СҮЗЛЕКЧӘСЕ

Туган республикабыз һәм аның күрше өлкәләрендәге географик атамаларның (авыл, шәһәр, елга, тау, күл исемнәренең) барлыкка килү сәбәпләрен, чорын һәм лексик мәгънәләрен өйрәнү бу җирлектә яшәгән халыкларның тарихы, теле, гореф-гадәтләре, тормыш шартлары турында күп кенә фәнни мәгълүматлар бирә.

Шуның өчен дә соңгы елларда рус, украин, үзбәк, казакъ һәм башка телләрдә җирле географик атамаларының килеп чыгышын яктыртуга багышланган махсус сүзлекләр чыкты. Казан университетының татар теле кафедрасында, татар географик атамаларының топонимик сүзлеген төзү өчен, материал туплау һәм җыелган материалларны өйрәнү эше алып барыла. Һәр атамага карата аерым мәкаләләр язылып, аларда татар җирле географик атамаларының килеп чыгышы аңлатыла. Шундый топонимик сүзлек-статьяларның берничәсе укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

Казан шәһәренең кайчан салынуы, исеме хакында риваятьләрдә һәм елъязмаларда күп төрле, әмма каршылыклы мәгълүматлар сакланган. XVI гасыр башларында язылган елъязмада: «Иске Казанга Саин хан (Батый хан) нигез салган, бу 1252 нче елларга туры килә», диелә. П. Рычковның «Опыт Казанской истории...» исемле китабында Казан топонимының килеп чыгышына карата ике төрле фикер үткәрелә.

П. Рычков Казан суы буенда болгарлар яшәгәннәр, төбе чоңгыллы, казылмалы-казанлыклы булганга, бу елганы Казан дигәннәр, шәһәр исеме әлеге елгадан алынган булса кирәк, ди. Казан атамасы елга исеменнән алынган дигән фикергә кушылсак та, елганың үзенә исем аның чоңгыллы булуыннан, ягъни төбенең тигезсезлегеннән чыгып бирелгән, дип карый алмыйбыз. Төбе казылмалы-казанлыклы булу — һәр елгага хас сыйфат[1]. М. Пинегин дә Казан елгасына төбе казанлыклы булганга «Казан» дип исем бирелгән, елга исеменнән Казан шәһәре исеме алынган дигән карашны үткәрә.

П. Рычков шулай ук Казан шәһәренең татарлар килгәч төзелгән булуы һәм аның исеме Казан-Солтан яки Саин хан исеменнән алынуы да мөмкин, ди. Профессор Карл Фукс («История города Казани», 1817), Казан елгасының кеше исеме белән бәйләнешле булуын инкарь итмәсә дә, шәһәр Саин тарафыннан төзелгән һәм аның исемен йөртә дигән фикергә каршы килә. Саин кеше исеме түгел, «бик яхшы» дигән мәгънәне белдерә торган гади сүз генә, ди ул. Ш. Мәрҗани фикеренчә, Казанга

[1] Шәһәргә исем салынган урынының чокыр-чакырлы, казылмалы-казанлыклы булуыннан чыгып алынган дигән караш та бар. Ләкин Иске Казан урнашкан урында күзгә ташланырдай казанлыклар юк. Шуңа күрә, атама утырган урынының рельефы үзенчәлегеннән алынган дип санау нигезсез. Галим-топонимист В. А. Никонов та «Краткий топонимический словарь» дигән хезмәтендә болай аңлатуның ышандырмавын әйтә.

нигез салучы кеше — Алтын Урда ханнарыннан берсе Сартак хан. Профессор Н. Ф. Катановның «Казан татарларының тарихи җырлары» исемле хезмәтендә Казанның салына башлавы 1290 еллар белән күрсәтелә. М. Пинегин дә «Казань в ее прошлом и настоящем» (Спб, 1890) дигән китабында иске Казанга 1290, яңа Казанга 1394 елда нигез салынган дип яза. Бу соңгы караш фәнни мәгълүматларга да нигездә туры килә. Тарихчы һәм археолог Н. Ф. Калинин Иске Казанның салынуын XIII гасыр урталары белән билгели. 1951 елгы археологик экспедиция биредә 1280 елларда куелган кабер ташы таба. Хәзергә XIII гасыр башына яки аннан да элгәрәк чорга караган әйберләр табылганы юк. Шуларга нигезләнеп, Н. Ф. Калинин Иске Казанга якынча XIII гасыр урталарында нигез салынган дигән фикергә килә.

Фәндә Иске Казанга Баян ханның улы Казан хан нигез салган һәм шәһәр аның исеме белән аталган дигән караш та яши. Мәгълүм булганча, Казан хан 1338 еллар тирәсендә Чыгтай олысында хакимлек иткән. Аның исеме язылган металл акчалар сугылган һәм ул акчалар Болгар иленә дә таралган. Хәлбуки, истәлекләр, елъязмалар һәм кабер ташлары исә Иске Казанга шактый элгәрәк, XIII гасыр урталарында яки азакларында (1280—1290 елларда) ук нигез салынуын хәбәр итәләр. Менә шуңа күрә, Баян улы Казан хан Иске Казанга нигез салган һәм шәһәр аның исеме белән аталган дип әйтә алмыйбыз.

Туктамыш хан белән Аксак Тимер арасында барган сугышта (1390 еллар) Казан-баһадир, Казанчы (Каранчы)-баһадир исемле гаскәр башлыкларының катнашуы билгеле. Әмма алар шәһәр салу белән шөгыльләнмәгәннәр, киресенчә, тыныч шәһәрләрне җимергәннәр, ватканнар гына.

Риваятьләргә караганда, Иске Казан 104 ел яшәгән. Казан кнәзьлеге XIV гасыр азакларында бик нык көчәйгән һәм аның биләмәләре дә киңәйгән, башкаласы Казан елгасы тамагындагы (Иделдән 3 км ераклыктагы) Елантауга күчкән. Елантауга салынган башкаланы Яңа Казан дип атаганнар. Легендалар һәм елъязмалардан калган өзекләр буенча, Аксак Тимер Бөек Болгар шәһәрен 1391 елда тар-мар иткән. Яңа Казан шәһәренә Болгарның соңгы ханы Габдулланың улы Алтынбәк нигез салган һәм аның беренче ханы булган [1]. Бу, якынча, 1394 елларга туры килә. Борынгы бәетләрдә Иске Казанга 1290 елда нигез салыну турында сүз алып барыла дигән идек. Шушы датага аның 104 ел яшәү гомерен кушсак, башкаланың Елантауга күчүе нәкъ 1394 елга туры килә. Бу елны хәзерге Казанның корыла башлау датасы итеп карый алабыз. Тарих фәннәре докторы, профессор М. Г. Сафаргалиев тә «Алтын Урданың таркалуы» (1960) дигән хезмәтендә хәзерге Казанның салына башлавын 1394—1402 еллар белән билгели. Рус елъязмаларында 1395—1396 елларда хәзерге Казан беренче мәртәбә телгә алына. Казан XV гасыр башларында Кремль урынына күчереп салына һәм үсә, зурая бара.

Татарстандагы җир-су исемнәрен тикшерү, анализлауга нигезләнеп, Казан атамасын түбәндәгечәрәк аңлатырга мөмкин.

Республикабызның берничә районында Казиле, ә Кама тамагы һәм Арча районнарында Кариле һәм Казиле авыллары бар. Биредә «р» һәм «з» тартыкларының чиратлашуы (ротацизм күренеше) белән очрашабыз. Бу атамалар кушма тезелеш тәшкил итәләр (каз — кар+иле) һәм ганлә, союз, авыл, җир биләмәсе, дәүләт төшенчәсен белдерәләр. Күчмә төрки кабиләләр җәмгыятендә ыруглык һәм кабиләчелек мөнәсәбәтләре хөкем сөргән заманда «ил», «йорт» сүзләре ыруг, кабилә оешмаларын яки кабилә союзына берләшкән кешеләр коллективын аңлаткан. Бу сүзләр ыруг яки кабилә биләгән территория (соңрак авыл) төшенчәсендә дә кулланылган.

Казиле, Кариле атамаларының аергыч өлеше (каз — кар) бу авылларның «каз» дигән борынгы төрки кабиләгә нисбәтле булуын белдерә [2]. Хайваннар тотемы белән

---

[1] Казан шәһәре турындагы легендаларның берсендә Алтынбәкнең, бу якларга килеп чыккач, хезмәтчесенә елгадан алтын казан белән су алып менәргә кушуы, шул чак казанның суга төшеп югалуы һәм шуннан соң елгага Казан исеме бирелүе, шул урында салынган шәһәр Казан дип аталуы турында сөйләнә. Шәһәр Болгар кнәзе Алтынбәк кушуы буенча салынган дигән фикер белән килешсәк тә, елга һәм шәһәр исеме алтын казанга бәйле рәвештә барлыкка килгән дип аңлатуның фәнни нигезе юк.

[2] Чувашиле (Биектау районы), Нугай иле (Ульяновск өлкәсе) дигән исемнәр дә элек биредә чувашлар һәм нугайлар яшәвенә ишарә ясый.

бәйләнешле кабилә һәм халык исемнәре борынгы төрки кабиләләр арасында киң таралган була. Мәсәлән, төрекмәннәрдә хәзер дә «т ә к ә» һәм «с а р ы к» дигән кабиләләр бар. Балага хайваннар, кош-кортлар, үсемлекләр исемен бирү йоласы шушы борынгы ышанулар белән бәйләнгән. Моның татарларга да хас булуын күп кенә авылларда сакланган, борынгыдан килә торган исем-кушаматлар раслыйлар. Аларның нигезендә борынгы кеше исемнәре ята һәм күбесе хәзер аерым бер нәселнең исеме яки фамилия функциясендә кулланылалар. Мәсәлән, Ч ы п ч ы к нәселе, К а р г а нәселе, А л а б у т а нәселе, А ю нәселе, К ү к е нәселе һ. б.

Тарихчы Ю. Б. Симченко XVII йөздә Икенче Бабасан волостенда яшәгән тобол татарларының тотемы к а з булуы, к а з а я г ы тамгасын волость билгесе итеп һәм шәхси имза урынына куллануы турында яза. Татарстанда да байтак кына авылларда Октябрь революциясенә кадәр имза урынына каз аягы тамгасы куйган нәселләр булган.

К а з к а б и л ә с е шушы җирләрдә болгарларга чаклы яшәгән төрки кабиләләрнең берсе булырга тиеш. Географик атамаларның таралышына карагандa, алар К а з а н, М и ш ә (Лаеш өязендә унбер Казиле авылы була, хәзерге Питрәч районында берничә Казиле авылы бар) һәм К а м а е л г а л а р ы буенда яшәгәннәр. Безнеңчә, составларында «каз» сүзе булган географик атамалар шушы кабилә исеменә бәйле рәвештә барлыкка килгән. Профессор А. И. Попов борынгы вакытта күп кенә объектларга аның кемнеке, кайсы ыруг, кабилә яки халыкныкы булуыннан чыгып исем бирелгән, шушы юл белән кабилә, халык исемнәренә нигезләнгән борынгы географик атамалар барлыкка килгән дигән фикер әйтә[1].

Безнең уебызча, Казан атамасы Казан елгасы исеменнән алынган. Елга атамасы үзе исә борынгы каз кабиләсе исеменә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән. Казан — каз кабиләләре елгасын, буйларында каз кабиләләре яши торган елга төшенчәсен белдергән.

Физик-географик объект булган Казан елгасының исеме, һичшиксез, тарихи-административ объект — Казан шәһәре исеменнән борынгырак, ягъни башта елга исеме, аннары шәһәр исеме барлыкка килгән.

А д м и р а л т е й с т в о б и с т ә с е. Татарлар Бишбалта бистәсе дип йөртәләр. Петр I кушуы буенча, 1718 елда Казан елгасы тамагына адмиралтейство корыла һәм аның тирә-ягында зур гына бистә барлыкка килә. Адмиралтействода хәрби корабльләр төзү верфе була. Шушы верфьтә корабльләр төзү өчен дәүләт крестьяннары Казан губернасындагы урманнарда бик күп имән, нарат агачлары кисканнәр. Аларны немец сүзе белән «лашман» дип атаганнар. XVIII гасырның II яртысында татар крестьяннарының яртысы лашманчылык хезмәтендә булган. Татарстанның Чирмешән районындагы Л а ш м а н а в ы л ы н ы ң, Саба, Арча районнарындагы Л а ш м а н ю л ы н ы ң һәм XIX гасыр башларында иҗат ителгән «Л а ш м а н б ә е т е» нең исемнәре шушы гаять авыр хезмәт белән бәйләнешле. Шул чорда телебездә «л а ш м а н ү г е з е», «л а ш м а н б и я с е» (таза, нык, көчле мәгънәсендә) дигән фразеологик тезмәләр ясала һәм кулланышка керә.

Б и ш б а л т а а т а м а с ы борынгы вакытта татарларда балага нык, каты әйберләрнең исемен бирү йоласы булу белән бәйләнешле. Бу исә бала таза булсын, авыруларга бирешмәсен дигән теләктән чыгып эшләнгән. Балта — хуҗалыкта еш кулланыла торган каты әйберләрнең берсе. Шуңа балта сүзен ир кешегә исем итеп тә кушканнар: Б и ш б а л т а, Б а л т а ч, Б а л т а й, Б а л т а к о л, Б а л т а б а й, Б а л т а н, Б а л т а һ. б. Кылыч, к у с а р, т и м е р, х ә н җ ә р, у р а к кебек каты коралларның исемен дә ир балага бирү гадәте булган. Бишбалта исемендә баланың биш балтага торырдай нык булуын теләү чагылыш тапкан. Б и ш б а л т а, кеше исеменнән авыл һәм соңыннан бистә исеменә күчеп, бүгенге көнгәчә сакланган.

А р ч а п о с е л о г ы, А р ч а к ы р ы һәм А р ч а у р а м ы (соңгы икесе Казанда) атамаларының нигезендә удмурт халкының борынгы исеме «ар» ята. Чуваш тарихчысы П. В. Денисов «ар» сүзе «урман кешеләре» төшенчәсен белдергән дигән карашта тора[2]. Борынгы төрки телдә «ар» сүзе «ир», «ир кеше» мәгънәсендә кул-

---

[1] А. П. Попов. Географические названия. М.—Л. 1965 ел. 21 бит.

[2] П. В. Денисов. Религиозные верования чуваш. Чувашгосиздат. 1959 ел. 42 бит.

ланылган[1] Арча топонимы (атамасы) «ар» тамырына «ча» кушымчасы ялганып ясалган. Ча, чә кушымчалары исә, төрле сүз төркемнәренә караган сүзләргә ялганып, әйбернең һәм билгенең кечкенәлеге төшенчәсен белдергән исем ясыйлар: сүзлекчә, салкынча һ. б. Арча поселогы да борынгы заманнарда арлар яшәгән кечкенә генә бер авыл булган булса кирәк.

Котлыбөкәш — Татарстанның Балык бистәсе районындагы авыл исеме. Бу сүз ике тамыр кушылып ясалган: котлы + бөкәш. Кот, котлы сүзләре борынгы телебездә җан, бәхет, тәбрик, матур-чибәр мәгънәләрендә кулланылган. Котлыбөкәш атамасында «котлы» сүзе «бәхетле» мәгънәсен белдерә. «Бөкәш» сүзенең мәгънәсе хәзергә аңлашылмый. Бүке (бүкәш, бөкәш) борынгы төрки тел ядкарьлары Орхон-Енисей язмаларында баһадир кеше, герой, батыр мәгънәсендә йөри. Бу исем белән мифик герой, образ аталган булса кирәк. Татарларда елаган баланы: «Елама, бүки килә», дип, куркытып юату гадәте булган һәм хәзер дә кайбер кешеләр шулай итәләр. Димәк, Котлыбөкәш — бәхетле, баһадир, герой дигән мәгънәне белдерүче кеше исеме булган һәм авыл исеменә әверелеп телебездә сакланган. Татарларда Букаев фамилияләре очравын да әйтергә кирәк.

Хансывар — Баулы районындагы авыл. Янсывар һәм Нырсывар — Питрәч районындагы татар авыллары. Бу топонимнар да шушы авылларга нигез салган кешеләрнең исемнәреннән ясалганнар. Хансывар — хан + сөяр; Янсывар — җан + сөяр, ә Нырсывар — нәр + сөяр төзелмәсеннән гыйбарәт. Болар өчесе дә төзелешләре ягыннан хәзерге телебездә кулланылышта актив йөри торган Илсөяр дигән кушма исемгә тәңгәл киләләр.

Хәзер «нәр» сүзенең мәгънәсен ачыклыйк. Нәр — чырай, бит, йөз сүзләренең синонимы. Ак чырайлы кешене «нөрсез», «нөре юк», «нөре качкан» (төсе киткән мәгънәсендә) диләр. Саба районының Оет авылында бу сүз «норсыз» формасында (ямьсез, юньсез мәгънәсендә) кулланыла. Димәк, Нырсывар йөзсөяр дигән мәгънәне белдергән. Борынгы телебездә «сөяр» сүзе калын әйтелеш белән «сывар» рәвешендә кулланылганга, ялгызлык исеме буларак бергә кушып әйтү процессында «нөр» сүзе дә калынайган, нор !! ныр формасын алган.

Зур Нөркәй, Кече Нөркәй (Сарман районындагы авыллар) атамаларында да әлеге «нөр» сүзе белән очрашабыз. Бу сүз, иркәләү-кечерәйтү кушымчасы «кәй» ялганып, кеше исеме булып кулланылган. Нөркәй татарларда Йөзкәй исеме белән мәгънәдәш булган (хәзер дә Нөркәев, Юзкаев дигән фамилияләр бар). Нөркәй сүзе шулай ук кеше исеменнән авыл исеменә күчкән. Зеленодольск районы Мулиле авылы кырында Нөркә сазы, Нөркә күпере дигән микротопонимнар бар. Биредә Нөркәй исеме азагындагы «й» авазы төшеп калу факты белән очрашабыз.

Мәлки — Апас районындагы бу авылның исеме шулай кыскартылган. Аның беренчел формасы Мәүлакәй булырга тиеш. Гарәп теленнән кергән мәүла сүзе берничә мәгънә белдерә: ия, хуҗа, яхшылык итүче, дус, колын азат итүче, алланың эпитеты[2]. Шушы сүзгә татар телендәге иркәләү-кечерәйтү кушылмасы «кәй» ялганып, Мәүлакәй дигән кеше исеме ясалган. Фонетик үзгәрешләр кичерү нәтиҗәсендә, «Мәүлакәй»дән «Мәүләки», аннан «Мәлки» барлыкка килгән. Мәүла сүзе үзе һәм аның кушымчалар яки сүзләр кушылу юлы белән ясалган төрләре татарларда кеше исеме буларак күптәннән кулланылган: Мәүла, Мәүли, Мәүләви, Мәүлихан, Мәүлабай, Мәүлиҗан, Мәүләдетдин, Мәүлакол, Мәүлия, Мәүлиҗиһан, Мәүлиҗамал, Мәүләбикә һ. б.

Килдеураз — Буа районындагы авыл һәм тимер юл станциясе исеме. Кеше исеменнән алынган. «Ураз» борынгы төрки телдә «бәхет» мәгънәсендә йөргән. Килдеураз «килде бәхет» төшенчәсен белдерә. Бу топоним кире сүз тәртибе тәшкил итүе белән дә игътибарга лаеклы. Монда беренче урында хәбәр (килде), икенче урында ия (ураз) килә. Килдебәк, Бирдебәк, Туктагул (тукта кол), Килдеиш һ. б. топоним һәм кеше исемнәрендә дә шушы күренеш белән очрашабыз. Боларда телебездәге борынгы форма сүз ясалыш ысулы сакланган.

---

[1] С. Е. Малов. Памятники древнетюркской письменности. М.—Л. 1951 ел. 365 бит.
[2] Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. Казан. 1965. 346 бит.

Бугруслан — Оренбург өлкәсендәге шәһәр. Бу шәһәрнең атамасы Богаарслан дигән кеше исеменнән алынган булса кирәк. Бога сүзе борынгы төрки телдә «үгез» дигән мәгънәдә йөргән. Тара татарлары хәзер дә үгезне «бога» диләр. Шушы мәгънәсендә бога сүзе борынгы венгр теленә кабул ителгән. Рус телендәге «бык»та «бога — бука»дан килеп чыккан дигән караш бар. Богаарслан исеме кеше белән хайваннарның килеп чыгышлары уртак дип карауга нигезләнгән борынгы тотемик дини ышануга барып тоташа. Әтисе арслан ыруыннан, әнисе бога ыруыннан, яки киресенчә булган ир балага Богаарслан дигән исем бирелгән. Бу исемне кушканда, баланың үгез кебек көчле, арслан кебек сизгер, җитез, кыю һәм батыр булуын теләү ырымыннан чыгып та эш ителгән. Богаарслан сүзе кеше исеме буларак хәзерге телебездә кулланылыштан төшсә дә, фамилиягә (мәсәлән, Зеленодольск районы Татар Танае авылында Бугруслановлар бар) һәм топонимга әверелеп сакланган.

Бәләбәй — Башкортстан АССРдагы шәһәр. Бу топонимның нигезендә Балабай (бала+бәй) дигән кеше исеме ята. Борынгы заманда төрки халыкларда балага туганлык термины (бала, баба, ата һ. б.) һәм сословие титулын (бәй — князь, хан, бай, әмир һ. б.) белдергән сүздән гыйбарәт исемнәрне кушу гадәте дә булган. Нәтиҗәдә, Бабахан, Атабай, Атабек, Балаәмир, Балабәй кебек кеше исемнәре барлыкка килгәннәр. «Балабәй»нең икенче компоненты «бәй» нечкә әйтелешле булганга, калын әйтелешле беренче компоненты «бала» да бергә кушып, бер сүз итеп әйтү аркасында нечкәргән, «Бәләбәй»гә әйләнгән.

Балымер — Татарстанның Куйбышев районындагы авыл. Шушы исем белән Идел буендагы болгар шәһәре аталган. Әлеге топонимның Балаәмир дигән кеше исеменнән килеп чыккан булуы һәм бу исемнең ничек ясалуы инде яхшы аңлашыла.

Әлмәт — Татарстан нефтьчеләренең үзәк шәһәре. Бу — атама. Әлмөхәммәт дигән кеше исемен кыскарту, икенче һәм өченче иҗекне (мөхәм) ташлап, беренче һәм дүртенче иҗекне янәшә әйтү (Әлмәт) нәтиҗәсендә барлыкка килгән булырга тиеш. Татарлар Ярмөхәммәт дигән кеше исемен Ярмәт яки Ярми, Ишмөхәммәтне — Ишмәт яки Ишми, Ширмөхәммәтне («шир» — фарсыча арслан) — Ширәмәт дип, кыскартып әйтәләр. Бу — безнең фикерне дәлилләүче бер факт булып тора. Әлмәт тирәсендә: Миңлебай, Габдрахман, Сәләй (Сәләйманнан кыскарган), Колшәрип һ. б. кебек кеше исеме белән аталган татар авылларының булуы да шул ук фикерне куәтли.

Дәүеш — Апас районындагы авыл. Бу авылның атамасы Дәүеш дигән кеше исеменнән алынган. Дәүеш ике тамырдан ясалган кушма сүз: дәү+еш. Дәү сүзе олы, зур мәгънәсендә кулланыла. «Дәү»нең этимологиясе даг/таг (дау/тау) дан килә. «Эш» өлеше — «иш» сүзенең борынгы телебездәге варианты. Күренекле тюрколог, профессор Н. И. Ашмарин «Болгарлар һәм чувашлар» (Казан, 1902 ел) дигән хезмәтендә татар һәм башкорт телләрендә «иш» сүзенең: тигез, тиң, охшаш, иптәш, ишле, күп санлы, ә чуваш телендә «йыш»ның семья, кеше, күп санлы дигән мәгънәләрдә кулланылуын әйтә. Татар телендәге еш, ешла сүзләре дә килеп чыгышлары ягыннан шул ук «иш»кә барып тоташалар. Димәк, Дәүеш — дәү+еш дигән мәгънәдә кулланылган. Мондый исем беренче яки зур туган ир балага бирелгән. Мишәрләрдә хәзер дә Девишев, татарларда Дәишев дигән фамилияләр очрый.

Көек. Казан артында шушы исем белән атала торган берничә татар авылы бар. Борынгы вакытларда ук кешеләр куе урманнар арасына килеп утырганнар. Ачык урын ясап, авыл кору һәм чәчүлек җирләре барлыкка китерү өчен, урманны, ут төртеп, яндырганнар. Шул урынга салынган авылга «Көек» дип исем биргәннәр. Борынгы телебездә көек сүзе яну, янгын мәгънәсендә кулланылган. Себер татарлары хәзер дә: «Йортым көеп китепте» (әдәби телдә — йортым янып китте), дип сөйлиләр. Апас районындагы Аюкөйдергән авылының исеме дә аю көйдерү (яндыру) вакыйгасы белән бәйләнешле.

Дөбъяз, Олыяз, Торнаяз, Арпаяз авыллары исеменең икенче өлеше боларның барысы өчен дә уртак «яз» сүзеннән гыйбарәт. Борынгы төрки телдә «яз» сүзе дала, язылган, җәелеп киткән тигез урын мәгънәсендә

кулланылган. Саба районында Арпаяз һәм Язлы Арташ дигән авыллар да бар. Арпаяз «арпа даласы», ә соңгысы «далалы Арташ» дигән мәгънәне аңлата.

Төмән — Көнбатыш Себердәге шәһәр. Төмән яки түмән сүзе борынгы төрки халыкларда ун мең төшенчәсендә йөргән. Йөз меңне ун түмән дип йөрткәннәр.

Татар теле тарихында түмән сүзе ике мәгънәдә кулланылган: 1) хәрби термин буларак, түмән яки төмән сүзе (русча — темник) ун меңнән торган гаскәрне һәм аның башлыгын белдергән. Өяз белән идарә итүче түрәне дә түмән дип атаганнар; 2) төмән сүзе бик күп, чиксез күп дигән төшенчәне белдерү өчен дә кулланылган. XVI йөз татар шагыйре Мәхмүт Мөхәммәдьяр бер әсәрендә: «Түмән төрле хикәятләр сөйләделәр»,— ди. Бирелә түмән бик күп, чиксез күп дигән мәгънәне аңлата. Татар теленең көнчыгыш диалектында ул шушы мәгънәсендә хәзер дә кулланылышта йөри. Тара һәм Тевриз татарлары: «Лапкага төмән төрле йепләр килепте» (кибеткә чиксез күп төрле җепләр килде),— дип сөйлиләр.

Төмән шәһәренең исеме, легендаларга караганда, ун мең — түмән сүзе белән бәйләнешле. Имеш, Төмән шәһәренә 10 мең гаскәре яки 10 мең хайваны булган бай татар кнәзе нигез салган һәм бу сан шәһәр исеменә әверелгән. Бу легенданы академик Г. Ф. Миллер себер татарларыннан 1750 елда язып ала һәм «Себер тарихы» дигән фундаменталь хезмәтендә урнаштыра. Әмма ул шәһәр исеменең ун мең — түмән сүзе белән мөнәсәбәтле булуын шик астына куя (кара: Г. Ф. Миллер. «История Сибири», т. 1, изд-во АН СССР, М.-Л., 1937, 273—274 битләр).

Безнең карашыбызча, Төмән сүзе телебездәге түбән (нижний) сүзеннән алынган булса кирәк. Сарт телендә түбәнлекне һәм елганың түбән агымын «түмән» дип йөрткәннәр (кара: М. Наливкина. Сартовско-русский словарь по наречиям Наманганского уезда. Казань. 1884 ел. 124 бит).

Себер татарлары телендә «б» һәм «м» авазлары чиратлашу җирлегендә, түбән сүзе түмән-төмән формасында кулланыла. Төмән шәһәре исеменең этимологиясе «түбән — түмән-төмән» сүзе белән бәйләнешле дип аңлатуның дөреслеккә туры килүен шәһәрнең географик урыны түбәнлеккә, Тура елгасының түбән агымына урнашкан булуы да раслый.

Төмән исеменең «түбән» сүзе белән мөнәсәбәтле булуын икенче төрле дә аңлатырга мөмкин. Төмән шәһәре Себер ханлыгының Тура елгасының югарырак агымына урнашкан элекке башкаласы Чингиторадан (тора — себер татарлары телендә шәһәр дигән сүз) түбәнрәк урнашкан була һәм аны Төмәнтора дип атаганнар. Соңыннан «тора» сүзе бу исем составыннан төшеп, «Төмән» генә кала. Бу исә татарларның калкурак җиргә утырган авыл исеменә «югары», ә аннан түбәнрәк җиргә утырганына «түбән» эпитеты өстәп йөртү гадәтенә дә туры килә. Руслар да Идел елгасының чагыштырмача түбәнрәк агымына урнашкан Новгород шәһәрен төньяктагы Новгород белән бутамау өчен, Нижний Новгород (хәзерге Горький) дип атаганнар. Димәк, себер татарларының борынгы бабалары, Чингитора белән чагыштырганда, Тура елгасының түбән агымына урнашкан шәһәрне Төмәнтора дип атаулары бик табигый.

Янсурин — Апас районындагы авыл. Бу топоним Янсорыйм дигән кеше исеменнән алынган. Бу исемне балага кушу исә борынгы вакытта илаһи көчтән — алладан бала, җан сорау һәм аның исәнлеген теләү йоласы белән бәйләнешле. Себер татарлары һәм казакълар арасында әле хәзер дә Сораган дигән кеше исемнәре очрыйлар.

Кенәр — Арча районындагы авыл. Бу исем марилар тарафыннан бирелгән. Марича «ку» — таш, ә «энгер, энер» — елга. Димәк, Куэнер (шуннан Кенәр) — «ташлы елга» дигән мәгънәне белдерә.

Кукмара — Татарстандагы район үзәге. Бу топоним шулай ук мари теле белән бәйләнешле. Ул марича «кок» (ике) һәм «мара» (мари халкының үз-үзен атау исеме) дигән сүзләрдән тора. Димәк, Кукмара «ике мари» дигән мәгънәне белдерә. Аңа кайчандыр ике мари нигез салып яшәгән һәм бу вакыйга авыл исемендә гәүдәләнеш тапкан булса кирәк.

## Фоат Вәлиев

# БОРЫНГЫ БОЛГАР

Көнчыгыш Европаның беренче дәүләтләреннән булган, исеме еракларга таралып гасырларда калган бөек Болгар! Батыр эшләре, зур кәсепләре, күп төрле асыл һөнәрләре белән данлыклы булган Болгар кешеләре — безнең ерак бабаларыбыз. Аларның даны турында алтын куллы осталар салган мәһабәт һәм матур Болгар, Суар, Биләр, Ашлы, Җүкәтау кебек Идел буе шәһәрләре, бу шәһәрләрне күреп сокланган гарәп, шәрык сәяхәтчеләре сөйлиләр. Ул шәһәрләрнең матурлыгын, байлыгын, бигрәк тә бу дәүләтнең борынгы башкаласы Болгарның югары архитектура сәнгатен анда сакланган калдык истәлекләр дә ачык күрсәтәләр. Бу казылма истәлекләрнең күбесе риваятьләргә кергән, әкиятләр тууга сәбәп булган. Аларны күргәндә бүген дә әле күп акыл ияләре, сәяхәтчеләр, тикшерүчеләр таң-хәйран кала, гүзәллекләренә соклана...

Болгар дәүләтенең бөтен тарихы борынгы Итил суы белән бәйле. Чөнки бу елга, коры җирдәге кәрван юллары кебек үк, безнең бабаларыбызга Урта, Көнчыгыш һәм Кече Азия, Иран, Кавказ, Русь халыклары белән, шулай ук якын күршеләребез белән аралашырга ярдәм иткән.

Дәүләт барлыкка килгәнче үк инде болгарлар киң халыкара мөнәсәбәтләргә керәләр, күп халыклар белән тыгыз элемтә тоталар. Бу хәл аларның политик һәм экономик тормышында зур роль уйный. Турыдан-туры ыру-кабилә тәртибенең җимерекләре өстендә төзелеп, колбиләүчелек җәмгыятен читләтеп узган Борынгы Киев һәм башка феодаль Европа дәүләтләре кебек үк, Болгар дәүләтенең дә оешу һәм үсү процессы бер кабиләлекне икенчесенең йотуы, шул рәвешчә, аерым политик берләшмәләр төзелү юлы белән бара.

IX—X йөзләр чигендә мәйданга килгән Болгар дәүләте ул чор төрки кабиләләренең иҗтимагый-экономик яктан тиз алга китүе нәтиҗәсендә туа. Бу кабиләләр дәүләтнең төп халкын тәшкил итә. Дәүләтнең географик уңай урында — Волга һәм Кама сулары кушылган җирдә урнашуы да аның барлыкка килүенә һәм ныгуына шактый файдалы була.

Шәрык авторларының һәм рус елъязмачыларының сүзләренә карaганда, Болгар дәүләте Волганың урта Каманың түбән агымы тирәләрендәге зур мәйданнарны били. Аның төньяк чиге Кама буйлап үтә, көньяк чиге Жигули тауларына барып терәлә. Чишмә елгасы — көнчыгыш, Зөя — көнбатыш чиген тәшкил итәләр. XIII йөз башларына аның биләмәләре бераз киңәя: Каманың уң ягы һәм көнбатышта Волга белән Сура елгалары арасы үзләштерелеп, эшкәртелә башлана. Борынгы мари, мордва, чуваш, башкорт, удмурт һәм башка Урта Волга халыклары яшәгән җирләр дә болгарларга буйсынган булып, аларның тарихы да Болгар тарихы белән тыгыз бәйләнә.

Болгар халкы этник яктан нигездә төрки халык булган. Гарәп чыганаклары күрсәткәнчә, ул болгар, баршле, асыгыйлы, суар кебек төрле кабиләләрдән торган.

Халкының төп кәсебе игенчелек һәм терлекчелек була. IX—X йөзләрдә үк инде өч басулы чәчү әйләнеше өстенлек ала. Хәзерге сабан сыман бер тәрәнле сабан һәм тимер тәрәнле җиңел агач сука — менә ул чор игенчесенең төп эш коралы шулар.

Гарәп язучысы Ибне Рөстә сүзләренә караганда, Болгарда бодай, арпа, тары игелгән. Солы, арыш, борчак та чәчкәннәр.

Болгарлар аучылык-сунарчылык, балыкчылык һәм умартачылыкны да бик яраткаңнар.

Болгардан килгән кеш, сусар, кондыз, кама һ. б. җәнлек тиреләре тышкы базарларда, бигрәк тә Көнчыгышта, бик үтемле була.

Һөнәрчелек дәүләт экономикасында зур урын тотып, аның продукциясе дә күпчелек читкә чыгарыла.

Ил экономикасында әһәмиятле урын тоткан кара металлургия, тимерчелек эше кебек һөнәр тармаклары бик нык үсә. Бронза кою, чүлмәкчелек һөнәрләре, тире, агач, сөяк һәм асыл ташлар эшкәртү шактый алга киткән була. Болгар осталары кулыннан чыккан көбә киемнәр, кылычлар, сөңгеләр, уклар, хәнҗәрләр, йозаклар, ялтыраган металл савыт-саба, күз явын алып торган чүлмәкләр, бизәнү әйберләре, атаклы болгар сафьяны, читек һәм башка төр аяк киемнәре, төрле-төрле эш кораллары ул вакытның шау-гөр килеп торган күп кенә базарларында сатыла. Борынгы Хорезм, Киев, соңгарак Владимир — Суздаль дәүләтләренең, хәтта Көнбатыш Европаның шәһәрләрендә дә бу товарларны очратып булган.

Болгар металлургларының X—XI гасырларда ук инде корыч коя белгәнлеге мәгълүм. Болгар кылычының сыйфаты атаклы дамаск кылычларыныкыннан түбән тормаган һәм шуңа күрә тирә-юньдә дан казанган. XIV йөзнең беренче яртысында болгар металлурглары Европада беренчеләрдән булып чуен кою эшен җәеп җибәрәләр.

Һөнәрчелек рәвешендәге шушы иҗтимагый җитештерүнең нык үсүе нәтиҗәсендә эчке-тышкы сәүдә бик киңәя. Болгар сәүдәгәрләре Европага һәм Азиягә чыгып дөнья базарларында катнашалар. Сәүдә флоты да үсә, илдән ерак булган чит җирләрдә хәрби ныгытмалар, сәүдә факторияләре барлыкка килә.

Дәүләтнең башкаласы булган Болгар шәһәре Европа белән Көнчыгыш арасындагы халыкара сәүдәнең төп үзәкләреннән берсенә әверелә. Монда Урта Азия, Иран, Кавказ, Русь, Балтик буе һәм Үзәк Европа сәүдәгәрләре һәм купецлары килләр. Болгарлар Кама буе, Урал һәм Төньяктагы халыклар белән дә сәүдә итәләр.

Көнчыгыштан Болгар иленә ефәкләр, тукымалар, алтын, көмеш, келәмнәр, асыл ташлар, сугыш кораллары, савыт-саба, татлы ашамлыклар һ. б. килә. Рус сәүдәгәрләре коллар белән сату итәләр, тире, сугыш кораллары, бизәнү әйберләре китерәләр. Балтик буе илләре франк кылычлары белән гәрәбә җибәрәләр. Төньяктагы куршеләр кыйммәтле һәм гади тире, каен һәм нарат агачы, чикләвек, бал, балавыз, балык җилеме, сугыш кораллары, терлек һ. б. саталар.

X йөзнең башында ук инде көмеш акчалар — дирһәмнәр чыга. Болгарда акча сугу эше оештырыла. Акча урынында төрле кыйммәтле җәнлек тиреләре дә йөри.

Дәүләт төзелү нәтиҗәсендә Волга — Кама тирәләрендәге халыклар үзара политик һәм экономик мөнәсәбәтләрен тагын да ныгыталар, Көнчыгыш белән культура һәм экономика өлкәсендә бәйләнешләр көчәя, һөнәрчел җитештерү киңәя, шәһәрләр үсә.

Көнчыгыш дөньясының төньяк читендә урнашып, күп кенә Көнчыгыш Европа халыклары белән орынып торган Болгар иленә Көнчыгыш, бигрәк тә Урта Азия дәүләтләре кызыксынып карыйлар, аның белән мөнәсәбәтне үстерергә һәм ныгытырга телиләр.

Болгар иленең Көнчыгыш дәүләтләре белән тыгыз культура-экономика мөнәсәбәтләре шуңа китереп җиткерә ки, X йөздә рәсми төстә ислам дине кабул ителә. Бу хәл болгар феодалларының хакимлеген көчәйтә, хезмәт халкын тагын да аларга бәйлерәк итә. X йөз башында халыкның төп өлеше ирекле, ягъни община члены хокукына ия була, һәм салым-налог дигән нәрсәләрне белми. Әмма соңга табарак инде, кагыйдә буларак, төрле салым (кеш тиреләре, йорт хайваны һ. б. ш.) түләү тәртибе кертелә.

Болгар Русь белән киң экономик һәм политик бәйләнешләр урнаштыра. IX гасырда ук инде рус сәүдәгәрләре һәм сугышчылары, Болгар дәүләте аркылы үтеп, Волга буйлап түбәнгә яки Көнчыгыш илләренә йөриләр.

Болгар дәүләтенең шәһәрләрендә хәтта кечкенә рус колонияләре дә була. Болгар феодаллары һәм руханилар рус князьләрен мөселманлыкка кертергә тырышып карый. Мәсәлән, 986 елны Киев дәүләтенә шул максат белән махсус бер төркем илчеләр җибәрелә.

Болгар сәүдәгәрләренә Киев җирендә сәүдә алып бару иреге куела. Рус купецлары да Болгар иленә еш киләләр.

XI йөз ахырында оешкан Владимир — Суздаль дәүләте белән дә болгарлар тату яшиләр. Бу ике дәүләт башындагы кешеләр арасында туганлык җепләре сузарга да омтылыш ясала: Владимир — Суздаль кнэзе Андрей Боголюбский Болгар патшасының кызын ала. Ләкин шулай матур гына яшәп ятканда хәрби бәрелешләр дә килеп чыга. Сәбәбе — Волгадагы сәүдә юлы өчен көрәш һәм Волга — Кама буйларындагы халыклар өстеннән хакимлек итәргә омтылу. Бу көрәш башта Болгар һәм Киев дәүләтләре, соңыннан Болгар белән Владимир — Суздаль дәүләтләре арасында бара. Хәрби бәрелешләр бигрәк тә XI—XII йөзләрдә ешая. Шул чорда Волга буйларында һ. б. урыннарда болгарларның хәрби ныгытмалары барлыкка килә. Бу бәрелешләр уртак дошман булган монгол-татар урдалары килеп баскач кына туктала.

Күрше удмурт, мари, башкорт, чуваш һәм бүтән Урта Волга, Кама халыклары белән дә болгарлар дәүләте дус булган. Бу халыкларның вәкилләре Болгар шәһәрләрендә һәм авылларында яшәгәннәр. Шул ук вакытта болгарлар үзләре дә алар җирендә, мәсәлән, Чепья, Бартым елгалары буенда, Сураның югары агымнарында көн иткәннәр.

Болгарлар үзләре белән тыгыз бәйләнештә торучы күршеләренә, аларның этногенезына һәм культурасына әзме-күпме йогынты ясыйлар.

Болгарларның монгол басып алуына кадәр чордагы культурасы шактый катлаулы мөхиттә үсә. Игенчелек культурасының нигездә утырып җиткән булуына карамастан, әле күчмә заман традицияләре дә, аерым очракларда булса да, үзен күрсәткәли.

Дәүләтнең борынгы, төп катламын тәшкил итүче төрки халык, ягъни болгарлар, үзләренең көньяк-көнчыгыш күршеләрендәге кардәш угыз-кыпчак кабиләләреннән оешкан булса кирәк.

Болгарларның катлаулы культурасын төзүдә, үстерүдә мондагы күп кенә төрки халыклар белән бергә фин-угор кабиләләре, шушы җирдә туган халык та катнаша. Бу культура киләчәктәге Казан татарлары культурасының нигезенә ята, аның үсеп чыккан бишеге була. Соңгырак чорларның күп кенә йогынты эзләре калдыруына карамастан, бу культурада, бигрәк тә сәнгать культурасында, угыз-кыпчак нәселеннән булган әзербайҗан, төрек һ. б халык культурасы белән бер ишлелек билгеләре күренеп тора.

Болгар культурасының үсешен шул чордан аерып карап булмый, әлбәттә. Тарихи, социаль-экономик шартлар, этник һәм географик мөхит халык тормышының милли һ. б. үзенчәлекләре белән тыгыз үрелеп киләләр.

Культура үсешендә Болгар дәүләтенең шәһәрләре зур роль уйный. XI йөз урталарына халкы 50 меңгә җиткән баш шәһәрнең — Болгарның — роле аерата зур була. Шәһәрләр культура, сәнгать, фән, һөнәрчел җитештерү һәм сәүдә үзәкләренә әйләнә. Киң масштаблы халыкара мөнәсәбәтләр хәрби һәм сәүдә флотының үсүенә, көймә төзү эшенең алга китүенә этәреш бирә.


Гарәп сәяхәтчеләренең язуынча, Болгар илендә астрономия бик югары баскычта торган; галимнәр зур тарихи хезмәтләр язган; әдәбият, музыка чәчәк аткан. Болгарларда җыенаять кодексы булган дигән мәгълүматлар да бар. Тик кайбер галимнәрнең һәм шагыйрьләрнең исемнәре генә тарих битләрендә саклана алган. Мәсәлән, «Болгар тарихы»н язган Якуп ибне-Ногман әл-Болгари дигән тарихчы; риторика, медицина, дару үләннәре турындагы язмалары белән мәгълүм Әхмәт әл-Болгари, дин галиме һәм философ Хәмит ибне-Идрис әл-Болгари заманында күренекле кешеләр булганнар. XII—XIII йөзләрдә яшәгән Болгар шагыйре Кол Гали турында күпләрнең инде ишеткәне-укыганы да бардыр. Укымышлылар һәм югары катлау арасында болгарлар үзләре язган, шулай ук гарәптән кергән әдәби һәм дини әсәрләр дә киң таралган булган.

Археология күрсәткәнчә, гарәп алфавиты урнашканга кадәр Болгар илендә рун язуы гамәлдә йөргән.

Урта Волгадагы беренче дәүләтнең мәһабәт һәм матур шәһәрләре, монументаль төзелешләре аның данын еракларга тарата. Әмма илнең борынгы төрки халкы боларны иҗат итүгә дәүләтчелек барлыкка килүдән күп элек әзерләнгән булган инде.

Археология тикшеренүләре шуны күрсәтә: болгарга ча заманнарда ук халык калын-калын стеналы һәм манаралы хәрби пулатлар, ныгытмалар торгыза, югары катлау өчен утарлы пулатлар һәм башка шундый төрле-төрле каралтылар төзи. Боларның барысы да кирпечтән һәм таштан эшләнә. Мондый монументаль төзелешләрдән тыш, гади хезмәт халкы өчен кызыл балчыктан салынган тораклар булган. Алар кайвакыт яртылаш җиргә кертеп, җир өй сыман итеп эшләнгәннәр.

Төрле-төрле йортлар, корылмалар төзегән борынгы осталар бу эштә зур күнекмә алалар, бай тәҗрибә туплыйлар; аларда архитектура сәнгате принциплары һәм идеяләре барлыкка килә башлый. Шулай итеп, дәүләт оешудан күп элек монументаль һәм халык архитектурасының үсеше өчен нигезләр салынган була.



*XI—XII гасырлар. Суар шәһәренең хәрби стеналары.*

Дәүләт оешу белән бергә сыйнфый хакимлекнең яңа формалары да барлыкка килә. Массага яңача шартларда йогынты ясауның юлларын эзләп, Болгарның югары катлау вәкилләре зарури рәвештә Көнчыгыш һәм Шәрык феодаль дәүләтләренең күп гасырлык тәҗрибәләренә мөрәҗәгать итәләр. Бу бәйләнешләр, үз чиратында, төзелеш өлкәсенә дә кагыла: чит илләрдән төзү осталары, архитекторлар китертелә. Бу рәвешле осталар чакырту Урта гасыр чоры өчен, гомумән, бик гадәти күренеш исәпләнә. Әмма мондый осталар Болгарда зур урын тотмый. Шулай да Көнчыгыш һәм Шәрык тәҗрибәсе, осталыгы, сәнгате файдаланыла.

Көнчыгыш халыкларының архитектура казанышларын җирле мөмкинлекләргә һәм шартларга җайлаштырып, болгар осталары чагыштырмача кыска вакыт эчендә үз архитектура мәктәпләрен булдыруга ирешәләр. Болгар архитектура осталарының һәм ташчыларының югары казанышлары турындагы хәбәрләр, сүзләр ерак чит илләргә тарала. Бу хакта иң яхшы мәгълүмат рус елъязмаларында саклана. Анда күрсәтелгәнчә, Владимир — Суздаль шәһәрләрен һәм соборларын салу өчен, башка дәүләтләр белән рәттән, Болгардан да осталар чакыртыла.

Болгар архитектура осталары дәүләтнең үзәгендә генә түгел, бәлки аның кырыйларында да монументаль таш пулатлар торгызалар. Мәсәлән, хәзерге Башкортстанның район үзәге булган Чишмә авылы якынындагы Тура-хан кәшәкхәсе (кәшәкханә — мавзолей) XIV йөздә шул рәвешле салынган. Бу тирәләрдә шулай ук ул чорның болгар кабер ташлары да сакланган.

Болгар шәһәрләренең план тәртибендә, төзелеш рәвешендә һәм архитектурасында җирле шартларны исәпкә алган, җирле материалны чагылдырган мөстәкыйльлек булса да, югарыда искә алынган сәбәпләр аркасында, Көнчыгыш шәһәрләре белән уртаклыклар да шактый. Дәүләтнең башкаласы булган Болгар һәм башка шәһәрләр икешәр катлы калын-калын биек имән стеналар белән әйләндереп алынган, аның өстендә күзәтү һәм дошманга ату өчен җайлы уемнар ясалган манаралар калкып тора, ә аста авыр капкалар.



*X—XI йөзләр. Болгар феодалының кирпеч йорты.*
Автор реконструкциясе.

Болгар шәһәренең үзәгендә — үзенә бер төрле мәйдан сыман урында — патша сарае, Үзәк мәчет (Җами мәчете), феодаль югары катлау утарлары, кәрвансарай һ. б. кайбер каралтылар урнашкан. Бу үзәк мәйданнан як-якка тар-тар гына тыкрыклар сыман урамнар китә: монда сәүдәгәр, түрә, рухани катлауларының йортлары, каралтылары. Читтә, бистәләрдә — һөнәрчеләр, чит ил халыклары яшәгән.

Борынгы авторларның әйтүенчә, Суар һәм Болгар шәһәрләрендә X йөздә үк инде үзәк, төп мәчетләр булган. Ислам динен рәсми (X йөз) кабул итүдән күп элек болгар авылларында агач мәчетләр була. «Авылларда мәчетләр белән башлангыч мәктәпләр, аларда мәзиннәр, имамнар бар», — ди ибне-Рөстә.

Археология материаллары күрсәткәнчә, торак каралтыларның күпчелеге агачтан бурап салынган, хәзерге кебек кыеклы, йорт урыны дүрт почмаклы булган. X йөз авторларыннан берсе ибне-һәүкаль болгарларның йортлары хакында: «Монда йортлар Итилдәгедән остарак төзелә иде», — ди. Икенче бер Якут дигән автор болай ди: «Болгарлар йортларын агачтан гына салалар: бер бүрәнәне икенчесе өстенә яткыралар да аларны шулай ук агач, ләкин нык кадаклар белән тоташтыралар».

Болгар шәһәрләре белән авылларында тагын үзенә бер төрле тораклар да бераз таралган булган: мондый йортлар такта кыса эченә кызыл балчык тутырып салынган, эчтән-тыштан сыланган һәм яссы түбәле булган. Өйләрнең Төньяк Кавказ халыкларыныкына хас бу төрен читтән килеп утырган болгарлар салган булса кирәк.

Баерак хуҗаларның таш яки кирпеч йортлары да булган. Кайбер таш, кирпеч йортлар, мәсәлән, мәчетләр, пулатлар үзәктән дә җылытулы булган. Җылыту казаннары идән астында урнашкан.

Болгарларның X—XII йөз монументаль корылмаларыннан безнең көнгәчә заманында куәтле хәрби ныгытма булып, хәзер «Шайтан» каласы («Чертово» городище)

дип йөртелә торган каралтының бер манарасы да Суар шәһәрендә бер болгар феодалының утарлы пулатының калдыгы гына сакланган. Утарлы пулатның архитектурасы Хорезм каралтыларынынкына охшаган.

IX—XIII йөз монументаль болгар архитектурасы хакындагы бүгенге мәгълүматларыбызны киләчәктәге археологик тикшеренүләр, һичшиксез, тулыландырачак.

Монголгача чордагы болгар халкында практик декоратив сәнгать нык алга киткән булган. Һөнәрчел җитештерүнең аерым төрләре: металл, таш, сөяк, агач, тире, йон эшкәртү, чүлмәк савытлар ясау һ. б. ш. белән бәйләнгән.

Ювелир осталар бигрәк тә дан казанганнар: төрле материалдан сырлап, чүкеп, коеп, таптап дисеңме, бер төр материалга икенче төрлесен бизәк итеп кую, асылташларны инкрустацияләү дисеңме — барысын да җиренә җиткереп эшләгән алар. Кулларыннан гөлләр таммаса да, югары сыйфатлы зиннәтләр: балдак, алка, җиз көзгеләр, кечкенә корьәннәр сала торган тартмачыклар, сәдәпләр, каптырмалар, декоратив балтачыклар, кием яки сбруй бизәү өчен хезмәт иткән төрле төймәләр чыккан.

Болгар осталары күп төрле кыйммәтле бизәнү әйберләре җитештергәннәр. Аларны алтын-көмештән, бронзадан яки бүтән металл эретмәдән, сөяктән һ. б. эшләп, геометрик яки үсемлек-чәчәк бизәкләре белән бизәгәннәр.

Ювелир продукциясенең күпчелеге сатуга чыгарылган. Ләкин, археологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, аерым кешеләрнең соравы-кушуы буенча да бизәнү әйберләре эшләнгән.

Тимерче, бакырчы, бронза коючы һәм эшкәртүче, тукучы, итекче-читекче, чүлмәкче һ. б. һөнәрчеләрнең дә продукциясе югары сәнгатьле булган.

Болгар осталарының барлык төр әйберләре дә: металлданмы ул, сөяктәнме, таштанмы, балчыктанмы яки башка материалданмы — үсемлек-чәчәк рәвешендәге яки геометрик орнамент белән бизәлә торган була.

Җан иясе сурәтләрен төшерүдән ислам тыйса да, монголгача чорның практик декоратив сәнгате әсәрләрендә хайваннар, кошлар, хәтта сюжетлы күренешләр дә шактый күп тасвирланган. Димәк, болгар халкының иҗатында мәҗүсилек карашлары белән бәйләнеп, әйләнә-тирә табигатен реалистик аңлауга нигезләнгән борынгы монголгача сәнгать традицияләре көчле булган.

XIII йөз башында Болгар дәүләтен күчмә монгол-татарлар басып ала һәм ул Чыңгыз хан империясе составындагы Җучи җитәкчелек иткән Алтын Урдага кертелә. Шушы ук Урдага Дешт һәм Кыпчак җирләре, Кырым, Хорезм, Төньяк Кавказ һәм рус князьлекләре дә керәләр.

Болгарларның монгол-татар яуларын туктатырга маташуы бик кыйбатка төшә: чәчәктәй шәһәрләр, авыллар җимертелә, дәүләтнең элекке сәүдә-һөнәр һәм хуҗалык эшләре тәмам чыгырыннан чыга.


Басып алучылар җирле халыкны күпләп үтерәләр, илнең иң яхшы галимнәрен, төзү осталарын, шагыйрьләрне, һөнәрчеләрне Алтын Урда калаларына көчләп куып алып китәләр...

Әмма Болгар дәүләтенең басып алынуы феодаль системаның нигезен какшатмый, феодаль культураның традицион характерын бозмый. Монголлар үзләре киң күпләмдә җирле халык тарафыннан ассимиляцияләнәләр, аерым алганда, алар арасында ислам киң таралып китә.

Үзеннән-үзе аңлашылганча, күчмә килмешәкләр югары үсештәге Болгар игенчелек культурасына яңа бер нәрсә дә өсти алмыйлар. Монголлар халыкның этник составына да йогынты ясый алмаганнар.

Дәүләтләре басып алына башлагач, хезмәт халкының, шулай ук феодалларның шактый өлеше Каманың төньягына таба, Казанка, Мишә сулары буйларына һәм Зөянең түбән агымы тирәләренә кача. Бу җирләрдә болгарлар электән шунда яшәгән мари, удмурт һ. б. халыклар белән мөнәсәбәткә керәләр. Яңа җирләрдә яңа авыллар, Кирмәнчүк кебек шәһәрләр калкып чыга һ. б.

Монголларның басып алуы баштарак илнең эчке үзидарәсен үзгәртә алмый, ләкин мөстәкыйль үсеш юлы инде киселгән була. Үз биләмәләрен идарә итү хокукы алу өчен, элекке Болгар биләре Алтын Урда ханнарыннан махсус ярлыклар алырга тиеш булалар.




*А. IX—X йөзләр. Алабуга тирәсендә «Шайтан каласы» калдыклары. Б. XIV йөз башы. Кече манара. В. XIV йөз башы. Олы дәрбә.*

**Болгар халкы күп төрле ясаклар түләргә, авыр йөкләмәләр үтәргә мәҗбүр ителә. Гади хезмәт халкын монгол ханнары гына түгел, «үз» феодаллары, җирле биләр дә изә.**

**Бер уйлаганда, болгарларның экономикасы һәм культурасы тәмам аяк астына салып тапталган, инде халык аякка баса алмас кебек тоела. Юк, тарих күрсәткәнчә, халык җимерек-ватыкларны төзәтү белән генә дә чикләнеп калмый, бәлки яңа материаль кыйммәтләр иҗат итә, Көнчыгыш һәм Көнбатыш илләре белән традицион сәүдә-экономика һәм культура мөнәсәбәтләрен киңәйтә, күршеләре белән тагын да тыгызрак бәйләнешкә керә. Шуның нәтиҗәсендә үзенең экономикасын, культурасын чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә шактый югары баскычка күтәрә. XIII йөзнең икенче яртысы һәм XIV йөзнең башы — Болгар дәүләтенең экономик яктан аякка басу, ә аның башкаласы булган Болгар шәһәренең чәчәк ату чоры исәпләнә.**

**Монголгача чордагы кебек үк, халыкның төп кәсебе игенчелек белән сәүдә була.**

**Бу чор өчен суергал дип йөртелгән җир биләү тәртибе хас: җир һәм андагы халык хәрби катлаудан булган феодалга гомерлек милек итеп бирелә. Шулай ук тарханчылык та барлыкка килә.**

һөнәрчел җитештерү һәм сәүдә эшенең үз казналарын баетуда нинди әһәмиятле урын тотуын чамалап алган монгол ханнары аларны тагын да үстерергә ярдәм итәләр, шулай ук шәһәрләрнең үсүен дә хуп күрәләр.

Болгарларның һөнәрчел җитештерүендәге техникада да, ассортиментта да элекке, монголгача, традицияләр дәвам иттерелә.

Болгарның сәүдә һәм экономикасы торгызылу, һөнәрчел җитештерүнең үсеше илдә акча сугуны китереп чыгара.

Басып алучыларның Алтын Урда дәүләтендә рәсми тел булып кыпчак теле санала башлый. XI йөздә үк Волга буена килеп чыккан бу бик күп санлы төрки халык соңыннан хәзерге мишәрләрнең формалашуында төп урынны тота. Барлык язу-сызу эшләре шушы телдә бара, һәртөрле рәсми кәгазьләр шул телдә языла, рус князьләренә һәм болгар биләренә идарә итү хокукы биргән ярлыклар шул телдә була. Культура дәрәҗәсе элекке кебек үк югары баскычта калган болгар халкы арасында да, әкренлек белән булса да, шул тел тарала.

Монгол-татар басып алучылары үз табаннары астына эләккән җирләрдәге халыкны буйсындыру һәм изүдә исламның әһәмиятен бик яхшы аңлыйлар. Шуңа күрә ул динне үзләре кабул итеп тагын да киңрәк таратырга булышалар. Моның өчен төрле культ каралтылары, зур мәчетләр, дөрбәләр, мавзолейлар, руханилар өчен мәктәп-мәдрәсәләр киң төзелә башлый. Алтын-Урта ханнары үткәргән исламлаштыру политикасы мөселманлаштыру үзәге булган Болгарның әһәмиятен тагын да үстерә. Монголлар килгәнче үк Болгар дәүләте Волга буенда ислам дине таратуның үзәге була.

Испам диненең көчәюе мөселман руханилары өчен тагын да киңрәк мөмкинлекләр ача. Болгарда рухани мәктәпне тәмамлап, кабиләдәшләре арасында ислам динен таратучы кешеләр болгарлар гына булмыйча, бәлки башкорт, кыпчак һ. б. халык вәкилләре дә була. Шушы миссионерлар, алар өстенә тагын болгар сәүдәгәрләре, күрше халыклар арасына барып, исламны тарату белән генә чикләнмиләр, бәлки болгар культурасының элементларын, болгар һәм Урта Азия дин галимнәренең әсәрләрен, болгар һөнәрчеләренең иҗат әйберләрен дә китерәләр.

Җитештерү көчләренең, экономиканың тиз үсүе нәтиҗәсендә Болгар иле XIII йөз ахырына яңадан халыкара күләмдә танылa башлый. Башкаладагы патша сарае, кәрвансарай, мәчетләр, пулатлы утарлар, җәмәгать мунчалары, мавзолейлар, башка төр таш яки кирпеч монументаль корылмалар тулысынча торгызыла яки яңадан салына. Шәһәр тиз үсә, халкы ишәя. һәрхәлдә, аның хәрби ныгытмалы стеналарының бик озын булуы шуны күрсәтә. Өзлексез артып торган халыкны борынгы шәһәр сыйдыра алмый башлый: аның тирәсендә бистәләр ясалып, анда һөнәрчеләр, шулай ук читтән килеп утырган халыклар яшиләр.


Ул заман Шәрык шәһәрләрендә яшәп килгән гадәт буенча, җәйге чорда шәһәрнең югары катлавы һәм хәлле кешеләре дача сымanрак бистәләргә чыгып җиңел чатырлар кора торган була. Яшелгә чумган шушы табигать кочагында алар ауга йөриләр, төрле күңел ачу уеннары оештыралар, ял итәләр.

Болгарның үзәк мәйданындагы Үзәк мәчетнең, ике мавзолейның һәм шәһәр эчендәге башка кайбер корылмаларның калдыкларыннан күренгәнчә, бу мәйданны һәм тулаем шәһәрне төзү үзенә бер зур план нигезендә алып барылган. Дәүләтнең башкаласы күп кенә эре Көнчыгыш шәһәрләрен хәтерләтә.

Болгар шәһәрендә ул чор өчен зур һәм яңа саналган техник корылмалар эшләнә, шәһәр төзелешенең югары формалары тормышка ашырыла. Водопровод, урамнарга таш җәю, тротуарлар сузу, агач утырту кебек эшләр шул хакта сөйли.

Шәһәрнең матур күренеше төзү материалларының төрлелегенә дә нык бәйләнгән: Болгарда таш, кирпеч, агач та, төсле штукатурка да, майолика да (пыяла бизәкләр салынган тышча һ. б. ш.) кулланылган. Шәһәрнең силуэт күренешен күп санлы архитектур формалар: күккә ашкан мәчет манаралары, мавзолей гөмбәзләре, мунча һ. б. төзелешләрнең түбәләре бизәп, җанландырып торган.

Шәһәрнең архитектур йөзе элекке, монголгача чор традицияләренә, күп буын осталары һәм төзүчеләренең кануннарына нигезләнгән. Ләкин шул ук вакытта шәһәр архитектурасында болгар төзү сәнгатенең моннан соңгы чор үсешенә бәйле күп кенә яңа сыйфатлар, яңа төр төзелешләр дә бар.



*XIII йөз ахыры — XIV йөз башы. А. Кара пулат (ханәкә дөрбә). Б. Кара пулатның эчке күренеше. В. Җами (үзәк) мәчетнең эчке күренеше.*

Автор реконструкциясе.


**Болгар архитектурасы һәм үсеше дәүләт үсешенең тарихи шартларын, аның күп кенә Көнчыгыш илләре белән булган культура-экономика мөнәсәбәтләрен чагылдыра. Монголгача чор болгар архитектурасында («Шайтан» каласы, Суар шәһәрендәге утарлы пулат) Урта Азия һәм бигрәк тә Хорезм архитектурасына тартымлык сизелеп, кирпеч өстенлек иткән булса, монгол хакимлеге чорында таш архитектура беренче планга чыга. Моның үзенең тарихи сәбәпләре бар.**

**Алтын Урданың мәмлүкләр кул астындагы Мисыр һәм сәлҗүкләр кулындагы Кече Азия, Кавказ белән урнаштырган мөнәсәбәтләре эзсез калмый. Билгеле булганча, Урта гасырларда Мисыр үзенә күрә Шәрык цивилизациясенең иң зур учакларыннан берсе һәм ислам диненең үзәге (Мәккә, Мәдинә) була. Бер яктан, монгол-татар ханнарының, мәсәлән, Иран-Әзербәйҗандагы Хулагу һәм Алтын Урдадагы Беркә ханнарның үзара дошманлашуы, икенче яктан, Хулагидларның Мисырга һөҗүм итү куркынычы Алтын Урда белән Мисырны якынлаштыра. Алтын Урда базарларга мохтаҗ була, халыкларны мөселманлаштыру һәм буйсындыру өчен «фатиха» кирәксенә, ә Мисырга көчле союздаш кирәк була.**

Сәүдәгәрләр, руханилар, төрле-төрле илче кәрваннары, Мәккә-Мәдинәгә хаҗга агылган күп санлы хаҗилар һәм сәяхәтчеләр аркылы Алтын Урда шәһәрләренә, шул исәптән Болгар шәһәрләренә, Мисыр культурасы һәм сәнгатенең үрнәкләре кайта, сәнгать идеяләре килә. Һәм киресенчә: Әмин әл-Хәлинең әйтүенә, Мисыр сәнгатендә, тулаем Мисыр культурасындагы кебек үк, Идел буе культурасының, кыпчак, болгар һ. б. төрки халыклар сәнгатенең элементлары да чагылыш таба.

Болгар иленең Мисыр белән тыгыз элемтәсе турында күп кенә археологик материаллар, шул исәптән Мисырдан килгән бизәкле чигешләр, төрле бизәнү әйберләре ачык сөйли.

1330—31 елларны Болгар патшасы Мисыр солтаны ән-Насыйрга зур бүләкләр: чигеп ау күренеше рәсемнәре төшергән кыйммәтле камалы аучы киеме; кондыз тиреләреннән теккән җилән; солтанның дәрәҗә исемнәре чигеп язылган чигүле баш киеме; алтын кәмәр, болгарда эшләнгән кылыч һәм алтын белән каелган солтан байрагы җибәрә. Болгар илчеләре дә зур бүләкләр белән әйләнеп кайталар.



*XIV йөз башы. Кече манара. Ишек янагында ташка уеп ясалган бизәкләр.*

Сакланган материаль истәлекләрдән һәм археологик калдыклардан күренгәнчә, Болгар архитектурасында һәм сәнгатендә бераз Мисыр йогынтысы сизелә. Бу өлкәдә, аерым алганда, культ хәнәләре төзелешендә, Мисырның төзү осталары, архитекторлары катнашмагандыр дип булмый, чөнки аларның шундый кайбер эшләре мәгълүм. Мәсәлән, Калаүн диган Мисыр солтаны исәбенә Кырымның Солхат шәһәрендә Бәйбарс мәчете салына.

XIII—XIV йөзләрдәге монументаль Болгар төзелешләреннән безгә тик берничә мемориаль корылма гына килеп җитә. Ләкин алары да, кызганычка каршы, табигать һәм кеше куллары тәэсиреннән акрынлап җимерелүләрендә дәвам итәләр.

1792 елны Болгарга Петр I килә. Ул чагында анда җитмешкә якын исән яки ярым җимерек монументаль архитектура истәлеге булган. XVIII гасыр өчен дә бу кадәр күп санлы кирпеч һәм таш корылма гаҗәпләнерлек хәл, билгеле. Ә инде аларның XIV—XV йөзләрдә тагын да күбрәк булганлыгын искә алсак, болгар монументаль архитектурасының ни дәрәҗәдә киң колачлы һәм югары техникалы булган икәнен аңларга, рус елъязмаларында Бөек Болгар дип аталган ил башкаласының куәтен һәм байлыгын күз алдына китерү кыен түгел.

Заманында чәчәк аткан башкала урынында хәзер өч мавзолей белән Кече Манараны да Кара пулат дип йөртелә торган корылманы гына күреп була. Соңгысының нәрсәгә хезмәт иткәнлеге билгеле түгел. Берәүләр аны мавзолей, икенчеләр, хөкем пулаты диләр. Дөресендә, ул — ханәкә, ягъни табынырга, хаҗга килүче дәрвишләргә җәйге торак урыны булган мәчет (дөрбә) булса кирәк. Бик оригиналь һәм мөстәкыйль архитектурасының гүзәллеге белән күзгә ташлана торган мәһабәт Үзәк мәчетнең дә (Җами мәчете) калдыклары гына сакланган. Әле күптән түгел генә шундый ук монументаль архитектуралы җәмәгать мунчаларының һ. б. корылмаларның кал-



*X—XIV йөзләр. Болгарларның ювелир сәнгате.*

Республика музее коллекциясеннән.

дыкларын күрергә мөмкин иде. Болары да заманында сәяхәтчеләрнең һушларын алып, матурлык һәм мәһабәтлекләре белән хәйран калдыра торган булганнар.

Архитектура типларының күп төрлелеге һәм камиллеге болгар төзүчеләренең, осталарының иҗат байлыгын, бу өлкәдәге ныклы традицияләрен күрсәтә, аларның новаторлыгы турында сөйли.

Болгар архитектурасының сакланган кадәресе, бу оригиналь һәм мөстәкыйль корылмаларның гади, гүзәл техник сыйфатлары һәм сәнгатьчә кыйммәтләре аларны Советлар Союзы халыкларының иң яхшы архитектура истәлекләре рәтеннән санарга мөмкинлек бирә.

Болгар архитектурасы Алтын Урда, Касыйм патшалыгы шәһәрләренең, башкортлардагы һәм Уралдагы күп кенә төзелешләрнең архитектурасы формалашуына һәм үсүенә зур йогынты ясаган.

Болгар иленең әзме-күпме экономик уңышлары булса да, хезмәт халкы монгол-татар изүенә каршы чыгышлар ясавын дәвам иттергән. Алтын Урда таркала башлаган чорларда Болгар иле дә төрле феодаль кисәкләргә аерыла (Болгар, Казан, Әтрәч-Шонгәт биләкләре). Аңа Алтын Урда ханнары, дала күчмәләре әледән-әле һөҗүм итеп торалар, рус ушкуйниклары (елга пиратлары) борчыйлар. Шулар нәтиҗәсендә Болгар иленең экономик һәм культура тормышы әкренләп сүнә бара, халкы туган җирләрен ташлап төньякка — Казан тирәсенә һәм көнбатышка — Идел аръягына, Зөя суының түбән агымына китә.

1431 елны кайчандыр чәчәк аткан дәүләтнең башкаласын рус князе Федор Пестрый тәмам җимереп ташлый.

Болгар халкы озакламый ханлыкка әйләнәчәк Казан тирәсендә туплана.

※ ※ ※

Мәхмүт Мөхәммәдиев

# ТЕЛ БАЙЛЫГЫБЫЗ ҺӘМ АҢАРДАН ФАЙДАЛАНУ

Сүзлекләрне бик хаклы рәвештә теге яки бу милли телнең байлыгын чагылдыра торган көзге дип атыйлар. Моннан бер ел элек Мәскәүдә чыккан «Татарча-русча сүзлек»кә карата да шундый ук бәя бирергә булыр иде. Моңа кадәр төзелгән тәрҗемә сүзлекләр белән чагыштырганда, ул татар теленең сүз байлыгын шактый тулы гәүдәләндерә. Шуның белән бергә, байтак кына сүзләр һәм фразеологик әйтелмәләрнең әлеге сүзлектән читтә калуын да икърар итмичә булмый.

Эш нәрсәдә соң? Нигә сүзлекләрдә телебезнең байлыгы тулы чагылмый? Төп сәбәп шунда: моңа кадәр төзелгән тәрҗемә сүзлекләребез картотека нигезендә эшләнмәделәр. Шуның аркасында гамәлгә яңа кергән сүзләр — неологизмнар гына түгел, хәтта матур әдәбиятта һәм башка чыганакларда киң кулланылган саф татар сүзләре, язучылар иҗат иткән уңышлы сүзъясамалар да сүзлекләрдә тиешле урын ала алмадылар, күләгәдә кала килделәр.

Хәзерге көндә Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында татар теленең аңлатмалы сүзлеге төзелеп ята. Бу сүзлектә моңарчы онытылып яткан күп кенә сүзләр яңадан яшәешкә кайтарылачак. Аларның күпчелеге, һичшиксез, киң кулланышка кереп китәр дип ышанырга кирәк.

Нинди сүзләр алар? Түбәндә шуларның берничәсен генә булса да карап үтик.

Җ. Вәлидинең аңлатмалы сүзлегендә һәм 1931 елда чыккан «Татарча-русча сүзлек»тә **аңдыру** дигән фигыль теркәлгән. Аның кайчандыр актив кулланышта йөргәнлеген классик язучыларыбызның әсәрләреннән алынган мисаллар да раслый. Мәсәлән: «Ташып киткән су калдыкларын **аңдырган** сыек болытлар, акмыйча гына салынган көе җиргә якын тора иделәр» (Ш. Камал); «Аның үзе дә, сүзе дә, йөзе дә вә күзе дә миңа әллә нинди авыр суыкны **аңдыралар**» (Г. Ибраһимов); «Күксел болытлар еракта әлләниләр **аңдыра**» (Н. Исәнбәт). Ф. Әмирхан исә шул ук сүзне **алдан белдереп, искәртеп куюю, кисәтү** мәгънәсендә куллана: «Хәят татар килгәнне күрми калса, Лиза аңар акрын гына: — Хаечка, закройся, вон мусульманин идет,— дип **аңдырудан** кире тормый вә үзенең бу эшен дустының дин тойгысына хөрмәт итүдән килә дип уйлый иде».

Мисаллардан күренгәнчә, сүз бик үзенчәлекле, шул ук вакытта җиңел аңлаешлы һәм тирән эчтәлекле. Димәк, аны, бер дә шикләнми, яңадан кулланышка кертергә мөмкин. Дөрес, Нәкый ага Исәнбәт аңдыруны диалекталь сүз (Урал татарлары диалекты [1]) дип күрсәтә. Ләкин фактлар бу фикерне кире кагалар. Асылда «аңдыру» — әдәби сүз, һәм ул бары тик язма сөйләмдә генә кулланылган булса кирәк. Югарыда китерелгән мисаллар шул фикерне куәтли.

[1] Н. Исәнбәт. Сайланма әсәрләр. I том. Казан, 1960 ел. 174 бит.

Түбәндәге шигъри юлларны укыганда, һәрбер кеше **арбау** сүзенә игътибар итми калмас: «Ягымлы эндәшеп һәм серле елмаеп, арбадың микәнни син мине шулай ук?» (М. Җәлил). Төп мәгънәсе — кемне дә булса үз ихтыярыңа буйсындыру, «сихерләү», «ырымлау»[1]. Менә тагын берничә мисал: «Миргалинең кесәсендә бадъян илә гатырша; Сәхибәне **арбай** икән бирмәс өчен Батырга» (Сәхибә матур бәете); «Авылыбызга чибәр-чибәр кешеләр килә, беренче очраганда күңелгә ягымлы гына булалар. Менә мондагы яраларны ачып салырга өлгермисең, шул аждаһалар [кулаклар] **арбап** өлгерәләр» (М. Әмир); «**Арбавын** белсәң, кара елан да карышмый» (Мәкаль). Шулай ук тирән мәгънәле, бик килешле һәм җиңел әйтелешле сүз.

Заманында Казан татарлары арасында **һөнәр, осталык, сәләт** дигән төшенчәләрне белдерү өчен **сол** сүзе кулланылган. В. В. Радлов сүзлегендә ул шул мәгънәдә бирелгән. 1931 елгы «Татарча-русча сүзлек»тә дә «искусство, мастерство, способность» дип тәрҗемә ителгән. В. В. Радлов әлеге сүзнең ясалма формаларын да бирә: **соллы, солсыз.** «Күп эшләгән оста булмас, **солын** белгән оста булыр»; «Кечтә түгел, **солда**»; «**Соллы** кеше май согынган, **солсызның** кулыннан төшкән», диелә мәкальләрдә. Бу факт үзе генә дә **солның** бик ерактан килгәнлеге турында сөйли. Әдәби чыганаклардан да мисаллар китерергә була: «**Солсыз** кулда юньсез рәвештә әйләнеп торган чыбыркы очы аның колагын ныклап тешләп алгач, ул дача капкасы янында ук чанадан тәгәрәп төшеп калды» (Ш. Камал); «Кулына алып тотынгач та, ул шундук сүгенүеннән дә, юкка-барга үрталуеннән дә туктады, куллары да калтыранмады, киресенчә, **соллы,** төгәл хәрәкәтләнде» (Н. Фәттах).

Димәк, әлеге сүз бөтенләй үк онытылып бетмәгән, сирәк булса да, язучыларның каләм очларына килеп эләгә икән. Китерелгән мисаллар **сол, соллы, солсыз** сүзләренең мәгънәви йөкләре шактый берәгәйле, телебезгә яхшы хезмәт итүгә сәләтле булуын күрсәтәләр.

В. В. Радлов сүзлегендә **төмсәрү (чырай бозылу, йөзгә усаллык билгеләре чыгу** мәгънәсендә) дигән фигыль бар. Мәгънәсе һәм ясалышы белән дә үзенең нигезе **төмсәгә** бик якын тора. Күрәсең, **төмсә** сүзе кайчандыр Казан татарлары сөйләшендә актив кулланылган. Ә әдәби чыганаклардан мисаллар табу шактый кыен. Бердәнбер чыганак — Ш. Камал әсәрләре. «Акчарлаклар» повестенда язучы аны түбәндәге мәгънәләрдә куллана.

I. **Зәгыйфь, тоныкъ:** «Факелларның **төмсә** һәм юеш утлары караңгы диңгез буйлап су өстеннән күңелгә ягымлы, йомшак нур сызыклары җибәреп торалар».

II. **Ягымсыз, тупас, кырыс:** «Эх,— диде (Шәрәфи агай),— элекке куршик яхшы кеше иде... Быел килмәгән, авылында калган, инде энесе аның урынында. Начар, әллә нинди **төмсә** нәрсә».

III. **Ямьсез, караңгы:** «Күк йөзен соры сыек болытлар каплап алган һәм шушы уңып төсе киткән алама коленкорга охшаулы ягымсыз һәм **төмсә** болытлар юаш кына тирбәнеп яткан диңгезгә салынып ук тора иделәр».

Күргәнебезчә, **төмсә** сүзенең ачык төсмерләнгән өч мәгънәсе бар. Әмма Җ. Вәлиди сүзлегендә аның беренче, ә яңа «Татарча-русча сүзлек»тә икенче мәгънәсе генә бирелгән.

Мәскәүдә чыккан «Татарча-русча сүзлек»тә **карарсыз, карарсызлык** дигән сүзләр алынган. Әмма шул ук сүзләрнең уңай формалары **(карарлы, карарлылык)** бирелмәгән: чөнки тезүченең кул астында мондый сүзләрнең барлыгын исбатларлык материал булмаган. Ш. Камал әсәрләрендә табылган мисаллар аларның тулы канлы, икеләнүсез кабул ителерлек сүзъясамалар булуына ышандыралар. Мәсәлән: «Мохтар **карарлы** тавыш белән: — Ләкин моннан болай [Сәхипҗамалны] күрәләтә җәберләтергә ярамый,— диде» (Таң атканда); «Дунаевның зәңгәрсу күзләреннән эшчәнлек, **карарлылык,** кискенлек чәчелеп тора» (Матур туганда).

Әгәр бу сүзләрне бүгенге көндә кулланылышта йөргән **катгый, катгыйлек** синонимнары белән янәшә куеп карасак, Ш. Камал тарафыннан сайланганнарының уңышлырак, максатчанрак икәнлеген күрербез.

**Киңенчә** сүзенең дә беренче кулланылыш мисаллары Ш. Камал әсәрләрендә очрый: «Шәһәр думасының ишекләре **киңенчә** ачык, кешеләр кырмыска шикелле

---

[1] В. В. Радлов. Опыт словаря тюркских наречий. I том. СП. 1893 ел.

кайнаша» (Таң атканда). Ш. Камалдан соң байтак еллар үткәч, шул ук сүз икенче бер язучының әсәренә килеп керә: «Сыерлар абзарының урта ишеге **киңенчә** ачык» (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр!). Бу мәгънәне икенче берәүләр бөтенләй башка сүзләр белән белдерәләр. Мәсәлән: «Бизәкле сары капка **төбенәчә** ачылды» (А. Расих. Хәсәен Ямашев); «Ида урам ягындагы тәрәзәне **иңеләй** ачып җибәрде» (Н. Фәттах).

Барлый, тикшерә башлагач, бер үк мәгънәне белдерә торган өч сүз табылды: **киңенчә — төбенәчә — иңеләй** (диалекталь сүз). Кызганычка каршы, аларның берсе дә сүзлекләрдә теркәлмәгән.

Радио тапшыруларның берсендә диктор мондый белдерү ясый: «Җырчыга эстрада оркестры ярдәм итә».

«Ярдәм итү» тезмәсенең үз урынында түгеллеге шунда ук колакка бәрелә. Чыннан да, бездә «сопровождать», «аккомпонировать» фигыльләренең мәгънәсен бирә торган уңышлы сүз юк икән. Ә менә Ш. Камал бу мәсьәләдә беркадәр эзләнгән диясе килә. Чагыштырып карыйк: «Фәтхи, кысык күзләрен ача алган хәтле ачып, корьән укыган тон белән рәк, «Зиләйлүк»не җырлап алып китте. Хөснетдин скрипкада, дәртле генә иттереп, Фәтхигә **кушмалык итте»** (Таң атканда). Бер нәрсә бәхәссез: **ярдәм итүгә** караганда язучы сайлаган **кушмалык итү** тезмәсе мәгънәне төгәлрәк белдерә.

Сүз уңаеннан шуңа охшашлы тагын бер мисал китереп үтик. Билгеле булганча, бездә **тупик** сүзенең татарча атамасы юк. «Социалистик Татарстан» газетасында «Терәлештә» исемле бер мәкалә басылган иде. Аны русчага тәрҗемә итсәк, «В тупике» дигән мәгънә аңлашыла. Димәк, мәкаләнең авторы (дөресрәге, тәрҗемәче) **терәлеш** сүзен **тупик** мәгънәсендә кулланган. Бу очракта **терәлештә** сүзе үзен чыннан да аклый. Әмма рус телендәге **дело зашло в тупик** яки **стать в тупик** тәгъбирләрен **эш терәлешкә керде** яки **терәлештә калу** дип тәрҗемә итсәк, ул сәер һәм ясалма яңгырар иде. Нишләргә соң? Эзләп карасаң, бездә утызынчы елларга кадәр үк моның махсус атамасы булган икән бит! Менә ул: «Биктимер абзыйның да быел эше **көрчеккә терәлде»** (Г. Толымбай); «Җир өләшү дигәннәре бик четерекле эш икән ул үзе. «Өләшүен өләшергә, әмма ничек өләшергә?» — дип, **көрчеккә** терәлеп кала кешеләр» (Ш. Маннур). 1931 елгы «Татарча-русча сүзлектә» **көрчек** — граница, финиш (ягъни чик, нәрсәнең дә булса ахыры, бетеме) дип тәрҗемә ителгән. Шагыйрь З. Мансур да ул сүзне шул ук мәгънәдә кулланган: «Каһәрләнгән сугыш ярасы соңгы **көрчек** куйган егеткә».

Ш. Камал әсәрләрендә бик уңышлы кулланылган тагын бер сүз: **өлгерештән**. Җ. Вәлиди сүзлегендә ул теркәлгән. Шуннан соңгы сүзлекләрдә күрсәтелми. Аны яңадан сүзлеккә кайтарырга кирәк. Түбәндәге мисаллар шул турыда сөйли: «Без поездан төшерү вакыйгасына кадәр башыбыздан үткәннәрне бер-беребезне бүлепбүлеп **өлгерештән** сөйли идек» (Бәхет эзләгәндә); «Берничә кеше **өлгерештән** аңа каршы җавап кайтара» (Таң атканда); «Управага керсәң, ялтыравык төймәле чиновниклар, тугызга бөгелеп, сиңа баш иялар, ...**өлгерештән** тыкшынып, кресло күрсәтергә ашыгалар» (Матур туганда).

«Русча-татарча сүзлек»ләрнең барысында да **плакучий** сүзе **бөдрә** дип тәрҗемә ителеп килә. Ләкин бу сүзләрнең мәгънәләре туры килешеп җитми. Шуңа күрәдер, ахры, соңгы елларда язучылар **бөдрә** сүзе урынына башка атама эзли башладылар. Г. Ахунов, мәсәлән, **плакучий** сүзен **елак** дип калькалаштыра: «Пальмаларны, **елак** талларны коендырып, ...чиләкләп-чиләкләп яңгыр явып узды». Г. Әпсәләмов исә бу сүзнең тагын да төгәлрәк тәрҗемәсен тәкъдим итте. «**Еламсыр** таллар белән уратып алынган тын инештә дөнья яңгыратып бакалар кычкыра иде». Озак та үтми, **еламсыр** сүзе бер-бер артлы төрле язучыларның әсәрләрендә, очеркларда күренә башлый. «Инеш буендагы **еламсыр** таллар кинәт кенә берьюлы күңелне биләп алалар» (Д. Сирай); «Каршыда әлеге иманнарнең сеңелләре, **еламсыр** каеннар моңаеп торалар» (М. Әмир); «**Еламсар** талларга тия-тия астан инеш ыңгырашты» (А. Гыйләҗев). Чыннан да, **еламсар-еламсыр** сүзе **ботаклары салынып, салпыраеп торган** дигән мәгънәне, **бөдрә** һәм **елак** сүзләренә караганда, образлырак, төгәлрәк ача. Тик монда кушымчадагы ике төрле язылышның берсен сайларга кирәк. Минемчә, әдәби норма итеп **еламсыр** вариантны алынырга тиеш. Бу сүз инде әдәби кулланышка кереп киткән, аны сүзлеккә теркисе генә кала.

Типтәрләр сөйләшендә **өрфия** сүзе пәрәвез, ә кайбер сөйләшләрдә **үтә күренмәле нәфис тукыма, нечкә, нәфис җептән бәйләнгән әйбер мәгънәсендә йөри икән**[1]. Язучы Г. Әпсәләмов шул сүзнең икенче мәгънәсен әдәби кулланышка кертә: «Ак **өрфия** шәле иңнәренә шуып төшкән Надежда Ивановна,... еракка-еракка карап, бакча буйлап бара» (Сүнмәс утлар); «Казан өстенә, әйтерсең, үтә күренмәле алсу **өрфия** каплаганнар. Шушы алсу **өрфия** астында... тылсымлы тынлык һәм изге тынычлык хөкем сөрә» (Ак чәчәкләр).

Матур сүз бит! Хәзер ул яңа «Татарча-русча сүзлек»кә дә кертелгән. Шулай итеп, диалекталь сүз әдәби телгә кергән, киң кулланышка юл алган.

Җирле сөйләшләрнең мондый мөмкинлеге бик зур. Фикеребезне куәтләү өчен, бер генә мисал китерик. «Социалистик Татарстан» газетасында «Соңгарган эш үрчеми» исемле мәкалә басылды. Кайберәүләр, бәлки, эш куян түгел бит, ул ничек **үрчи** ала икән, дип аптырап та калганнардыр. Җирле сөйләшләрдә исә **эш алга бармый** дигән мәгънәне эчтәлеклерәк, аңлаешлырак бирә торган, кызганычка каршы, әле һаман да гомуми кулланышка кереп китә алмый яткан **ырау** сүзе бар. Соңгарган эш **ырамый,** дип әйтелсә, минем өчен, мәсәлән, бик аңлаешлы. «Эшемнең бер дә **ырамы** юк бүген» дип сөйләү дә күңелгә хуш килә. Әдәби чыганакларга мөрәҗәгать итик: «Бияләйкәйләргә йоннар эрлим, нигә лә минем орчыгым **ырамый**»; «Бергәләп эшләгән эш **ырамлы** була»; «Сөйләшеп барсаң, юл **ырамлы** була» (Н. Исәнбәт. Татар халык мәкальләре); «Мин һич кенә дә Сабирның кеенә басып бара алмыйм... Аның белән бару шундый **ырамсыз**» (Н. Исәнбәт. Куян мажаралары). Мисаллар бу фигыльнең исем һәм сыйфат формалары да барлыгын күрсәтәләр: **ырам, ырамлы, ырамсыз.** Болары да игътибарга лаеклы. Билгеле, хәзергә алар барысы да аңлатмалы сүзлеккә диалекталь сүзләр итеп кенә кертеләләр. Әмма, массалашып, әдәби тел формасына күтәрелүләре дә мөмкин. Әгәр күренекле тел осталарыбызның әсәрләрен тикшерә башласак, дөньяга чыга алмый яткан мондый сүзләрне шактый күп табарга булыр иде. Димәк, сүзлек хәзинәбезне баету өчен, матур әдәбият һәм халык авыз иҗаты әсәрләрен игътибар белән күзәтергә, аларның телен игътибар белән өйрәнергә кирәк икән. Шул нигездә генә сүзлекләребезне тулыландырырга, хаксызга онытылган яки пассивлашкан сүзләр һәм мәгънәләрне киң массага җиткерергә мөмкин.

Яңа сүзләр әдәби әсәрләрдә генә түгел, фәнни-популяр әсәрләрдә, дәреслекләрдә һәм вакытлы матбугат битләрендә дә даими рәвештә туып торалар. Ул чыганакларда да әле барланмаган, сүзлекләргә теркәлмәгән, әмма әдәби тел хәзинәбездә урын алырлык сүзләр очратып була. Мәсәлән: **икенчел чимал, йортбасар, йортлыксыз, йогышлау, ыргым, эзтабар** кебек сүзләр башлап вакытлы матбугатта күренделәр. Барысына да аерым-аерым тукталмыйча, спортка бәйләнешле **ыргым** сүзен генә алып карыйк. «Социалистик Татарстан»да ул ике мәгънәдә кулланылып килә. Беренчесе — штанг күтәрү ысулы. Русчасы — рывок (мәсәлән, ыргымда ул 135 кг күтәрде). Икенчесе — йөгерү ярышында, тизлекне кинәт арттырып, алга омтылу. «Ул зур темпта **ыргым** ясый. Башка йөгерешчеләр аның артыннан иярергә тырышып карасалар да, булдыра алмадылар». Сүз һәр ике мәгънәсе белән дә кабул ителерлек.

Бездә кайбер гади генә төшенчәләрне белдерү өчен дә татарча сүзләр юк икән. Мәсәлән, 4 томлы «Русча-татарча сүзлек»тә вклад, вкладка, вкладчик, вкладыш, втулка кебек тәрҗемәсез бирелгән сүзлар байтак кына. Мондый очракларда нишләргә соң? Чынлабрак уйлап, эзләп карасаң, боларның да күпчелегенә татарча сүзләр табылыр иде. Кайбер иптәшләр, бәлки, бу кеше рус алынмаларына үгисетеп карый икән дип уйларлар. Һич алай түгел. Татар теленең рус теле аша кергән алынмалар исәбенә туктаусыз тулылана, баеп баруы — һәркемгә билгеле факт. Бирегә бәхәс алынма булу дәрәҗәсенә күтәрелмәгән һәм аңа дәгъва итә алмый торган сүзләр турында бара. Рус сүзләрен куллануда талымсызлык күрсәтү мисаллары вакытлы матбугат битләрендә дә, кайбер язучыларның әдәби әсәрләрендә дә очрап тора. Газета битләреннән берничә мисал: «Балыкны суыткычка куймыйча да бер-ике көн **свежий** килеш сакларга була»; «Экономик **служба** җитәкчеләре», «китапханә

---

[1] Ә. Өфләтунов. БАССРның көнбатыш, көньяк-көнбатыш өлешендә яшәүче татарлар сөйләшенең тел үзенчәлекләре. Кандидатлык диссертациясе. 1960 ел. 156 бит.

**работниклары»**; «1966 елда радистлар **многоборьесы** буенча мин Татарстан чемпионы булдым». Күп чәйнәлгән **ничья** сүзе турында әйтеп тә торасы юк: **ничьялар дәвам итә, ничьялар туры, ничьясыз уен** кебек тезмәләр әледән-әле күзгә чагылып тора. Тырышканда бу мисаллардагы рус сүзләрен татарча тәгъбирләр белән дә биреп булыр иде.

Э. Касыймовның «Дөньяда ни иң ямьле?» дигән хикәясендә мондый бер җөмлә бар: «Турней катламына җиткәч, токым ишелеп, **прихват** ясалды». Бу — рус сүзен куллануның бик характерлы мисалы. Нефтьчеләргә һәм язучының үзенә **прихват** сүзе, бәлки, аңлашыла торгандыр. Ләкин гади укучыга ул аңлашылып җитми. Аны хәтта рус теленең 17 томлык сүзлегеннән дә таба алмыйсыз. Шул ук автордан тагын бер мисал: «Әлбинә... ашыгып каен **посадкасы** буеннан сузылган сукмак белән китте». (Бир кулыңны, дустым!) Монда да, рус сүзенә мөрәҗәгать иткәнче, башта беркадәр уйлану, ул сүзне татарча бирү **мөмкинлеген эзләү** кирәк иде. Мәсәлән, болай фикер йөртеп карыйк: **посадка** сүзе **посадить** фигыленнән ясалган. Безнең телдә **утырту** фигыленнән шул мәгънәгә туры килә торган исем ясап булмыймы икән? Бик була: утырту — утыртма. Биредә бернинди дә ясалмалылык яки тел законнарын бозу юк дияргә мөмкин. Ма-мә кушымчасы белән фигыльләрдән исем ясау — актив күренеш. Инде әлеге җөмләне үзебез «эзләп тапкан» татарча сүз куеп укып карыйк: «Әлбинә... ашыгып каен **утыртмасы** буеннан сузылган сукмак белән китте». Ничек уйлыйсыз, аңлашыла бит? Язучы әйтергә теләгән фикергә бернинди дә зарар килмәде шикелле. Киресенчә, оттык кына кебек.

«Аэровокзалда **посадка** башлануын көтеп утыра идем» (Г. Мөхәммәтшин); «Профессор... анализның нәтиҗәләрен, **снимокларын** күрсәтте» (Г. Әпсәләмов). Мондагы **посадка, снимок** сүзләрен татарчалаштырып бирү дә әллә ни кыен булмас иде. М. Хәсәновның «Юллар, юллар» романында мондый русча сүзләр аеруча күп. Менә алар: **перегиб, культура очагы, расценка, самосвал, достояние, яшәү средствосы, специалист, рядовой эшче, балагур, обед вакыты...** Инде биредәге рус сүзләренең кулланышын татар әдәби теленең бүгенге торышы өчен табигый һәм зарури хәл дип саныйбыз икән, ул чагында икенче бер әсәрләрдә **служащий, троеборье, пятиборье, захват, пересадка, завтрак, ужин** кебек сүзләр очраганда гаҗәпләнергә һич урын калмаячак. Бер уңайдан **мобилизовать итү, мариновать итү, командировать итү, командовать итү** кебек фигыльләр турында да берничә сүз әйтү урынсыз булмас. В. Исәнгалиева үзенең «Нигезе рус теле алынмаларыннан торган төрки фигыльләр» исемле хезмәтендә мондый фигыльләрне куллану күп кенә төрки телләрдә әдәби нормага әйләнгән яки әйләнеп бара, дип билгеләп үтә. «Рус инфинитивы+итү ярдәмче фигыле тезмәсе бигрәк тә татар һәм башкорт телләрендә киң кулланыла»[1],— ди ул. Башка төрки телләр өчен ничектер, анысына керешмибез. Әмма татар әдәби теленең хәзерге торышы бу фикерләрне кире кага. Дөрес, кайчандыр **грунтовать итү, монтировать итү, мариновать итү, дифференцировать итү, редактировать итү** дип сөйләгәннәр һәм язганнар. Әмма хәзер инде бу үтелгән, артта калган этап дип кенә карала. Һәм халык әлеге сүзләрне татар теленең үз эчке законнарына нигезләп куллана. Мәсәлән: **грунтлау, монтажлау, маринадлау, дифференциацияләү** яки **дифференциация ясау, редакцияләү**. Кушымчалау ысулы белән биреп булмаганда да, **«...ать»** формасыннан котылу мөмкинлекләре табылды. **Командировать — командировкага җибәрү; командовать — командалык итү; дирижировать — дирижерлык итү; цитировать — цитата китерү, сигнализировать — сигнал бирү** һ. б. Кыскасы, югарыда сөйләнгән күренеш — телнең үз эчке мөмкинлекләреннән файдаланып үсүен, камилләшүен күрсәтә торган фактларның берсе. Шул җирлектә туган тел үзенең табигате өчен ят элементлардан арына бара.

Сүзләрдән, сүзләрнең мәгънәләреннән дөрес файдаланмау, аларны урынсыз куллану очраклары турында да берничә сүз әйтеп китәсе килә. Г. Кутуйның бу хакта язган бик матур фикере бар: «Үзенең төп мәгънәсенә җавап бирерлек рәвештә урынлы кулланылган сүз фикергә җиңеллек китерә, уйның, максатның ачык булуына ярдәм итә. Уйлап әйтелгән, уйлап китерелгән сүзләр ике төрле мәгънәнең килеп

---

[1] В. Исенгалиева. Тюркские глаголы с основами, заимствованными из русского языка. Алма-Ата. 1966 ел. 46 бит.

чыгуына юл калдырмыйлар... Урынлы кулланылган сүз — ул мәгънә дә, идеология дә, ул матурлык та»[1].

Чыннан да, сүзләр үз урыннарында кулланылмаганда, сәер бер хәл туа: газета яки китапны укудан кинәт туктыйсың да, бу нәрсә икән, нигә болай әйтелде икән, дип уйлый башлыйсың. Фикер таркала, игътибар бөтенләй читкә юнәлә. Сүзне озакка сузмыйча, мисалларга мөрәҗәгать итик. Башта газета битләреннән берничә мисал: «СССР халыкларының **мәһабәт казанышлары»**. **Бөек казанышлар, зур җиңүләр** дип әйтү әле табигый яңгырый. **Ә мәһабәт казаныш** акылга ятышып җитми. Чөнки **мәһабәт сүзе** нигездә конкрет төшенчәле сүзләрнең аерылмышы буларак кына кулланыла. Мәсәлән: **мәһабәт бина, мәһабәт гәүдәле кеше...**

«Бу көрәштә Куба безнең **кайнар булышлыгыбыздан** файдалана». Монысы инде **горячая поддержканың** уңышсыз аудармасы. Кайнар теләктәшлек күрсәтү, дип, бәлки, әйтеп була торгандыр. Әмма кайнар **булышлык күрсәтү** дип сөйләүне берничек тә аклап булмый.

«Утыз-кырык минуттан әлеге **сеңге** яки бораулар белән коралланган сунарчыларның эзен дә күрмәссез». Сүз һәвәскәр балыкчылар турында бара. Тик алар инде бозны **сөңге** белән түгел, ә **сөймән** белән тишә торганнардыр. Кайбер язучылар да сүз куллануга тиешле игътибар биреп җиткермиләр. Бу фикерне мисаллар белән дәлилләргә мөмкин. «Кырыкка да җитмәгән бу ябык ханым хәзер алтмыш яшьлек **карый иде»** (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). Татар болай **сөйләми.** Бу — тәрҗемә. Романның журнал вариантында ясалган әлеге хата китап итеп чыгарганда да төзәтелмәгән. Күрәсең, язучыга бу турыда искәртүче булмагандыр, үзе дә абайлап җиткермәгән. Яшь язучы Х. Сарьянның «Әткәм һөнәре» повестенда да шундыйрак сүз очрый: «Таһир турында сүз чыккач, әле генә кичергән шатлык янына **егетләнеп** кайгы килеп басты». Кире күренешне уңай мәгънәле **егетләнеп** фигыле белән характерлауның уңышсыз икәнлеген автор үзе дә сизеп алган: китап басмасында ул аны **әрсезләнеп** дигән фигыль белән алыштырган. Һәм бик урынлы.

Бездә үз урынында кулланылмаган сүзләр байтак. Әмма аларны сиземләү һәм дөрес төгәллеген аңлату шактый кыен. Чөнки алар аерым язучылар тарафыннан күп кенә еллар шулай кулланылып килгәннәр, игътибар итүче булмаган, ничектер күнегелә башланган. Мәсәлән, **йотлыгу** һәм **йотылу** сүзләренең хәл фигыль формасында кулланылу очракларын алып карыйк. Алдан ук искәртеп куярга кирәк: бу ике фигыльнең, үзара мәгънәви аралашып, ялгыш кулланыла башлавына җирле сөйләшләр сизелерлек йогынты ясаган булсалар кирәк. Әгәр бер төркем язучылар, мәсәлән, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, М. Фәйзи, һ. Такташ, Г. Кутуй, Ф. Кәрим, Х. Туфан, А. Шамов, М. Әмир, С. Шакир, С. Сөләйманова, И. Салаховлар **йотылып уку** (тыңлау, карау, күзәтү) дип язсалар, икенче бер төркем, мәсәлән, М. Максуд, М. Гали, М. Садри, Г. Әпсәләмов, А. Гыйләҗевлар, җирле сөйләштә кулланылганча, **йотлыгып** уку (тыңлау, карау, күзәтү) дип язуны дөрес саныйлар. Ә өченчеләре, ике сүз арасындагы мәгънә аермалыкларына игътибар итмичә, аларны синоним сүзләр итеп куллана башлыйлар. Болай өстән караганда, монда берниндә ялгышлык та юк шикелле. Әмма ныклабрак тикшерә башласаң, сүзгә үзенә хас булмаган мәгънәләр дә йөкләтелгәнлеге ачыклана. Менә берничә мисал:

1. «**Йотылып**, әкият укыганнан битәр мавыгып укыдык без аларны» (М. Әмир. Агыйдел); «Мәхәббәт хакындагы китапларны **йотлыгып** укый башлаган кеннәре иде аның» (А. Гыйләҗев. Бердү).

2. «Якубның җанга якын сүзләрен **йотылып** тыңладылар» (И. Гази. Онытылмас еллар); «Якуб үз тирәсендә сырышып, **йотлыгып** тыңлап утыручы кешеләргә ялт-йолт карап алды» (Шунда ук).

3. «Раил үзе өчен бөтенләй ят яңа нәрсәләрне **йотылып** тәрәзәдән күзәтә» (А. Расих); «Гыйлфан да, Җәгъфәр дә Хесаеннең һәрбер хәрәкәтен **йотлыгып** күзәтә башладылар» (А. Расих. Хесаен Ямашев).

4. «Бала күз яшьләренә **йотлыга-йотлыга:** — Әнием толмый-й... — диде» (Г. Гобәй. Маратның язмышы). «Илсөяр яшенә **йотыла-йотыла** әтисенә сырышты» (Аныкы ук. Маякчы кызы).

---

[1] Г. Кутуй. Яза белеп языгыз. Язучылык хезмәте турында. Казан. 1958 ел. 149 бит.

5. «Бер тын каз өйрәсен бик тәмләп **йотлыгып** ашадылар» (Ә. Еники. Рәшә); «Солдатларның... концертларны балалардай **йотлыгып** тыңлауларын сөйләде ул» (Шунда ук).

6. «Җыелышта булды Бану да, **йотылып-йотылып** тыңлады» (Н. Баян. Сайланма әсәрләр. 1952); «Мин хәл җыям бүген, Кырым синдә, **йотылып** сулыйм тәмле һаваңны» (Шунда ук).

Бу җөмләләрне игътибарсыз гына укып үткәндә, **йотылып** һәм **йотлыгып** сүзләренең һәр ике кулланышның берсендә ялгыш икәнлеген искәрмәскә мөмкин. Әмма аларны, рәттән куеп, чагыштырып карагач, уйланырга мәҗбүр буласың: «йотлыгу» һәм «йотылу» бер үк мәгънәне белдермиләр бит, ничек итеп алар синонимлашып киткәннәр (1—4 мисаллар) яки ни өчен «йотылу» фигыленең мәгънәсе «йотлыгу» фигыленә йөкләнгән һәм киресенчә (5—6 мисаллар)? Бигрәк тә бер үк язучының хәтта бер үк әсәрендә шундый кулланыш күзәтелү үзеннән-үзе сагаерга мәҗбүр итә. Әгәр мисалларга иярсәк, **йотлыгып** ашарга, эчәргә, суларга, иснәргә, тәмәке суырырга һәм укырга, тыңларга, күзәтергә, карарга да мөмкин икән. Шулай ук **йотылып** укыйлар, тыңлыйлар, карыйлар, күзәтәләр һәм эчәләр, сулыйлар, исниләр, тәмәке дә суыралар икән. Гаҗәп түгелме? Ә бит бу сүзләрнең һәркайсының үзенә генә хас мәгънә үзенчәлекләре бар. Йотлыгу — ачыгу, бик нык ашыйсы килү яки бик нык сусау мәгънәләрен аңлата. Димәк, бу фигыль физиологик күренешне белдерә. Ә йотылу («йоту» фигыленнең төшем юнәлеше) күчмә мәгънәдә берәр нәрсә белән артык мавыгу, бөтен игътибарны шуңа юнәлтүне аңлата. Монысы — рухи, психологик күренеш. Аларның «ып» формасындагы кулланышлары да (йотлыгып, йотылып) шушы төп мәгънәгә, һәр сүзнең асыл эчтәлегенә нигезләнергә тиеш. Югарыда китерелгән мисалларның бер өлешендә бу закончалык сакланган, ә икенче өлешендә (һәр парның икенче мисалын кара) сакланмаган. Әгәр бу ике сүзнең кулланышындагы мондый эзлексезлеккә чик куярга телибез икән, шушы закончалыктан чыгып эш итәргә кирәк. Ул вакытта дөрес кулланыш **йотлыгып** ашау (эчү, иснәү, сулау, тәмәке суыру) һәм **йотылып** уку (тыңлау, карау, күзәтү) булырга тиеш.

Менә мондый күзәтү, анализлардан соң, **йотлыгу** һәм **йотылу** фигыльләренең мәгънәләре аңлатмалы сүзлектә түбәндәгечә бирелделәр:

ЙОТЛЫГУ ф. 1. Бик нык ачыгу яки сусау. **Җаен койрыгын [ашаган] йотлыкмас.** Мәкаль. **Бер чишмәнең суын эчеп бетерердәй булып йотлыктым, ирен кренгә ябышты.** Х. Садрый. // рәв. мәгъ. **йотлыгып.** Ашыгып, кабаланып, туймастай булып. **Зөлфия йотлыгып су эчә.** Р. Ишморат.— **Өендә ач торган шикелле, анда [кунакка] баргач, йотлыгып ашап утыру бер дә килешкән эш түгел.** Ф. Әмирхан. **Чыклы төнге һаваны йотлыгып сулаудан [Фәттахның] киң, таза күкрәге бер югары калка, бер түбән төшә.** Ф. Кәрим.

2. Ашаган, эчкәндә төелү, чәчәү. **Авыру суны бер-ике йоткач ук йотлыкты, башын бер читкә тартты.** А. Шамов. **Күп чәйнәп аз йотсаң, йотлыкмассың.** Мәкаль.

3. Күч. Ашыгу, дулкынлану, каушаудан һ. б. тотлыгып сөйләү, уку, авазларны яки сүзләрнең ахырын ачык әйтеп бетермәү. **[Егетнең] балалар кебек йотлыгуы, бер сүзне бетерми икенчене башлаулары ничектер кызыклы вә күңелле тоела иде.** Ш. Камал. // рәв. мәгъ. **Кыз сулу алды һәм — йотлыгып**

ЙОТЫЛУ ф. 1. Төш юн. к. йоту. 2. Күч. Берәр нәрсә белән артык мавыгу, бөтен игътибарны шуңа юнәлтү. **Солдатларның инде үзара сөйләшәселәре дә килми башлады — бик күңелсез уйларга йотылганнар иде.** Ә. Еники. **Матур сахра, моңлы тавышларга Безнең эшче тәмам йотылды.** М. Гафури //Кемгә яки нәрсәгә дә булса күзне алмыйча текәлеп карап тору турында. **Хатын аңар йөзе белән әйләнде, күз карашы белән егеткә йотылды.** Г. Ибраһимов. **Чем кара күзләр күксел тауларга йотылганнар.** М. Әмир. // рәв. мәгъ. **йотылып. Зур игътибар белән,** бик нык бирелеп, кызыксынып. **Сәгыйдә китапны йотылып укый башлый.** Һ. Такташ. **Барысы да карт солдат янына җыелып, аны шул хәтле йотылып тыңладылар, хәтта ишек ачылганын да сизми калдылар.** К. Нәҗми. **Хәят рәсемгә йотылып карый.** Г. Кутуй.

3. Күч. Таралып, ераклашып юкка чыгу (тавыш, төтен, дулкын һ. б. ш.). **Гөрселдәгән тавыш урман эченә кереп йотылды.** Г. Гобәй. **Затон ярлары арасында йөрүче паром эзеннән көмеш тимгелләре дә озакка бармыйлар, шомаралар, тигез катлау**

өстәп куйды: — ...Иптәшләр... мине калдырмагыз! А. Шамов.

булып, койрык артында йотылалар. К. Нәҗми.

Сөйләгәннәргә йомгак ясап, шуны әйтергә була. Безнең сүзлек хәзинәбез гаять бай, тик ул әле тиешенчә барланмаган гына. Шуның аркасында күп кенә сүзләребез актив кулланышка керә алмыйча яталар, кайберләре бөтенләй онытылуга йөз тотканнар. Хәзерге көндә Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында татар теленең ике томлык аңлатмалы сүзлеге төзелеп бетеп, аны редакцияләү эше бара. Аның басылып чыгуы тел байлыгыбызны, тел культурабызның үсешен тулырак күзалларга мөмкинлек бирәчәк. Сүзлек шактый бай картотека материалы нигезендә төзелде. Аның төп һәм иң зур өлешен классик һәм күп кенә күренекле язучыларыбызның әсәрләреннән тупланган сүзләр алып тора. Болардан тыш картотека фәнни-политик һәм фәнни-популяр әдәбияттан, 5—10 класслар өчен чыгарылган мәктәп дәреслекләреннән һәм халык иҗаты әсәрләреннән сайлап җыйган сүзләр белән тулыландырылды. Шуның өстенә сүзлек төзүче иптәшләр картотекага салынмаган барлык игътибарга лаеклы әдәби әсәрләрне карап чыктылар, вакытлы матбугатны (газета-журналларны) системалы рәвештә күзәтеп бардылар һәм алардан кирәкле сүзләрне сайлап алдылар.

Телебезнең байлыгын барлау буенча Институтның диалектологлары да гаять зур эш башкардылар. Алар, татарлар яши торган төп төбәкләрнең тел үзенчәлекләрен өйрәнеп, җирле сөйләшләрдә генә сакланып, яшәп килгән бик зур лексик байлык тупладылар һәм шул байлыкны эченә алган зур күләмле «Диалектологик сүзлек» төзеп бетерделәр. Шулай итеп, халкыбызның әдәби тел даирәсеннән читтә торган искиткеч бай хәзинә киң масса укучы карамагына тапшырылачак.

Матур әдәбият, гомумән фән, культура үсеше әдәби телебезнең өзлексез баюын, камилләшә баруын таләп итә. Күренекле тел остасы Гомәр ага Бәширов әйткәнчә, «күптән түгел генә үз җирлегендә чәчәк ату хокукы алган һәрбер милли тел кебек үк, безнең татар әдәби теленең дә үсү мөмкинлекләре зур»[1]. Сүз дә юк, танылган язучыларыбыз, вакытлы матбугат хезмәткәрләре бу юнәлештә җитди эшчәнлек күрсәтәләр. Әмма без әле телне баетырга ярдәм итә торган чыганаклардан — булган сүзлек хәзинәбездән, телебезнең сүз ясау мөмкинлекләреннән, җанлы сөйләшү теленнән, җирле сөйләшләрдән тулы файдалана белмибез. Бездә телгә игътибарсызлык үзен нык сиздерә, тел үсешен аңлы рәвештә тәртипкә салу җитешеп бетми.

Моннан ике дистә еллар элек күренекле телчебез Ш. Рамазанов: «Гомумән культура дәрәҗәбезне үстерү белән бергә, лингвистик белемебезне, тел культурабызны да үстерергә, телебезгә мәхәббәт һәм сизгер мөнәсәбәт тойгылары тәрбияләргә тиешбез»[2], — дигән иде. Бу сүзләр хәзер дә көчендә кала.

◆◇◆

[1] Г. Бәширов. Сайланма әсәрләр. Казан. 1965. 2 том. 301 бит.
[2] Ш. Рамазанов. Татар теле буенча очерклар. Казан. 1954. 198 бит.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ БЕЛГЕЧЕ



Үзеңнең укучың турында язу җиңел дә һәм кыен да. Җиңел, чонки аның бөтен үсеше синең күз алдыннан узган, ә кыенлыгы аның иҗатына объектив бәя бирә алуга бәйләнгән.

Баян Гыйззәт 1937—1941 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган чакларында ук үзен өметле каләм иясе итеп күрсәтте. Муса Җәлил 1940 елда Язучылар союзы идарәсендә ясаган отчет докладында 35 яшь автор арасында, аеруча күтәрелеп, үсеп килүчеләр итеп, Хәй Вахит, Г. Әпсәләмов, Б. Гыйззәт иптәшләрне күрсәтергә була дип әйткән иде [1].

Илебезгә фашист илбасарлар басып кергән дәһшәтле сугыш еллары яшь авторны каләмен винтовкага алыштырырга мәҗбүр итте. Ул, институтны тәмамлап чыгу белән, 1941 елда армия сафларына алынып, башта замполит һәм взвод командиры булып хезмәт итә. Аннары, минометартиллерия училищесында укып, рота командиры була, күп сугышларда катнаша. 1943 елда Советлар Союзы Коммунистлар партиясе сафына алына. Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен ике мәртәбә Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

Армиядән кайткач, 1946—1950 елларда, Б. Гыйззәт Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында әдәби бүлек мөдире булып эшли. Шул ук елларда ул СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантурада укый. 1951 елда диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала, 1953 елдан өлкән фәнни сотрудник итеп сайлана.

Б. Гыйззәт әдәби-фәнни эшчәнлеген берничә юнәлештә алып барды. Башта ул татар драматургиясенең күренекле вәкилләренең иҗатын өйрәнеп, алар турында монографияләр һәм аерым хезмәтләр (Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Гамир Насрый) язды. XX гасыр башындагы татар драматургларының рус телендә басылган җыентыгы аның сүз башы белән чыкты. Б. Гыйззәт драматургия һәм драматурглар турында газета-журналларда, әдәбият һәм театр энциклопедияләрендә дә күп санлы мәкаләләр бастырды. Үзенең шул күзәтүләрен гомумиләштереп, ул татар совет драматургиясе тарихын язып чыкты. Бу зур хезмәтнең бер өлеше 1960 елда Казанда басылган «Татар совет әдәбияты» китабына һәм 1966 елда Мәскәүдә рус

[1] Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр. 3 том. 360 бит.

телендә чыккан «История татарской советской литературы» исемле җыентыкка урнаштырылды.

Б. Гыйззәтнең соңгы елларда алып барган икенче юнәлештәге эшчәнлеге дә шактый нәтиҗәле булды. Ул Мәскәүдә Сәнгать тарихы институты чыгара торган «СССР халыклары театры тарихы» дигән алты томлык хезмәтне язу коллективына автор итеп чакырылды һәм шул хезмәтнең татар театры тарихына караган бүлеген эшләп бирде.

Б. Гыйззәтнең бу зур хезмәте һәм «Совет драма театрлары» китабының дөньяга чыккан дүрт томында урын алган башка очерклары «Театр» журналында (1967 елгы 11 саны) югары бәя алды.

Б. Гыйззәт М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институтында әзерләнә торган күп томлы «СССР халыклары әдәбияты тарихы»н төзү эшендә дә актив катнаша. Аның бу коллектив хезмәт өчен татар драматургиясе буенча язган очерклары да тәнкыйтьчеләрнең игътибарын җәлеп итте. Филология фәннәре докторы Ломидзе ул очеркларда авторның «үз вакытында драматургларны һәм тамашачыларны дулкынландырган төп проблемаларга дөрес анализ» ясавын билгеләп үтә.

Югарыда исемнәре саналган хезмәтләрне тудыру өчен, авторга күп еллар буе архивларда эшләргә, XX нче гасыр башыннан алып бүгенге көнгә кадәр чыккан газета-журналларны күздән кичерергә кирәк булды. Шулай ук 50 ел эчендә булып үткән әһәмиятле вакыйгалар һәм күренешләрне өйрәнергә, татар сәхнәсендә куелган спектакльләрне барларга, анда катнашучыларны белергә, аларның уеннарын күзалларга да ул күп көч куйды. Б. Гыйззәт һәр эшен намус белән үтәп килә. Аның шәхси архивында татар культурасы мәсьәләләренә бәйле бик күп материал тупланган. Галимнең бу эше аерым игътибарга лаеклы һәм ул бигрәк тә яшьләр өчен үрнәк булырлык.

Б. Гыйззәтнең бик яратып һәм бирелеп эшли торган тагын бер эше бар: ул инде күп еллар буена театр һәм драматургия буенча проблематик тәнкыйть мәкаләләре язып килә. Аның театр сәнгатенең торышы һәм үсеше турындагы ул мәкаләләрен укучылар яратып каршылыйлар.

Баян Гыйззәт — тыйнак табигатьле, туры сүзле, кыю фикерле, үзенә һәм башкаларга таләпчән галим.

Фән өлкәсендә зур эшләр алып бару белән бергә, Баян Гыйззәт җәмәгать эшендә дә актив катнаша. Республика «Белем» җәмгыятенең әдәбият-сәнгать бюросы председателе, Казан шәһәр Советы депутаты, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының сәнгать эшләре советы члены, Татарстан язучылар союзының тәнкыйть секциясе җитәкчесе буларак та ул актив эшләп килде.

Хәзер СССР Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты коллективы Баян Гыйззәткә тагын бер җаваплы эш тапшырды: аны яңа төзелгән сәнгать секторы мөдире итеп сайлап, татар театры һәм музыкасы тарихы буенча институтта эшләнә торган фәнни хезмәтләргә җитәкчелек итү бурычын йөкләде. Шул ук вакытта ул А. В. Луначарский исемендәге Дәүләт театры сәнгате институты докторантурасында да укый һәм «Татар драматургиясенең үсеше һәм аның сәхнәдә гәүдәләнеше» дигән темага зур хезмәтен тәмамлап килә, сәнгать фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗәне алырга әзерләнә. Без каләмдәшебезнең культурабыз үсеше өчен гаять кирәкле булган бу хезмәтен уңышлы тәмамлап чыгуына ихлас күңелдән ышанабыз. Тууына 50, әдәби-фәнни хезмәтләре башлануга 20 ел тулу уңае белән, аңа какшамас сәламәтлек, бәхетле, шатлыклы тормыш һәм иҗатында тагын да зуррак уңышлар телибез.

**М. ГАЙНУЛЛИН,**
филология фәннәре докторы,
профессор.

Әбрар Кәримуллин

# КАЗАН ТАТАР МАТБАГАЧЫЛЫГЫ ТАРИХЫННАН

## I. Казанда беренче татар типографиясе

Казанда беренче татар типографиясе кайчан ачылган? Бу сорауга төрле хезмәтләрдә төрлечәрәк җавап бирелеп килгән. Н. Ф. Катанов, Ш. Ахмеров, Г. Гобәйдуллин, П. Знаменский, К. В. Лаврский һәм П. А. Пономарев татар типографиясе 1802 елда ачылды, дип язганнар. Кайбер авторлар бу датаны 1801 ел белән билгелиләр, өченче берәүләр исә, Казанда беренче типография XIX йөзнең башында ачылды, дип якынчалап кына әйтеп үтәләр. Архив материалларыннан күренгәнчә, Казанда беренче татар типографиясе 1800 елда ачыла[1]. Типография ачу өчен рөхсәт 1800 елның 25 маенда Павел I нчедән алына һәм Сенатның 1800 ел 13 сентябрь указы белән бу рөхсәт законлаштырыла. 1800 елның көзендә типографиядән беренче басма текстлар чыга башлый.

Культурабыз тарихында гаять зур роль уйнаган татар китабы тарихының өйрәнелми килүе нәтиҗәсе буларак, бу өлкәгә караган күп кенә мәсьәләләрдә җитди төгәлсезлекләр һәм дөрес булмаган карашлар яшәп килә. XIX йөз ахырында татар китаплары буенча цензор булып эшләгән В. Смирнов: «Татарларга китап басу эшен Екатерина II нче заманының эшлекләләре көчләп такты диярга мөмкин», дип чыга[2]. Мондый ялгыш фикерләр соңгы еллардагы хезмәтләрдә дә очраштыргалый. Мәсәлән, Е. И. Рубинштейн: «Казанда беренче татар типографиясе хөкүмәт тарафыннан университет һәм гимназия өчен уку китаплары һәм кирәк санда Корьән басу өчен оештырылды»[3], дип, В. Смирновның ялгыш карашларын тагын да куәтли төшә.

Әлбәттә, патша хөкүмәте үз теләге белән татарларга типография ачып бирмәде. Киресенчә, татар халкының алдынгы карашлы вәкилләре басмаханә ачу өчен чирек гасыр буе Петербург юлын таптагач, бик күп үтенечләр язгач, аларның бу үтенечләрен куәтләп башка халык вәкилләре кушылгач кына, патша рөхсәт бирергә мәҗбүр булды. Дөресрәге, бу рөхсәт аннан тартып алынды. Алар «татар, төрек, фарсы һәм гарәп тел-

---

[1] ЦГА ТАССР. Ф. 977. Оп. ректор. д. 644. 5 кәг.

[2] В. Смирнов. Мусульманские печатные издания в России. Записки вост. отд. русск. археологич. об-ва. Т. III. 1889. 8 бит.

[3] Е. И. Рубинштейн. Книгопечатание в русской провинции первой половины XIX в. (400 лет русского книгопечатания. Т. I. М., 1964. 298 бит).

ләрендә дәреслекләр һәм халык мәгарифе өчен китаплар басу өчен» рөхсәт сорасалар да[1], халыкларны надалылыкта, карангылыкта тоту политикасын алга сөргән патша хөкүмәте типографиядә бары тик «Корьән һәм башка мөселман дине китаплары басуны» гына рөхсәт итте[2].

Типография өчен җиһазларны Петербургтан Казанга Г. Бурашев үз хисабына алып кайта һәм аны I Казан гимназиясенә тапшыра[3]. Сенат указы буенча, типография арендага бирелеп, арендатор типография эшчеләренә хезмәт хакы түләргә һәм басмаханә бинасын карау, җылыту, яктырту һ. б. расходларын күтәрергә тиеш була.

Архивларда Бурашевның китап басып чыгару буенча эшчәнлеген турыдан-туры чагылдырган материаллар сакланмаган. Университет ректоры Н. И. Лобачевскийның 1826 елгы отчетында[4] һәм университет тарихына караган кайбер хезмәтләрдә, Бурашевның 1801—1805 еллар эчендә 7 исемдә 17 басма китап чыгаруы күрсәтелә. 1801 елда басылып чыккан 2 китап типографиянең беренче басмалары була. Боларның беренчесе — Әттаһаҗи исеме белән мәктәп-мәдрәсәләр өчен чыгарылган татар әлифбасы, икенчесе — Һәфтияк[5]. Аерым әсәрләр, берничә мәртәбә басылып, түбәндәге тираж белән чыкканнар: Әлифба — 11 000 данә, Һәфтияк — 7 000, Пиргули — 1 200, Стуани[6] — 3 000, Сөбәтел гаҗизин — 3 000, Фәүзен нәҗат — 3 000 данә. Бу басмалар — Корьән һәм Һәфтияктән калганнары — мәктәп-мәдрәсә өчен чыгарылган ярым тарихи-легендар, ярым дини эчтәлекле уку китаплары[7].

1801 елда чыккан ике әсәрне басу өчен рөхсәт Павел I иченең үзеннән алынган. 1802 елдан башлап Казанда басыла торган татар китаплары өстеннән цензорлык эше Казан гимназиясе конторасына йөкләтелә. Татар китапларының рәсми цензоры булып Оренбург мөфтие, аның Казандагы вәкиле итеп «Казанның Иске бистә агач мәчете имамы» М. Абдразяков билгеләнә. Ләкин 1802 елда мөфти рөхсәте белән басыла торган «Фәүзен нәҗат» корректурасын тикшергәндә, корректор Мамышев ислам диненең сөнни сектасы турында кулъязмада булмаган өч бит артык текст очрата һәм бу турыда мөфтигә дә, гимназия башлыкларына да хәбәр итә. Татарча китап баса башлауны хуп күрмәгән патша чиновниклары һәм миссионерлар бу кечкенә фактны зур вакыйгага әйләндерәләр. Нәтиҗәдә Абдразяков цензорлыктан алына һәм Бурашевны эзәрлекләү башлана. Гимназия конторасы 1803 елның 21 июлендә Бурашев өстеннән шикаять язып, типографияне яптырырга кирәк, ул доход бирми дип, Сенатка мөрәҗәгать итә[8]. Эзәрлекләүләр башлангач, Бурашев, халык мәгарифе министрына китап басарга комачаулары турында хат язып, эш өчен нормаль шартлар тудыруларын үтенә. Бурашевның бу үтенече җавапсыз калдырыла.

Официаль рәвештә типографияне арендалаудан Бурашев 1803 елда ук читләштерелгән булса да, китаплар 1805 елга хәтле аның җитәкчелегендә чыгып килә[9].

---

[1] ЦГИАЛ. Ф. 1329. оп. 4. д. 296. 3 кәг.

[2] ЦГА ТАССР. Ф. 977. оп. ректор. д. 644. 8 кәг.

[3] Габделгазиз Туктамыш улы Бурашев, озак еллар буе патша армиясендә хезмәт итеп, прапорщик дәрәҗәсендә отставкага чыккан кеше. Үз хисабына хосуси татар типографиясе ачу өчен, ул 1796 елда ук патшага мөрәҗәгать итеп карый. Рөхсәт ала алмагач, Азиат филиалы типографиясендә мәктәп-мәдрәсәләр өчен китап бастырыр өчен, Сенатка да керә. Әмма бу типография эшсез торуга карамастан, анда татар китапларын басудан баш тарталар. Казанда ачылган беренче татар типографиясен оештыруда ул — иң актив катнашучы, типографиянең беренче арендаторы. Татар китабы тарихында ул иң беренче типограф та, нәшир дә.

[4] Казан университеты. Фәнни китапханә. Кулъязмалар бүлеге. Рус секторы. Кульязма № 7661. 5 кәг.

[5] Бу әсәр соңыннан «Әлифба иман шартлары белән», «Шәрнатель иман», «Иман шарты» исемнәре белән басыла. Шиһап Мәрҗани бу әсәрнең Болгар чорында ук мәктәп-мәдрәсәләрдә уку китабы булып йөртелүен күрсәтә.

[6] Бу әсәрләр «Пиргули васыяте», «Пиргули китабы», шулай ук «Стуани китабы» исеме белән дә йөртелгәннәр.

[7] XVI—XVII йөзнең беренче яртысында рус мәктәпләре өчен бердәнбер уку китаплары булып «Часословец», «Псалтырь» кебек дини эчтәлекле әсәрләр хезмәт иткән. (400 лет русского книгопечатания. — В кн.: Исследования и материалы. Сб. IX. М., 1964. 7 б.). Бездә дә Һәфтияк, башка уку китаплары белән бергәттән, кадими мәктәпләрдә шушы бурычны өлешчә үтәгән.

[8] ЦГА ТАССР. ф. 977. д. 1023. 28 кәг.

[9] ЦГА ТАССР. ф. 977. д. 675. 24—26 кәг.

1805 елны, Бурашев киткәч, типографияне договор белән сәүдәгәр Юныс Апанаевка тапшыралар. Типография 1806 елдан алып 1809 елга кадәр аның арендасында кала.

Архив материаллары арасында типографияне арендалаган өчен Апанаевның күпме акча кертүе турында документлар булса да, нинди китаплар бастыруы хакында тулы мәгълүматлар юк. Карл Фукс фикеренчә, 1806 елда Апанаев 19 500 данә Әлифба, 3 000 — һәфтияк, 1 000 — Пиргули, 1 200 — Ступни, 1 200 — Сөбәтел гаҗизин, 1 500 данә Корьән бастырып чыгарган[1]. Бу саннар шактый күпертелгән булса кирәк. Әгәр типографиядә бер генә хәреф җыючы эшләвен, Апанаевның китап басу эшенә 1806 елның март аенда гына керешүен искә алганда[2], 10 ай чамасы вакыт эчендә шул хәтле китап басып чыгаруы бик шикле. Ул вакытта типографиядә басыла торган һәр китапның берәр данәсе Фәннәр академиясенә җибәрелеп барылган. Андагы документлар буенча 1806 елда Апанаевның бары дүрт китап: Әлифба, Сөбәтел гаҗизин, Пиргули, Ступни әсәрләрен генә басуы күренә[3]. Бу факт Б. Дорн библиографиясендә теркәлгән китап исемнәре белән дә раслана[4]. Б. Дорн 1806—1809 елларда Апанаев баскан түбәндәге әсәрләрне теркәгән: Әлифба — 3 басма, Пиргули — 5, Ступни — 3, Сөбәтел гаҗизин — 4, һәфтияк — 4, Корьән — 2, Сәйфел Мөлек — 2, Мөхәммәдия — 2 басма. Димәк, Апанаев дүрт ел эчендә барысы 26 китап бастырып чыгарган.

Бурашев чыгарган китаплар белән чагыштырганда, бу басмалар арасында ике яңа әсәр күренә. Беренчесе — Сәйфел Мөлек кыйссасы — татар телендә басылган беренче матур әдәбият әсәре. Бу китап Мисыр шаһы Сәйфел Мөлекнең Көнчыгыш илләренә сәяхәте турындагы маҗаралы тасвирлардан гыйбарәт. Икенчесе — Мөхәммәдия — Көнчыгышта киң таралган ярым тарихи, ярым дини әсәр. (Соңыннан бу әсәрне А. Казембек та берничә мәртәбә бастырып чыгара.)

Татар китаплары басу эшендә туктаусыз киртәләргә, договор шартларының гаять авырлыгына түзә алмыйча, Апанаев 1809 елны типографияне арендалаудан баш тартырга мәҗбүр була. Дүрт елга якын арендалап торган өчен, ул 5 879 сум 59 тиен акча түли. (Сенат указы буенча, типографияне арендалаган өчен арендатор елына 500 сум гына түләргә тиеш була.)

Апанаев арендалаудан баш тарткач, китап басу бик күп кими. 1810—1829 еллар арасында елына уртача 1—4 китап басылып килә, ә 1811, 1813, 1815, 1824, 1828, 1829 елларда бер генә басма әсәр дә чыкмый.

1810 елдан соң, аренда хакы артык югары булу сәбәпле, типографияне арендага алырга теләүчеләр табылмый. Шушы елдан башлап типографияне материаль яктан кайгырту гимназия өстенә кала. Яңа шрифтлар булдырылмагач, типография татар заказларын бик сирәк үти. Китап бастыру өчен татар нәширләре үзләре хәреф койдырып китерергә тиеш булалар. Мәсәлән, 3000 данә Әлифба бастырыр өчен, Апанаев Мәскәүдән үз хисабына гарәп хәрефләре койдырып алып кайтырга мәҗбүр була[5]. Шуның өстенә типографиядә татар китаплары басу бәяләре бермә-бер күтәрелә. 1814 елда күләме 37 табаклы бер китапны 3000 данә бастыру өчен 5203 сум акча түләнгән. Ә бу сумма исә типографиянең үз бәясеннән 2,5 мәртәбә артыграк[6] була.

Казан уку округы попечителе итеп Магницкий билгеләнгәч, бу реакционер татар китаплары басу бәясен тагын да күтәрә. Халык мәгарифе министрына язган хатында ул: «Татар нәширләренең заказларын бастыруны тагын да авырайту өчен, татар китабы басуның бәясен тагын да күтәрүне файдалы таптым», дип мактана[7].

1809 елга караган мондый мәгълүматлар сакланган: рус нәширләренең заказларын табагын 17 сумга, миссионерлар заказы буенча гарәп хәрефе белән басыла торган

---

[1] К. Фукс. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Казань. 1844. 120 б.

[2] ЦГА ТАССР. ф. 977. д. 675. 40 кәг.

[3] ЦГА ТАССР. ф. 977. д. 296. 9 кәг.

[4] B. Dorn. Chronologisches Verzeichniss der seit dem Jahre 1801 bis 1866 in Kazan gedruckten arabischen, türkischen, tatarischen und persischen Werke... — Mélanges asiatiques... Academie Imperiale des sciene de St.—Pétersbourg, t. V, 1868, pp. 539—540.

[5] ЦГА ТАССР. ф. 92. д. 491. 18 кәг.

[6] ЦГА ТАССР. ф. 92. д. 1023. 35 кәг. Типографиянең бөтен барлыгы бу елларда 2 000 сум да тормаган. Ул азмы-күпме яңартылгач та, 1829 елда да, барлыгы 2 115 сум 05 тиенгә бәяләнгән. (Кара: ЦГА ТАССР. ф. 977. д. 675. 140—145 кәг.)

[7] ЦГА ТАССР. ф. 92. оп. 1. д. 1429. 3 кәг.

христиан катехизисларын һәм догалыкларны 25 сумга бассалар[1], татар нәширләренә бер табак басу өчен 65 сум акча түләргә кирәк булган[2]. Патша самодержавиесе, аның реакцион чиновниклары, татар китабы басуның бәясен күтәреп, халкыбызның мәгърифәте үсешен буарга тырышты. Бу «халыклар термәсе» булган патша Россиясендә милли изүнең культура өлкәсендәге чагылышы иде.

Башка типография булмагач, татар нәширләре теләсә теләмәсәләр дә, бу авыр шартларга түзәргә мәҗбүр булганнар. Шунысы кызык: шартлар ифрат авыр булса да, татар нәширләренең заказлары кимемәгән, киресенчә, шрифтлар җитешмәү сәбәпле, типография аларның күбесен кабул итә алмаган.

Гимназия типографиясендә махсус заказлар белән дә татарча китаплар басыла. 1803 елда «Сыгырларда үлнән чәчәкләре шул әдәмиләрдәге табигъ чәчәкнең йогышчылы агырлыкларини дәфгъ әйләмәк өчен мәгә ябышдырып сакча халәс улмакайның имкяннәре» исемле медицина буенча татар телендә беренче басма китап чыга. Бу әсәр халыкта киң таралган булган, күрәсең, 1812 елда ул китап янадан басылып чыга. 1813 елда медицина буенча тагын бер яңа әсәр басылуы билгеле. Аның рус телендәге исеме «Описание летучей мази» дип аталган[3]. 1820 елда «Тәгълим намә» дип йөртелгән китап чыга. Бу әсәрдә мәртәә киткән кешеләрне терелтәй күмүдән саклану өчен киңәшләр бирелә. Бу әсәрләрнең өчесен дә русчадан Ибраһим Хәлфин тәрҗемә иткән.

1808—1809 елларда университет галимнәре редакциясендә башка әсәрләр дә басыла. 1808 елда Х. Френ редакциясендә «Рисаләи Әхмәдия», «Китап сафа бәгъзе әд-дәраһим» исемле китаплар, гарәп шагыйрьләреннән — Аш-Шанфар һәм Әл-Туграйларның шигъри үрнәкләре — әнә шундыйлардан[4]. Басма китаплардан тыш, Сенатның төрле указлары, белдерүләре татар телендә басылып халыкка таратыла. Мәсәлән, 1813 елда французларны җиңү уңае белән татарча Манифест басыла.

Бу типографиядә чыккан китапларның тулы репертуарын эченә алган бер генә библиография дә юк. Югарыда искә алынып үткән Б. Дорн библиографиясендә 1801—1829 еллар арасында чыккан 56 басма, ә А. Соловьев һәм Н. Катанов библиографиясендә 20 ләп басма гына искә алынган[5]. Без бу елларда гимназия каршындагы типографиядә басылган 93 басманы ачыкладык[6]. Байтак басмаларның тиражы да ачыкланды. Ачыкланган 50 басманың тиражы 151.000 данә тәшкил итә. Һәр басма уртача 3 000 данә белән басылуын (151.000:50 = 3020) искә алсак, бу 93 басма — 280.000 чамасы тираж белән чыккан дип карый алабыз[7].

Татар нәширләренең барлык ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмаса да, типография шул чор өчен чагыштырмача күп китап чыгарды. Бу басмаларның халык мәгарифе өчен әһәмияте зур булды. Типографиянең прогрессив эшчәнлеге — күренекле рус галимнәре тарафыннан күптән танылган факт. Академиклар Б. Дорн, Х. Френ, И. Крачковский, профессорлар А. Казембек, И. Булич, К. Фукс һ. б. аның эшчәнлегенә бик югары бәя бирделәр. «Казан татарлары һәм Россиянең Европа өлешендә яшәүче башка вак милләтләрнең мәгарифе күтәрелү турындагы-туры Казандагы беренче Азиат типографиясе эшчәнлегеннән башлана», дип язып чыкты профессор Н. Ф. Катанов. Бу басмаханәнең эшчәнлегенә совет тарихчылары да зур бәя бирәләр. «Казанда берен-

---

[1] ЦГА ТАССР, ф. 977, д. 2944, 80 кәг.

[2] ЦГА ТАССР, ф. 977, д. 492, 4 кәг.

[3] Бу басманың татарча нөсхәсен таба алмадык, исемен шуңа күрә рус телендә генә китерергә мәҗбүрбез.

[4] И. Ю. Крачковский. Первое издание арабских стихотворений в России. — Библиография Востока, вып. 8/9. 1935/1936. 5—8 бб.

[5] А. Соловьев и Н. Катанов. Каталог книг, отпечатанных в типографии имп. Казанского университета с 1800 по 1896 год. Казань, 1896. 1—7; 325—329 битләр.

[6] Бу санның әле барлык басмаларны эченә алып бетермәве мөмкин.

[7] Гимназия каршында ачылган беренче татар типографиясе 1800 елда оештырылып, 1829 елга хәтле эшләде, аннан университет типографиясенә кушылды. 1829 елда төзелгән бер отчетта (ЦГА ТАССР, ф. 977, д. 5743, 25 кәг.) анда барлыгы 137.255 данә китап басылды дип күрсәтелә. Бу саннар без китергәннәрдән шактый түбән. Сәбәбе — гимназия типографиясендә университет һәм башка оешмалар өчен басылган китаплар бу санга кертелмәгәннәр. Бу отчеттан алынган саннар, типография архивы белән чагыштырылмыйча, дөрес дип кабул ителеп, матбугатта да кулланыла башладылар. (Кара: С. З. Закиров. Издания на восточных языках в Казани в первой половине XIX века. — Народы Азии и Африки. 1961. № 6. 109 б. — Е. И. Рубинштейн, күрсәтелгән хезмәт, 299 б.).

че татар типографиясенең басмалары Идел буе, Урал, Себер татарлары арасында халыкны агартуда зур роль уйнады», ди С. З. Закиров [1]. 1800 елда Казанда ачылган басмаханә төрки халыклар арасында, төрекләрдән кала, гарәп хәрефләре белән китап баскан беренче типография булды. Бу басмаханәнең тарихта тоткан роле югарыда күрсәтелгән моментлар белән генә чикләнми. Хәтта анда бер генә дөньяви китап басылмаган булса да, Казанда ачылган беренче басмаханә буларак, ул татар тарихында прогрессив күренеш булып саналырга хаклы булыр иде [2].

Күреп үткәнебезчә, типография дини әсәрләр басу белән генә чикләнмичә, беренче көненнән үк халыкка файдалы китаплар да чыгара башлады, бик күп борынгы кулъязмаларны югалудан саклап калды, киләчәктә Казанда китап басуның киң җәелеп китүенә нигез булды.

Бу басмаханә әдәбиятта, архив документларында «татар», «шәрык», «азиат», «гимназия» типографиясе дип, төрлечә атап йөртелә. Шуның нәтиҗәсе буларак, бу басмаханәнең эшчәнлеген XIX йөздә Казанда эшләп килгән башка типографияләр белән бутау очраклары шактый күп. Бу басмаханәнең ачылуы, эшчәнлеге татарларга турыдан-туры бәйле. Шунлыктан аны без татар типографиясе дип атау дөрес булыр дип саныйбыз. Шуның өстенә ул Казанда ачылган беренче басмаханә дә булды.

Типографиянең эшчәнлеге турында сөйләгәндә, анда эшләгән осталар турында да бер-ике сүз әйтеп үтү урынлы булыр. Безгә Петр I иченең поход типографиясендә һәм Фәннәр академиясендә эшләгән татар китап осталарының исемнәре билгеле түгел. Шулай ук И. Шнор типографиясендә эшләгән татар осталарының да исемнәрен белеп бетермибез әле. Беренче татар типографиясе оештырылгач, үзләре теләп Петербургтан Казанга кайткан Г. Рәхмәтуллин һәм Х. Мамышев фамилияле кешеләр — безгә мәгълүм татар китап осталарының беренчеләреннән.

Гали Рәхмәтуллин 1759 елда туган. 1780 елда солдатка алынып, шактый озак еллар матрос булып хезмәт итә, шведлар белән булган диңгез сугышында зур батырлыклар күрсәтә, берничә медаль белән бүләкләнә. 1791 елны Екатерина II иченең 25 декабрь указы буенча флоттан алынып, И. Шнор типографиясенә татар наборщигы итеп билгеләнә. Шул вакыттан башлап 1834 елга хәтле Петербургта һәм Казанда гарәп хәрефләре белән чыккан китапларның күпчелеге менә шушы оста тарафыннан җыелганнар. Г. Рәхмәтуллин Казан университеты типографиясендә үсеп чыккан рус наборщикларының укытучысы да булган. Архив материаллары аның үз эшен тирән белүче, тырыш, яхшы оста булуы турында сөйлиләр. Г. Рәхмәтуллин 74 яшенә кадәр типографиядә эшли. Эштән киткәндә, аның класс чины булмавын сәбәп итеп, пенсия билгеләмиләр.

Безгә мәгълүм китап басу осталарының икенчесе — Хәмзә Мамышев. Ул 1768—1770 еллар тирәсендә туган. (1831 елны язган бер гаризасында үзенә 60 яшь чамасы икәнлеген искәрткән.) Х. Мамышев 1789 елны Кронштадтта рядовой булып хезмәт итә башлый. Ул да, Г. Рәхмәтуллин кебек үк, шведларга каршы сугышта катнаша, батырлыгы өчен көмеш медаль белән бүләкләнә. 1791 елны Екатерина II иченең 17 ноябрь указы белән шул ук И. Шнор типографиясенә хәреф җыючы итеп җибәрелә. 1800 елда Казанда типография ачылгач, Сенат указы буенча ул Казанга килә һәм елына 360 сум эш хакы белән корректор итеп билгеләнә. 1816 елдан 1829 елга кадәр типографиянең факторы вазифасын башкара һәм, типографиядәге шөгыле белән беррәттән, 1805—1811 елларда татар теле укытучысы булып та эшли. Пенсиягә чыгар алдыннан Мамышев Титулярный Советник дәрәҗәсенә күтәрелә.

Типографиянең бөтен эшчәнлеге менә шушы ике кешенең хезмәтенә, тырышлыгына бәйле булган. Алар типографиянең наборщигы һәм машинисты да, китап басучысы һәм төпләүчесе дә, механигы һәм кара эшчесе дә, корректоры һәм техник редакторы да. Бу осталарның хезмәте киләчәктә татар китабы тарихында тиешле югары бәя алыр, аларның эшчәнлеге аерым өйрәнелер дип ышанасы килә.

XIX йөз башы татар китабы тарихында Казан университетының татар теле адъюнкты Ибраһим Хәлфиненең дә роле шактый зур. Ул, бу чорда чыккан күп кенә

---

[1] С. З. Закиров, күрсәтелгән хезмәт, 110 б.

[2] Моның өчен шуны искә төшерү җитә: 1564 елда Мәскәүдә оештырылган китап басу эше рус культурасы тарихында гаять зур һәм дөрес бәя алды. Анда йөз елга якын бер генә дөньяви китап та басылмады.

татар китапларының, барлык тәрҗемә әсәрләрнең авторы булу белән беррәттән, рус галимнәренең шәрык телләрендә басылган күп хезмәтләренең фәнни редакторы да. Ул типографиянең эшенә турыдан-туры катнашып килгән, аның шрифтларын яхшырту буенча да күп булышкан. Цензор буларак, барлык татар китаплары аның кулыннан үткән, күбесен редактор, галим буларак та эшкәртеп чыккан. И. Хәлфин татар типографиясе университетка күчкән елны үлә. Шул ук елны аның улы, Шаһиәхмәт Хәлфин, гаиләләренең матди хәле авыраю сәбәпле, гимназиядә укуын ташлап, типографиягә наборщик итеп алуны сорап университет идарәсенә гариза бирә. Әмма аны эшкә алмыйлар, Уфа губернасына хәрби хезмәткә китәргә тәкъдим итәләр[1]. XVII йөз урталарыннан хөкүмәткә зур хезмәт күрсәтеп килгән, рус, шәрык фәненә олы өлеш керткән, татар культурасында тирән эз калдырган Хәлфиннәр династиясенең бу өлкәдәге эшчәнлеге менә шушында өзелә.

## II. Университет типографиясенең татар басмалары

Яңа ачылган университетның баштагы елларда матди хәле бик начар булса да, тора-бара эшләр җайга салына башлый. Дәрәҗәле уку йортында эшләүче галимнәрнең фәнни хезмәтләрен, уку китапларын һәм эш документларын бастырып чыгару өчен, гимназиядән кушылган татар типографиясеннән тыш, махсус типография ачуга ихтыяҗ туа. Андый типография рәсми рәвештә 1809 елның 20 гыйнварында ачыла һәм бу уңай белән бер битле «Объявление» дә басыла[2]. Бу игъланда университет хисабына уку китаплары басылачагы, татар типографиясендәге кебек үк, шәхси заказлар да кабул ителәчәге белдерелә, китап бастырырга теләгән кешеләрнең университет типографиясенә мөрәҗәгать итәргә тиешлекләре әйтелә. 1809 елда университет типографиясенең беренче китабы басылып чыга. Ул — И. Хәлфиннең «Шаһиншаһның Казан гимназиясендә лисан төрки вә хатт гарәби үгрәтелә торган әлифба илә кечекчә нәху вә сарыфыдыр» дигән әсәре. 170 биттән торган бу китап 1 200 данә белән рус мәктәпләрендә татар теле өйрәнү өчен дәреслек буларак чыгарыла. Шул ук типографиядә 1812 елда ул яңадан басыла. 1819 елда И. Хәлфиннең «Әхвәли Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» исемле зур хезмәте дөнья күрә. Хәлфиннең яна хезмәтенә Х. Френ шәкерте Я. О. Ярцев зур бәя бирә: «Бу хезмәт — тарихи язмаларны чыгару белән дә, аларны укуны җиңеләйтү белән дә төрки вә татар телен өйрәнүчеләр өчен гаять кирәкле хезмәт. Аның сүзлек өлешендә, инде гамәлдән төшеп калган, яңа төрки әсәрләрдә очрамый торган борынгы сүзләр һәм тәкъбирләрнең дөрес һәм тулы аңлатылуы белән дә хезмәт әһәмиятле... Шуның өстенә бу хезмәт үзенең яңалыгы белән дә [университет — Э. К.] Советның игътибарына һәм югары бәясенә лаеклы»[3].

1824 елда университет типографиясендә Мәскәүнең духовный академиясе заказы буенча А. Троянскийның «Краткая татарская грамматика» дигән әсәре икенче басма булып чыга[4].

---

[1] ЦГА ТАССР. ф. 977. д. 2041. 1—6 каг.

[2] Бу «Объявление»нең тулы тексты Н. П. Загоскинның «История имп. Казанского университета». т. 2. Казань. 1903 елда чыккан китабында китерелә. 667 б.

[3] ЦГА ТАССР ф. 92. д. 824. 32 каг. Хәлфиннең бу хезмәте, татар текстологиясендә беренче хезмәт буларак, фәнни әһәмиятен хәзерге көндә дә югалтмаган.

[4] Троянскийның бу грамматикасының беренче басмасы 1814 елда Петербург Фәннәр академиясе типографиясендә басыла.

1815—1850 елларда Фәннәр академиясе типографиясендә гарәп хәрефләре белән китап басу бөтенләй диярлек туктала. 1820 елда «Шәҗәрәи төрки» исемле борынгы төрки әсәрне бастырыр өчен, Фәннәр академиясе үзе Казан университеты типографиясенә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Бу әсәр, хәрефләр җитешмәү сәбәпле, 5 ел буе басыла. Граф Румянцев кушуы белән басылган бу әсәр Х. Френ редакциясендә, И. Хәлфин комментарийлары белән чыга.

Шәрык әсәрләрне оригиналда чыгаруда профессор Ф. Эрдманның да хезмәте зур. Аның комментарийлары белән 1822 елда Тәхаветдин Мөхетдиннең «Әл-мөлек вә әл-хәнәфә вә вилаяти Мәккәи әш-шәриф» әсәре, 1826—1832 елларда әзербәйҗан классигы Низаминың өч китабы басылып чыга.

Университет типографиясе зур масштаблы типография итеп оештырылса да, беренче ике дистә елда күп китап баса алмый. Ул 1815 елга хәтле университет хисабына яшәп килә. Үз хисабына яшәргә калгач, өч ел эчендә 9 783 сум расходка керә[1].

Университет типографиясенең авыр хәле 1830 елларга хәтле сузыла. Типография оештырылудан алып бу елга хәтле анда барлыгы 188 китап, журнал, журнал оттисклары басыла[2]. Университетның ректоры итеп Н. И. Лобачевский куелгач, типографиянең материаль базасы ныгый төшә. 1829 елда университет типографиясен һәм гимназия типографиясен берләштерәләр. Типография начальнигы әмере белән гимназия типографиясеннән килгән гарәп шрифтларын эретеп рус хәрефләре коялар. Һәм шулай итеп, 1829—1830 елларда гарәп хәрефләре университетта бөтенләй диярлек бетә. Типография материаль яктан яхшы ук баетылса да, гарәп хәрефләре булмау сәбәпле, шәхси заказлар кабул итә алмый һәм бер тиен дә доход китерми. 1831 елда ашыгыч рәвештә гарәп хәрефләре кайтарыла. Ниһаять, шушы елдан башлап университет типографиясе җиң сызганып татар нәширләренең заказларын басарга керешә, күп тә үтми, типография үз чыгымнарын каплый һәм шактый гына табыш та ала башлый. Татар китаплары басудан килгән доходка типографиягә яңа станнар кайтартыла, тибет, монгол, санскрит, әрмән һәм башка телләрдә шрифтлар булдырыла. 1831 елдан башлап университет типографиясенең эшчәнлеге бермә-бер үсә. Ел саен 20—40 шар яңа басма чыгып тора. Шунысы кызык, типография бик күп китап чыгара башласа да, аның штаты артмый диярлек. 1819 елда анда 16 кеше эшләгән булса, 1840—1850 елларда да аның штаты 17—20 кешедән торган[3].

Типографиядә гарәп хәрефләре яңадан булдырылгач, университет галимнәренең бу шрифт белән язылган хезмәтләре һәм алар редакциясендәге төрки әсәрләр дә күбрәк басыла башлый. 1832 елда профессор А. Казембек редакциясендә Сәед Мөхәммәд Ризаның «Китаб әс-сәбаигъ әс-сәйяр или семь планет, содержащий историю Крымских ханов от Мингли-Гирей хана I-го до Мингли-Гирей хана II-го, т. е. с $\frac{871}{1466}$ по $\frac{1150}{1737}$ года» дигән әсәре басыла. Әзербәйҗан классигы Низаминың фарсы телендә «Хикәят дохтәр падша рус» исемле әсәре чыга. Типографиягә беренче зур доход китергән Юнысов заказы да шул елны үтәлә. Ул 10 000 данә Әлифба, 3 300 данә Һәфтияк, 6 600 данә Коръән бастыра.

1832—1850 елларда гарәп хәрефләре белән чыккан басма китаплар арасында татар тарихына һәм тел белемена караган хезмәтләр дә шактый гына. 1839 елда А. Казембекның «Грамматика турецко-татарского языка»сы, ә аның киңәйтелгән басмасы 1846 елда, «Общая грамматика турецко-татарского языка» исемендә басыла. Университет профессоры, тюрколог И. Березин «Библиотека восточных историков» сериясеннән төркигә караган тарихи кулъязмалар бастырып чыгара. («Шейбаниада. История монголо-тюрков». 1849; «Сборник ханских ярлыков». 1850; «Тарханные ярлыки Тохтамыша, Тимур Кутлуга и Саадет Гирея». 1850)[4].

Рус уку йортлары өчен чыгарылган хезмәтләр арасында А. Троянскийның «Словарь татарского языка» (Т. 1. 1833, Т. 2 1835), М. Ивановның «Татарская хрестоматия» (1842), «Татарская грамматика»ларын күрсәтеп була. Казан гимназиясенең татар

---

[1] Н. П. Загоскин. История имп. Казанского университета. Т. 2. Казань. 1903. 342 б. Типографиянең зур расход китерүе штатның зур булуыннан да килә. Оештырылу елларында ук аның штаты 15 кешедән торган. Аларга елына 10 000 сум диярлек хезмәт хакы түләнеп килгән, ә басылган китапларның саны берничәдән артмаган.

[2] Н. П. Загоскин, А. Соловьев материалларына таянып, бу елларда 178 басма чыгуын күрсәтә. (Кара: Н. П. Загоскин. История имп. Казанского университета. Т. 4. Казань. 1906. 48 б.)

[3] Университет типографиясендә татар осталары да эшләп килгән. Мәсәлән, 1819 елда 16 кешенең 2 се татар була, 1844 елда 17 кешенең 7 се — татар остасы: Габделкәрим Уралиев (корректор), Дәүләтша Яушев (хәреф җыючы), Муса Мөсәгыйтов (печатник), Галиәкбәр Халитов (батырщик), Халит Монасыйпов (хәреф җыючы), Ибнней Ючеев (хәреф коючы), Әхмәт Мөхәммәтов (печатник).

[4] Университет галимнәре редакциясендә чыккан төрки, гарәби, фарси әсәрләрдә китапның исеме күп очракта рус телендә күрсәтелә. Шуңа күрә андый әсәрләр исеме татар теленә тәрҗемә ителмичә бирелде. Әгәр китап исеме гарәп хәрефләре белән дә күрсәтелсә, алар әсәрнең оригиналы телендә китерелделәр.

теле укытучысы Первухин 30.000 татар сүзен эченә алган сүзлек хәзерләгән була, ләкин ул нигәдер басылмый кала[1].

1830—1850 еллар эчендә бу типографиядә университет һәм бүтән оешмалар өчен гарәп шрифтында 29 китап басылуы ачыкланды. Шуның өстенә татар нәширләренең заказы белән 165 китап басыла. Татар нәширләре заказы белән басылган китаплар арасында мәктәп-мәдрәсә өчен басылган дәреслекләр төп урынны тота. Әлифба 33 тапкыр, Стуани — 5, Сөбәтел гаҗизин — 4, Сәйфел Мөлек — 4, Пиргули — 2, Фәүзен наҗәт — 4 тапкыр чыккан.

1839 елда XII—XIII йөз татар әдәбияты әсәре «Киссаи Йосыф» аерым китап булып басылып чыга һәм шуннан соң ел саен диярлек, кайбер елларны хәтта берничә басма булып чыгарылып килена. 1841 елда татарча беренче басма календарь дөньяга чыга. Аның авторы — тәрҗемәче Рәхмәтулла Әмирханов була. Болардан тыш, татар һәм Көнчыгыш әдәбияты әсәрләреннән «Киссаи Таһир» (1847)[2], «Ләтаиф Хуҗа Насретдин» (1845), «Кисекбаш кыйссасы» (1846), «Ахырзаман китабы» (1847); Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә»се (1850), Ибраһим Хаккиның «Мәгърифәт намә»се (1845), XII йөз суфи шагыйре Бакырганиның «Хәким ата»сы (1846) һәм «Бәдәвам»ы (1846), Болгар чоры әсәрләреннән «Мәликә китабы» (1846), «Киссаи Сөләйман» (1848) һәм халык тарафыннан әлек яратылып укыла торган башка бик күп әсәрләр басыла.

Мөселман юриспруденциясе буенча «Шәрх фикгы Кәбир» (1849), «Шәрх фикгы Әкбәр» (1848), «Шәрх фикгы Кайдани» (1848) кебек әсәрләр чыгарыла. XIX йөзнең I яртысында дөньяви, борынгы әдәбият һ. б. башка шундый әсәрләр генә басылды дисәк, дөреслектән ерак булыр идек. Халык аңын агулаган Коръән кебек дини китаплар да шактый басылып килгән.

1830—1850 елларда, безнең исәбебезчә, университет типографиясендә 536 китап, журнал һәм оттисклар басылган. Шуларның 194 е гарәп хәрефләре белән чыккан басмалар булып, югарыда күренгәнчә, аларның 165 е татар нәширләренең заказлары белән басылган. Калган китаплар — дәреслекләр, төрле документлар һәм университет галимнәренең үз хезмәтләре. Рус телендә чыккан 30 лап китап төрле оешмалар заказы белән акча түләп басылган. Ә университет чыгарган китаплар һәм журналлар шәхси заказлардан килгән доход хисабына бушка чыгарылганнар. Әгәр татар нәширләренең заказларын басу өчен бәянең гадәттәгедән ике-өч мәртәбә югары торуын һәм бу елларда акча түләп басылган 200 ләп китапның 165 е татар китаплары булуын искә алсак, университет типографиясенең төп доходы татар китаплары басудан килгәнлеге күренә. Шул доходы хисабына төрле җиһазлар алына, университет өчен чыгарылган барлык китаплар бушка басыла, шуның өстенә типография ел саен үзенә берничә мең сум доход ала килә[3].

1829 елда гимназия типографиясен үзенә кушкач, университет типографиясе Казанда татар китабы басу буенча бердәнбер типография булып калды. Казанда хосуси типографияләр барлыкка килгәнче, барлык татар китаплары шушы типографиядә басылдылар. Бу типографиядә бик күп китап басу осталары тәрбияләнде. XIX йөзнең беренче яртысында гарәп шрифтлары белән китап басу буенча университет типографиясе Россиядә иң эшлекле басмаханә булды. Бирелә башка шәрык халыклары — монгол, тибет, әрмән һ. б. халык телләрендә дә бик күп китаплар басылып чыкты.

## III. Казанда беренче хосуси типографияләр

Университет типографиясе генә татар нәширләренең көннән-көн үсә барган ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмады. Бу хәл Казанда татар китабы басу өчен яңа типографияләр оештыруга этәрде. Урындагы патша чиновникларының: «Казанда беркемгә дә татар китабы басар өчен хосуси типография ачарга рөхсәт бирмәскә», дип, әледән-әле Петербургка язып торуларына[4] карамастан, патша хөкүмәте мәдәниятка

[1] Первухинның бу кулъязмасы әлегә хәтле табылганы юк. Ул сүзлек турында әдәбиятта без берниндн белешмә очратмадык.
[2] Җәя эчендә әсәрнең беренче мәртәбә басылу елы күрсәтелә.
[3] Отчет имп. Казанского университета и Учебного округа за 17 лет... Казань. 1844. 238 б.
[4] ЦГА ТАССР. ф. 977. д. 1023. 25 кәг.

сусаган бөтен бер халыкның теләгенә каршы килә алмый, Казанда шәхси типографияләр ачарга рөхсәт бирергә мәҗбүр була.

Казанда беренче хосуси типография 1841 елда ачыла. Лейдинскта туган Шевиц дигән чит ил кешесе аны татар халкы арасында мәгърифәт тарату өчен оештырмый, әлбәттә. Ул, Казанда художник һәм гравер булып шактый озак яшәгән кеше буларак, китап басуның торышын, аның доходлы эш булуын яхшы белгән. Ул татар китапларына сорауның зур булуын, ә университет типографиясенең заказларны кабул итеп өлгерә алмавын күреп, татар китабы басу өчен типография ачкан һәм зур керем алырга исәп тоткан. 1841—1845 елның уртасына хәтле Шевиц типографиясендә 30 татар китабы басыла. 1845 елны патша әмере белән Казандагы шәхси типографияләрдә татар китабы басу тыелгач, Шевиц хуҗалыгында да татар китаплары басу күп кими. Татар китабын басу тыелгач, банкротлыкка чыгудан куркып, Шевиц типографиясен сата һәм үз иленә кайтып китә. Шевиц типографиясен 1849 елны купец Н. Л. Коковин сатып ала[1] һәм ул Коковин типографиясе дип йөртелә башлый.

1841—1850 еллар эчендә бу типографиядә татар нәширләренең заказы белән барлыгы 57 китап басыла. Алар арасында «Киссаи Иосыф», «Киссаи Сөләйман», «Лэтаиф Хуҗа Насретдин», «Киссаи Сәйфел Мөлек» кебек әсәрләр һәм мәктәп-мәдрәсәләр өчен чыгарылган «Сөбәтел гаҗизин», «Фәузен наҗәт», «Рисаләи мөһиммә», «Гыйбрәт намә» кебек дидактик китаплар бар.

Казанда ачылган икенче хосуси типографиянең, дөресрәге литографиянең[2], хуҗасы татар кешесе була. Яхин литографиясе[3] исеме белән билгеле бу басмаханәнең беренче басмасы 1844 елда чыга. 1845 елны хосуси типографияләрдә татарча китап басу тыелу сәбәпле, Яхин литографиясендә татар китаплары күп басыла алмады. 60 елларда бу ташбасмаханә Шаһи Яхинның улы Мөхәммәдвәли Яхинга күчә, 70 елларда Әбдрәшитов литографиясе булып йөри, 1893 елдан Касыйм Абдуллин ташбасмаханәсе хисапланып, 1908 елда китап басудан бөтенләй туктый[4]. Бу литографиянең татар китабы тарихында тоткан роле әллә ни зур булмады. Шулай да аның Россиядәге төрки халыклар арасында оештырылган беренче ташбасмаханә булуы тарихи әһәмияткә ия.

XIX гасырның икенче яртысында Казанда ачылган өченче хосуси типография Рәхимҗан Сәгыйтов басмаханәсе булды[5]. Сәгыйтов типографияне Яңа бистәдәге үз йортында оештыра һәм 1844 елда китап басу эшенә керешә. Татар китаплары басуны тыю турында патшаның әлеге әмере аркасында бу типографиядә күп китап чыга алмады. 1844 елдан 1850 елга кадәр вакыт эчендә нибары 27 китап кына басылган. Алар арасында «Киссаи Таһир», «Киссаи Иосыф» (4 басма), «Бакыргани», «Рисаләи мөһиммә», «Сөбәтел гаҗизин» һ. б. әсәрләр бар. Сәгыйтов типографиясенең эшчәнлеге турында 1925 елда Казанда чыккан «Материалы по истории Татарстана» (Вып. II) дигән хезмәттә азмы-күпме белешмә китерелгән. Анда: «Бу типография бары 1844—1847 елларда гына китап басу белән шөгыльләнгән», — диелә. (104 бит.) Архив материалларыннан күренгәнчә, Сәгыйтов типографиясе 1850 еллардан соң да эшләгән әле. Бу типографиядә 1862 елда чыккан китап та табылды. 1851 елдан алып 1862 елга кадәр Сәгыйтов типографиясендә тагын 53 китап басылганлыгы ачыкланды. Типография тотудан туктагач, Сәгыйтов, нәшир буларак, университет типографиясендә үз хисабына татар китаплары бастыруны дәвам иткән.

Зур дәрт белән ачылган татар типографияләре патша хөкүмәте тарафыннан махсус тыюлар, эзәрлекләүләр нәтиҗәсендә әкренләп юкка чыгалар. Яңадан хосуси татар типографиясе Казанда XIX йөзнең ахырында гына ачыла.

1841—1850 елларда Казанның хосуси типографияләрендә барысы 88 татар китабы чыккан. Аларның тиражлары төрлесенеке төрлечә: кайсы 3 300 данә, кайсы 4 600, кай-

---

[1] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 1, д. 674, 5 кәг. Типографиянең 9 000 сум көмешкә сатылуын искә алсак, ул заманы өчен бай басмаханә булган. Чагыштырыгыз: университет типографиясе иң бай вакытында, 1842—1844 елларда, 18 000 сум бәяләнгән.

[2] Бу ысул белән китап басу XVIII гасырның ахырында Европада барлыкка килә. Россиядә ташбасма ысул белән китап басу 1816 елда башлана.

[3] Бу типографияне «Шагин», «Шогин», «Яхин» литографиясе дип тә йөрткәннәр.

[4] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 3768, 4 кәг.

[5] Бу типография «Ракимзянов», «Рахимзянов», «Саитов», «Саидов» типографиясе дип тә йөртелгән.

сы аннан да күбрәк. Кайбер китапларның тиражы бөтенләй күрсәтелмәгән. Шул ук уи ел эчендә университет типографиясендә 119 татар китабы басылган. Димәк, бу елларда барлык типографияләр чыгарган татарча китапларның саны — 207. Һәр басма уртача 3 000 әр данә белән басылганда да, татар китапларының гомуми тиражы 600 000 данәдән дә узган дип әйтә алабыз.

Әгәр 1829 елга хәтле бу эш белән, башлыча, сәүдәгәр Апанаевлар гаиләсе, өлешчә, Сәедборһанов һәм Юнысовлар шөгыльләнсәләр, хәзер инде аларга яңа сәүдәгәрләр — Сәгыйтовлар, Хәсән Исхак улы Карташев, Миңлебай Әбдрәшит улы Ахматов, Гобәйдулла Габделсаттаров, Абдулсалих Назир улы Медведевлар кушыла. Нәширләк эшенә Мортаза Катенин, Мортаза Максутов, Ибраһим Медведев, Мортаза Давыдов, Исхак Уразов, Мөхәммәдъяр Козлов, Шәриф Фаризов һ. б. мещаннар да керешә. Баймурат Вахитов, Баймурат Мусин, Г. Ваһапов кебек шәкерт-студентлар да китап басуда катнаша башлый. Китапчылык эшендә хәтта крестьяннар да читтә калмаган. Китап басуда актив катнашкан Казан өязе Бөрке авылы крестьяны Шакирҗан, Лаеш өязе Алан авылы крестьяны Шәмсетдин Мөхәммәдъяр улы — әнә шундыйлардан. Китап басучылар арасында хатын-кызлар да булган. Аларның беренчесе — Гайниҗамал Гобәева.

Татар китабын басуга бу хәтле киң һәм төрле катлау кешеләренең керешүен халыкның китапка, белемгә зур омтылышы һәм мәдәниятка сусаган булуы белән генә аңлатырга мөмкин. Әлбәттә, китап басу һәм сату китапчыларга табыш та китергән. Күп нәширләр китап басуда беренче чиратта файда алуны күз алдында тоткан. Әмма алар арасында халыкка хезмәт итү, мәгърифәт тарату өчен фидакарьләрча эшләгәннәре дә күп булган. Ул чорда актив нәширләрдән Р. Әмирханов, Г. Ваһапов, Г. Мәхмудовларның китап басудагы эшчәнлекләре шуны раслый.

Татар китабын басу шактый кыйммәт торган. 1840 ел башларыннан Казанда шәхси типографияләр ачыла башлагач, казенный басмаханәнең монополиясе җимерелә, китап басу бәясе шактый арзаная, китапларның сату бәяләре дә күпкә төшә. Б. Дорнның әйтүе буенча, 1860 елларда Әлифба 2 тиенгә, Һәфтияк 15 тиенгә, Сөбәтел гаҗизин 25 тиенгә[1] сатыла башлый. Китап бәясен арзанайту, китапның үзкыйммәтен киметү бәрабәренә, татар нәширләре китапларның начар кагазьдә, юка тыш белән чыгуына риза булганнар. Шуңа күрә дә китапларны бизәүгә игътибар аз булган, барлык басмалар бертөрле шрифтлар, бертөрле трафарет бизәкләр белән чыккан.

1830 елга хәтле татар нәширләренең заказлары белән чыгарылган китаплар үзләренең титул битләре булмавы белән аерылып торалар. Бу басмаларда әсәрнең исеме китапның ахырында күрсәтелә, шунда ук аның кем тарафыннан, кайчан, кайда басылуы да әйтелә. Татар китабының бу полиграфик үзенчәлеге кульязма китап традициясеннән килә. Басмалардагы бу үзенчәлекләр теге яки бу татар китабының кайсы типографиядә һәм кайсы чорда басылганын ачыкларга ярдәм итте.

## Татар китабы һәм патша цензурасы

Халык теләгенә каршы тора алмагач, Казанда типография ачарга мәҗбүр булган патша хөкүмәте татар китабына каршы төрле ясалма киртәләр куеп килде. Алда күреп үткәнчә, Казанда басылган беренче китапларның цензоры Павел I нче үзе булды. Соңрак Сенатның махсус указы белән Казанда басыла торган китапларның цензурасы гимназия конторасына йөкләтелә. Гимназия белән килешү нәтиҗәсендә татар китабының цензоры итеп мөфти куела. Соңрак мөфтидән тыш дөньяви цензор итеп И. Хәлфин билгеләнә. 1803 елдан башлап татар китабы шушы ике цензор рөхсәте белән генә басыла башлый. Кульязма башта Уфага, мөфтигә җибәрелгән, аннан әйләнеп кайткач,

[1] Б. Дорн. Күрсәтелгән хезмәт. 596 б.

ул яңадан Хәлфин тарафыннан каралган һәм соңгы рөхсәтне ул биргән. Архив материалларыннан күренгәнчә, мөфти кайбер әсәрләрне басарга рөхсәт бирми. Мәсәлән, 1803 елда аңа җибәрелгән 6 кульязманың 4 сен ул бөтенләй кире кайтармый, ни өчен басарга рөхсәт бирмәве турында да хәбәр итми[1]. И. Хәлфин дә мөфти рөхсәт иткән барлык кульязмаларны үткәрми. Мәсәлән, мөфти басарга лаеклы дип тапкан «Рисаләи Мөхәммәдия», И. Хәлфиннең рөхсәт бирмәве аркасында, ике ел буе басылмый ята. Бу ике цензор арасында каршылыклар шактый еш булып торган. «Татар китаплары цензурасын мөфтидән алырга, Казан университеты каршында оештырылган цензура комитетына тапшырырга кирәк», дигән тәкъдим белән И. Хәлфин университет советына да мөрәҗәгать итеп карый[2].

1812 елда университет каршында цензура комитеты оештырылгач, татар кульязмалары бу комитет аша да үтәргә тиеш була. Шуның өстенә китап басу өчен Казан уку округы попечителенең дә рөхсәте кирәк булган. Ә 1840 елларда татар китабын басу өчен Казан хәрби губернаторыннан, хәтта эчке эшләр министрыннан рөхсәт визасы таләп ителгән[3].

XIX гасырда Казан рус булмаган халыкларны христианлаштыруның идеологик һәм практик үзәге булды. Казанда шәхси типографияләр барлыкка килеп, аларда татар китаплары басыла башлагач, «бу эш христианлаштыруга зыян китерә» дип, миссионерлар Св. Синодка жалоба яздылар һәм һәр уңай моментта, Казанда татар китапларын тыюны сорый башладылар. Св. Синод бу жалоба буенча патшага мөрәҗәгать итә. Патша «Казанда Корьән һәм башка мөселман дине китапларын басуны тыярга» дигән боерык чыгара. Аның бу боерыгы эчке эшләр министры тарафыннан 1845 елның 3 август хаты белән Казан хәрби губернаторына җиткерелә[4].

Патша әмерендә Корьән һәм башка мөселман дине әсәрләрен басу тыела диелгән. Әгәр әмер шулай гамәлгә ашырылган булса, татар китабы зыян күрмәс иде, бәлки аның репертуары яхшырыр гына иде. Ләкин эштә бу боерык киресенчә үтәлгән. Дини китаплар басу тыелуга карамастан, университет типографиясе аларны күпләп басуын дәвам иттергән. Чөнки алар зур табыш китергәннәр. Бу турыда югары даирәләр белгәннәр һәм аңа бармак аша гына караганнар. Аның каравы, Казан губернаторы шәхси типографияләрдә һәртөрле татар китаплары басуны, шул исәптән дөньяви китаплар басуны да тыйган. Шулай итеп бу әмер ике яктан да бозып тормышка ашырылган: тыелган дини әсәрләр казенный типографиядә басылып килгән, ә хосуси типографияләрдә тыелмаган дөньяви китаплар басу рөхсәт ителмәгән.

Татар китаплары басуны тыю татар нәширләре һәм типографлары арасында гына түгел, университетның алдынгы карашлы галимнәре арасында да ризасызлык тудырган. Татар китабын яклап чыгучылар арасында бөек рус математигы Н. И. Лобачевский да бар. Н. И. Лобачевскийның карашы университет исеменнән Петербургка җибәрелгән язуда ачык чагылган. «...Типографиядә Корьән һәм башка дини әсәрләр генә түгел, татар һәм төрек телләрендә *ә д ә б и* (курсив безнеке — Ә. К.) әсәрләр дә өзлексез басылып киленде. Алар белән без Европа ориенталистларын да тәэмин итеп торабыз. Шуның өстенә Корьән һәм башка азиат китаплары басу университет типографиясенә өзлексез доход китереп торды, бу доходтан башка типография, гомумән, яши дә алмаган булыр иде»[5].

Шушы хат нигезендә эчке эшләр министры Св. Синодка мөрәҗәгать иткәч, соңгысы, Казан миссионерларына хат язып, аларның фикерен сораган. Яңа куелган архиепископ Св. Синодка җавабында бу мәсьәләгә үз карашын белдереп болай язган: «Корьән бары тик гарәп телендә генә басыла. Аны татарлар аңламыйлар. Ә инде кирә-

---

[1] Архив материалларында бу кульязмаларның нинди әсәрләр булулары күрсәтелмәгән.

[2] ЦГА ТАССР. ф. 977. д. 146. 6 кәг.

[3] Рус телендә чыккан әсәрләр өчен XIX йөзнең беренче яртысында Казанда аерым цензор бөтенләй булмый. Университет үзе баскан китаплар 1812 елга хәтле попечитель рөхсәте белән генә чыгарылганнар. 1812—1828 елларда алар өчен цензура комитеты эшләп килә. 1829 елдан соң университет үзе чыгара торган китаплар бернинди цензурасыз басыла.

[4] ЦГА ТАССР. ф. 1. оп. 2. д. 483. 97 кәг.

[5] ЦГА ТАССР. ф. 977. оп. ректор. 644. 8—9 кәг.

шен татарларының икенче буыны татар язуын бөтенләй танымауларын искә алсак, аларның магометанлыкка кире кайтуларын Корьән басуга сылтау, гомумән, дөрес булмас... Корьән, башка дини китаплар, *әдәби эчтәлекле әсәрләрне* (курсив безнеке — Ә. К.) шәрык телләрендә басуны тыю, алар белән сәүдә итүне инглиз компанияләре кулына калдырачак. Ә бу үз чиратында Россиядә ул төр китаплар белән сәүдә итүдә контрабандага юл ачачак. Шуның өстенә, Россиядә Корьән һәм башка шәрык китаплары бастыру, бүтән илләрнең мөселман халкы арасында Россиядә дин иреге яши дигән ышаныч тудырачак, ә моның файдасы аз түгел»[1].

Татар китабы басуның патша хөкүмәте алып барган христианлаштыру политикасына зыяны булмагач, киресенчә, бу эшкә һәм экономик, һәм политик капитал бирүе расләнгач, 1849 елда татар китаплары басуны тыю турындагы әлеге боерык кире алына. Татар китапларын басарга рөхсәт янадан бирелү белән бергә, бу эштә үтүе бик кыен булган яңа кирталәр дә корыла. Казандагы цензор үзе шикле тапкан кульъязмаларны Петербургка, цензураның баш идарәсенә җибәреп торырга тиеш була[2]. Халык мәгарифе министры кульъязмаларны цензура өчен Св. Синодка җибәрүне дә шарт итеп куйган[3]. 1850 елларда татар китабы чыгаруның никадәр авыр, никадәр мәшәкатьле икәнен белү өчен, бер генә мисал китерү дә җитә. Шәрык китаплары цензоры профессор А. Казембек үзенең «Общая грамматика турецко-татарского языка» дигән хезмәтен бастырыр өчен Халык мәгарифе министрыннан һәм Петербург цензоры Корсаковтан рөхсәт алырга тиеш була. Инде цензорның үз китабы шундый кирталәр аша узгач, гади татар нәшире китабы нинди иләкләр аша үткәнлеге яхшы аңлашыла. 60 елларда татар китабын эзәрлекләү тагын да көчәйгән. 1873 елда татар китаплары буенча цензура бөтенләй Петербургка күчерелгәч, Казанда татар китаплары чыгару эше гаять катлауланган. Цензураның читтә булуы яңа кыенлыклар, яңа авырлыклар тудырган.

* * *

Казан типографияләрендә 1801—1855 еллар эчендә 577 татар китабы басылган[4]. Бу чорда Россиянең барлык провинциаль типографияләрендә (Мәскәү һәм Петербург типографияләреннән тыш) барлыгы 1463 китап басылган[5]. Димәк, бу басмаларның өчтән бер өлешеннән артыгын татар китаплары тәшкил иткән. Бу — заманы өчен аз түгел. Шуны искә алып үтәргә кирәк, XIX йөзнең беренче яртысында Россиянең бүтән бер генә төрки халкында да китап басу булмаганлыктан[6], татар китаплары шәрыкның төрки халыклары арасында да киң таралды.

Татар басма китабының чагыштырмача иртә барлыкка килүе, төрле кирталәргә карамастан тиз үсүе, халкыбызның язма, басма сүзгә, әдәбиятка көчле мәхәббәте турында сөйли. Халыкның китапка ихтыяҗы шул кадәр зур булган ки, аларны Казан типографияләрендә чыккан китаплар гына канәгатьләндерә алмаган. Шул сәбәпле шәрык илләреннән ел саен меңләгән китаплар кайтартылып торылган.

Казанда татар матбагачылыгы барлыкка килү культурабыз тарихында якты бер күренеш булды. Аның прогрессив ролен рус галимнәре дә күрсәтеп үткәннәр. Хәтта

---

1 ЦГА ТАССР. ф. 1. оп. 2. д. 483. 45—46 каг.

2 ЦГА ТАССР. ф. 1. оп. 2. д. 483. 46 каг.

3 Шунда ук, 1—2 каг.

4 Бу санның Казанда басылган барлык татар китапларын эченә алып бетермәве мөмкин.

5 400 ЛЕТ русского книгопечатания. Т. I. М., 1964. 291 б. XIX йөзнең беренче яртысында татар китаплары Петербург типографияләрендә дә, өлешчә, Мәскәү, Оренбург типографияләрендә дә басылып килгәннәр. Шуның өстенә Шуша, Каррас һәм Астрахань типографияләрендә дә татар телендә китаплар чыккан. Без аларны бирергә искә алмадык. XIX йөзнең беренче яртысында Казаннан читтә чыккан татар китапларын тикшерү аерым хезмәт сорый.

6 Татарлардан кала, Россиянең төрки халыклары арасыннан китап басу эшенә керешүчеләр әзербайҗаннар булды.

миссионер, Казанның духовный академия ректоры П. Знаменский да Казанда типография ачылгач, «татарлар арасында грамоталык бик тиз үсә, басма китаплар алар арасында күп санда тарала башлады», дип язып чыкты [1].

Татар матбагачылыгының уңай роле турында уртак карашлар арасында тик Ә. И. Харисовның карашы гына диссонанс булып яңгырый. Аныңча, Казан типографияләрендә күбесенчә дини китаплар гына басылган, дөньяви китаплар бик сирәк чыккан. Ул үзенең карашын дәлилләп: «А. Соловьевның «Каталог книг» дигән китабында Казанда 100 ел эчендә чыккан китапларның исемлеге Корьәннән башлануы шуны күрсәтә дә инде», дип язып чыга [2]. Без бу очракта Ә. Харисов белән бәхәсләшеп торуны кирәк тапмыйбыз. Чөнки 1803 елда ук, Корьән басылудан элегрәк, Әлифба, Фәүзен нәҗат, Пиргули, Сөбәтел гаҗизин кебек уку китаплары, медицина буенча татар телендә әсәрләр басылганын алдарак әйтеп үткән идек инде. Дөрес, бу чорда Корьән һәм башка дини әсәрләр дә шактый күп басылган. Ләкин татар китабының XIX гасырдагы репертуарын дини китапларга гына кайтарып калдыру тарихи дөреслектән читләшү булыр иде.

Казанда чыккан беренче басмаларны объектив бәяләргә кирәк. Рус әдәбият белгечләре XVII йөз патриархларының тезмә вәгазьләрен, төрле дини китапларның шигырь белән язылган өлешләрен «рус матур әдәбиятына нигез салган әдәби әсәрләр» дип саныйлар [3]. Ә ни өчен без мәктәп-мәдрәсәләр өчен шигырьләр белән басылган әсәрләрне художество әдәбиятыннан читләштерергә тиеш соң? Ф. Бурцевның 1634 елда чыккан «Азбука»сы рус китабы тарихында беренче ярым дөньяви басма санала [4]. Бурцев «Азбука»сы да, «Шәриатель иман» — «Иман шарты әлифба белән» — «Иман шарты» — дип йөртелә торган татар Әлифбасы да икесе дә алфавит белән башлана, икесендә дә хәрефләрнең исемнәре, укылышы күрсәтелә, икесендә дә саннарның язылышы бирелә. Соңыннан һәр икесендә уку өчен текстлар — догалар китерелгән. Бу ике басма бер-берсенә тәңгәл диярлек. Әгәр рус китап белгечләре Бурцев «Азбука»сын рус китабы тарихында беренче ярым дөньяви басма дип саныйлар икән (без бу фикер белән тулысынча килешәбез), без дә бу Әлифбаны татар китабы тарихындагы беренче шундый басма дип атарга тиешбез. Азбуканың һәм Әлифбаның әһәмияте догаларда түгел, аларның хәреф танырга, укырга, язарга өйрәтүендә. Гомумән, XIX йөзнең беренче яртысында чыккан китапларны бәяләгәндә, ул эпоханың тарихи шартларын — культура һәм фәнен ни дәрәҗәдә торуын, нинди социаль шартлар хөкем сөрүен исәпкә алмыйча, хәзерге көн дәрәҗәсеннән генә чыгып хөкем йөртү ялгыш булыр.

XIX йөзнең беренче яртысында татар китабы үсеше, нигездә, түбәндәге дүрт юнәлештә барды:

1. Мәгърифәтчелек юнәлеше — уку йортлары өчен киң күләмдә дәреслекләр, татар теле грамматикалары һәм сүзлекләре чыгару, медицина буенча фәнни-популяр әсәрләр һәм официаль законнар бастыру.

2. Фәнни юнәлеш — борынгы төрки-татар тарихи кулъязмаларын шәрехләп бастыру, шәрык әдәбияты җәүһәрләрен чыгару.

3. Әдәби юнәлеш — массовый тираж белән матур әдәбият һәм халык иҗаты әсәрләрен бастыру.

4. Дини юнәлеш — исламның кануни әсәрләрен чыгару.

Татар китабы тарихының үткән юлы зур һәм катлаулы. Кызганычка каршы, ул соңгы елларга хәтле өйрәнелми киленде. Басма сүз тарихын җентекләп өйрәнми торып, культурабыз тарихын тулы, дөрес бәяләү мөмкин түгел. Татар китабы тарихын өйрәнү тел, әдәбият, сәнгатебез тарихын өйрәнүгә дә зур ярдәм итәчәк. Бу эшкә киң планда керешер алдыннан, бу өлкәдә башка халыклардан артка калмас өчен, барлык басмаларны эченә алган татар китаплары исемлеген әзерләп чыгару заруридыр.

---

[1] П. Знаменский. Казанские татары. Казань. 1910. 28 б.

[2] А. И. Харисов. Литературное наследие башкирского народа XVIII—XIX вв. Автореферат... Алма-Ата — Уфа, 1966. 58 б. А. Соловьев каталогында, Харисов әйткәнчә, Казан типографияләрендә 100 ел эчендә чыккан китаплар түгел, ә Казан университеты һәм гимназия типографиясендә 1896 елга хәтле басылган китаплар гына теркәлгән. Анда хосуси типографияләр чыгарган басмалар, шул исәптән татар китаплары кертелмәгән.

[3] 400 лет русского книгопечатания. Т. 1, М., 1964. 61 б.

[4] Е. И. Кацпржак. История книги. М., 1964. 215 б.

**Гариф Галиев**

# МИНЕМ МӘЛИКӘМ

хикәя



Мин үзем авыл кешесе. Килеш-килбәтем, тормышым турында күп сөйләп тормыйм, йорт-жир дә житү, азык-төлек ягыннан да зарланырлык түгел, өс-башыбыз да бөтен, тәнебез дә сәламәт, шуннан үзегез аңларсыз дип уйлыйм. Тик менә елдан-ел олыгая барабыз. Үзем дә, хатыным Мәликә дә жиденче дистәгә кердек инде. Һәм без икебез дә рәсми яктан караганда колхоз эшенә йөрүдән азат ителгән кешеләр булып саналабыз. Шуңа карамастан, жан түзми, гел эшлисе килә. Хатыным да, гомер буе дигәндәй терлекчелек фермасында эшләгәнгәдер инде, иртән тору белән шул якка карый. Мин үзем элеккерәк елларда урман кисү, салам өю кебек авыр эшләрдә йөри идем. Хәзер колхозның столярлык мастерскоенда агач юнам. Акча өчен түгел, тик торасым килми, гомеремне бушка үткәрә алмыйм. Аягың-кулың хәрәкәт иткән чакта ничек инде кул кушырып тик тормак кирәк.

Шулай көн артыннан көн үтә, хатын да, мин дә һаман колхоз эшенә йөрибез. Ашарга-эчәргә тәмле азык, тәнең сәламәт булгач, эштән дә рәхәт нәрсә юк. Ләкин тора-бара мин хатынымның эшкә йөрүе белән ничектер бик үк риза булмый башладым. Без инде ир кеше, мин әйтәм, ул хатын кеше, олыгайган көнендә өйдә иркенләп ял итсен, дим. Шул ният белән өнди торгач, мин бу мәсьәләдә аны үземнең якка аудардым, ягъни хатыным минем фикеремә күнде, фермага эшкә йөрүдән туктады. Тик озак та үтмәде, аның сәер гадәтләре күренә башлады.

Бу хәл кинәт булмады. Мин аның ничек башланганлыгын беркадәр вакыт белмичә йөрдем. Соңга таба гына искәрә торган булдым. Минем хатыным йомыш белән барган жиреннән, нишләптер, тиз генә әйләнеп кайтмый торган булды. Элек ул алай түгел иде. Әйтик, сөт аертырга дип сепаратор пунктына китә иде дә эше бетү белән кайта иде. Соңгы вакытларда исә ул анда озак кала башлады. Беркөнне мин аннан:

— Нишләп бик озак тордың?— дип сорадым.

— Мин барганда сепараторны кормаганнар иде, корганнарын көттем,— дип жавап бирде ул.

Берничә көн үткәч, болай озак тору тагы кабатланды. Мин тагы аннан сорарга мәжбүр булдым:

— Ни булды соң сиңа, әнисе, китәсең дә югаласың, китәсең дә югаласың — дидем.

Ул тагы җавап тапты:

— Суык сөтне машина аера алмый бит, мин сепараторга барып житкәнче сөтем суынып беткән иде, анда баргач казанга салып җылытырга туры килде,— ди.

Икенче көнне дә сепаратор пунктында шактый озак торып кайтты бу. Гадәтенчә, мин тагын кызыксындым:

— Син көтү чыкканда киткән идең, хәзер көтү кайтыр вакыт җитә, ә син юк та юк. Әллә соң анда тоз суы сипкәннәрме?

Ул салкын кан белән генә җавап кайтарды:

— Чират зур иде. Бер килгәч, аертып китим инде дип, көттем. Кичкә калдырсам, сөтем әчи.

Хатынымның фикере дөрес иде. Чыннан да, сөтне савып алу белән үк машинадан чыгару яхшы. Юкса әчеп әрәм була ул.

Беркөнне сепаратор пунктында хатыным аеруча озак торды. Бу юлы инде өйгә кайтып керү белән үк, мин авыз ачканчы, ул үзе әйтте:

— Сепараторның көе киткән. Ике борыныннан да сөт ага... Рәтли алмыйча җаннары чыкты,— диде.

Мин тынычландым. Ләкин башыма бер уй килде: нигә, мин әйтәм, безнең үзебезгә бәләкәй сепаратор алмаска! Көн саен пунктка барып кайту өчен хатынымның никадәр вакыты үтә. Үзебезнеке булса, сөтне теләгән вакытында аера ала ич ул, дим. Хатынымны кызганып та куйдым, олыгайган көнендә әллә нинди мәшәкатьләргә дучар булып йөрүдән котылсын, мин әйтәм.

Яхшы теләккә кем каршы төшсен, ул да минем фикеремә кушылды. Һәм беркөнне район үзәгендәге олы магазинга бардым да казанына ярты чиләк кенә сөт сыешлы бәләкәй сепаратор сатып алып кайттым. Аны күршемдәге тракторчы белән корып та куйдык.

Шул көннән алып өй алдыбызда иртә-кич тә сепараторыбыз җырлап утыра торган булды. Мин дә аның моңлы тавышына кушылып, әллә кайчан алырга кирәк булган икән, бик әйбәт булды бит бу, дип, эчемнән генә җырлап ала торган булдым. Хатыным сепаратор пунктына йөрүдән котылды. Мәгәр минем бу куанычым озакка бармады, хатыным күлмәк тегү белән мавыга башлады. Мин монда атна-ун көн саен яңа күлмәк тегү турында сүз алып бармыйм. Бер күлмәкне тегүнең бер айга сузылуы турында сөйләргә телим. Әйе, бер күлмәкне бер ай тегү турында!

Шулай, карлар эреп, матур язлар килде. Тышта гөрләвекләр ага, сыерчыклар сайрый, тавыклар җырлый, атлар кешни, кыскасы, барлык җан иясенең кузгалган көннәре иде. Бөтенесе бергә кушылган бу тавышлар күңелләрне иечкәртә, үткән гомерләрне искә төшерә иде. Нәкъ менә шундый ямансу көннәрнең берсендә кибеткә товар кайтты. Товар бушатылу белән кибеткә йөгерү без авыл кешеләренең гадәте инде ул. Мин дә шунда таба атладым.

Анда озак тормадым, хатыныма алсу бөрчек төшерелгән ак штапель күлмәклек алдым да аны тизрәк сөендерү өчен ашыга-ашыга кайтып киттем. Ул алган әйберемне бик ошатты:

— Шушындый җиңел ак күлмәкне күптән киясем килеп йөри идем, бик зур рәхмәт, әтисе,— диде.

Ул аның иңен-буен тикшереп карады, аннары яңадан шатланды:

— Әтисе, бик мул итеп алгансың икән. моннан бер алъяпкыч та чыга әле, рәхмәт яугыры, бүген үк кисәм дә иртәгә Фәрдәнәләргә барып тегә башлыйм,— диде.

Кисүен бик тиз кисте, әмма тегүе озакка сузылды. Арттырып әйтү булмасын, айга якын тартылгандыр аның бу күлмәкне тегүе! Ул ашарга-эчәргә хәзерләп, өйне җыештыргалагандай итә дә көн саен Фәрдәнәләргә китә. Беркөнне, бүген җиңен тектем, дип, икенче көнне итәкләрен типчедем, дип, өченче көнне, изүләрен каедым, дип, дүртенче

көнне, бил туры кысынкырак тегелгән, шуны сүтеп киңрәк итеп яңадан тектем, дип кайта бу.

Мин беркатлы кеше, хатын-кыз күлмәген тегү, күрәсең, шулай бик чигерекледер инде ул, дип, эчемнән генә уйлап йөри бирәм.

Ниһаять, ул мине беркөнне юатты:

— Хәзер җиңнәрен генә утыртасы калды инде, әтисе, алъяпкычын тегү озак түгел аның,— диде ишектән чыкканда.

Ләкин борчуга төшеп кайтып керде:

— Сыңар җиңем югалган, эзли-эзли башым катты, аптырагач, өйгә кайтып азрак ял итеп килим, дидем. Фәрдәнәләрнең бөтен өйләрен актардым, юк, таба алмадым,— диде һәм лып итеп өстәл янына килеп утырды.

— Кая китсен ул, синең җиңеңнең кемгә кирәге бар, әйбер арасына кереп уралгандыр, иртәгә табылыр әле,— дидем мин.

Иртәгәсен бик иртә Фәрдәнәләргә китте һәм бу юлы тиз кайтты.

— Таптым, әтисе, Фәрдәнәләрнең көзгеләре артына кыстырып куйганмын икән, сиңа әйтер өчен генә кайттым,— диде дә яңадан чыгып китте.

Мин үз-үзем белән сөйләшеп калдым, бу мин әйтәм соңгы күлмәге булмасын, тагы да яңа күлмәкләр кияргә язсын, дим. Мәгәр болай кешегә йөреп интекмәсен иде, әллә соң үзебезгә тегү машинасы алыргамы, дим. Акчабыз бар, бер дә көч килерлек түгел бит, мин әйтәм.

Минем бу фикерем көннән-көн ныгый барды һәм... Тукта, башта шуны әйтеп үтим, безнең элек-электән үк тегү машинабыз бар иде. Без ул машинабызны, төпчек кызыбыз кияүгә чыккач, аңа бүләк иттек. Безгә, ике бөртек кешегә, тегү машинасының соңгы елларда әллә ни кирәге дә сизелмәде. Ә инде сирәк-мирәк кенә күлмәк-фәлән тегәргә туры килгәндә хатыным үзе белән фермада эшләгән ахирәт дусты, югары очтагы Фәрдәнәләргә барып тегеп кайта торган булды. Тик мин хатынымның бер күлмәкне бер ай тегеп, интегеп йөрүе белән эчемнән риза булмый башладым һәм, бик үк зарур нәрсә булмаса да, тегү машинасы сатып алуны кирәк таптым. Алган әйбер алган урынында кала, бар нәрсәнең зыяны тимәс, дидем. Болай уйлавымны хатыным да муафикъ күрде:

— Һаман саен кешегә йөргәнче бик әйбәт булыр, әтисе. Ямау ямаган чаклар да була. Кул белән чемченеп утыруга караганда машина белән теккәләп чыгу бөтенләй башка. Келтер-келтер итеп ике-өч тапкыр әйләндердең — эше бетте,— диде шатлана-шатлана.

Барып та җиттем, бәреп тә ектым, дигәндәй, район үзәгендәге универмагка барып та кердем, кул машинасы алып кайттым да киттем.

Шулай итеп, сирәк-сирәк кенә булса да өебездә келтер-келтер тегү машинасы әйләнә торган булды. Мин, инде сепараторыбыз да, тегү машинабыз да булды, хатынымны кешегә йөрүдән коткардым лабаса, хәзер инде өйдә генә торыр, дип, тагы шатландым, тагы тынычлангандай булдым. Тик иртәрәк шатланганмын икән шул!..

Менә язлар үтеп, җәй айлары керде, һәм хатын-кызның, бала чаганың карлыганга йөри торган вакыты җитте. Ә карлыган безнең Куышлы елга буенда котырып уңа, аны җыярга гына өлгер, һәм минем Мәликәм дә башкалар кебек карлыганга барам дип көн саен иртүк чыга да китә, чыга да китә. Мин кайчан гына эштән кайтып кермим, ул өйдә булмый. Вакыт-вакыт ачуым да килә. Дөрес, бер көнне дә чиләген тутырмыйча кайтмый кайтуын. Шулай булса да аның болай өй ташлап йөрүе минем эчемне пошыра башлады. Үзен кызганып та куям: кичләрен әрәмәлектән кайтып кергәндә җиңнәре ертылган, беләкләре сыдырылган, чәчләре бүселгән, аяклары юешләнгән була.

— Ни өчен шулчаклы комсызланасың, синең белән миңа күпме генә карлыган кирәк, көн туса, башың әрәмәдән кайтмый, болай йөрсәң, куак төбендә чүгәләгән килеш дөньядан китәрсең әле,— дим аңа.

Ул миңа каршы әйтмәсә дә үзенекен итә:

— Син ачуланма әле, әтисе, безгә аны берәү дә җыеп китермәс. Көч барында җыеп калырга кирәк. Вареньесын да кайнатам, кагын да коям,— ди.

Җимеш өлгергән вакытта карлыганга, шомыртка, ә көз көне баланга йөрүне мин һич кенә дә яманламыйм. Юк, кая ул аны кирәкмәс эш итеп карау, киресенчә, җимешкә йөрүгә бик уңай караштә мин. Тик минә көн аралаш диярлек иртәдән кичкә кадәр әрәмәлектә йөрү белән генә килешә алмыйм. Аннары син эштән арып кайтканда хатының өйдә булмый икән, аннан да күңелсезрәк хәл юк. Ничек кенә димә, олыгайгач, үз өеңдә тынычлап ял итәсе, иркенләп ашыйсы-эчәсе килә дигәндәй, нинди дер җылылыкка мохтаҗ буласың. Ә инде син үзеңә күрә, ягъни кулыңнан килгән кадәр көч салып берәр эш башкарып кайтканда казан астында ут янмаса, самавырың шаулап утырмаса, өең салкын булса, моннан да ямьсез, моннан да шыксыз нәрсә юк.

Хатыным карлыганга йөри башлагач (дөресен әйткәндә, ул элек тә йөри иде, ләкин бу кадәр дөньясын онытмый иде) туган минә шундый күңелсезлек мине тагы исәпкә калдырды. Мин элек алай түгел идем, ә хәзер шулай хатыным Мәликәне юксынам. Ул булмаса, өйнең яме китә.

Хәзер инде мин аны карлыганга йөрүдән туктату турында уйлый башладым. Бу мәсьәләдә ничек хәрәкәт итәргә, нинди чара кулланырга соң?

Шулай исәпкә калып йөри торгач, сугыш вакытында үзебезнең илебезнең Украина кебек ерак почмакларында, шулай ук чит илләрдә йөргән чакларым исемә төште. Анда бит бер генә табан җирне дә буш яткырмыйлар. Ә безнең ишек алдыбыз никадәр киң. Нигә безгә шуның бер өлешен бакча итеп, аңа карлыган утыртмаска.

Һәм мин башыма килгән бу уемны эшкә ашырдым: шул көзне елга буендагы әрәмәлектән җитмеш төп карлыган куагы алып кайтып, бакчага утырттым.

Хатыным бу эшемә дә кул куйды:

— Рәхмәт, әтисе, әллә кайларга барып карлыган җыеп йөргәнче, үзебезнең бакчабыздан җыярбыз. Җимеш агачлары утыртуны хөкүмәт тә алга ала, бик акыллы эш эшләдең,— диде.

Инде көзләр үтеп, карлар явып, салкын кышлар килде.

Ул көнне иртәдән бирле кар яуды. Хатыным Мәликә гадәтенчә ферма янындагы урам коесына суга китте. Мин аның судан тиз генә кайтмавына ияләнеп килә идем инде. Ләкин бүген ул аеруча озак торды. Мин ишек алдына чыгып, дүрт-биш кочак утын ярдым, малларга печән салдым, абзар-кураларны себердем, күршебез белән ике арадагы бәләкәй капкабыз таралган иде, аны рәтләп куйдым. Ә Мәликәм һаман кайтмады. Тагын шундый вак-төяк эшләр башкардым да, өйгә кереп, самавыр яңарттым. Аннары чәй хәзерләргә тотындым; өстәлгә поднос, чынаяк кебек әйберләр китереп куйдым, икмәк кистем. Ниһаять, капкадан Мәликәм кайтып керде. Аны күрү белән аптырап калдым, аның кулында чиләксез көянтә генә иде... Нәрсә булды икән моңа? Чиләкләре кая икән? Коега төшкәндер, дияр идең, коеның үз чиләге бар...

Ул ишектән кемнәргәдер ачуланып килеп керде:

— Тапканнар шаярыр кеше... Бала-чага эше булмыйча кем эше булсын... Көянтә-чиләкләремне кое янында калдырып, фермага кереп чыккан идем. Чыксам, чиләкләремнән җилләр искән. Гарифулла хатыны әйтә, мин коега килгәндә ике малайның чиләк тотып йөгергәннәрен күреп калдым, синең чиләкләреңне, мөгаен, шулар алып киткәннәрдер, ди.

— Суга баргач, фермага кермәгән булсаң, чиләкләрең дә югалмас иде, үзең дә вакытында кайткан булыр идең, йөрисең шунда... — дип каты гына бәрелеп алдым моңа.

Тышта әле һаман кар ява иде. Хатыным минем белән сүз көрәштереп тормады, башындагы шәлен рәтләбрәк яңадан бәйләде дә:

— Аларның кем малайлары икәнлеген барыбер белермен, чиләкләремне дә таптырырмын»— дип өйдән чыгып китте.

Капкага житкәндә генә аңа ике малай каршы очрады. Аларның икесенең кулында ике чиләк иде. Бу хәлне күргәч, мин дә йөгереп тышка чыктым.

— Мәликә апа, син чиләк югалткан дип ишеткән идек. Шушымы чиләкләрең? — диделәр алар ашыга-ашыга.

— Әйе, шушылар, гөлкәйләрем. Кайда иде?

— Чана шуганда кое яныннан, кар астыннан килеп чыкты. Аны малайлар күмеп киткән булганнар.

— Ни өчен?

— Син, Мәликә апа, коега килгән саен фермага керәсең ич. Синең чиләкләреңне яшереп кую турында малайлар әллә кайчаннан бирле сөйләшәләр иде инде.

Алар шулай диделәр дә чыгып йөгерделәр.

— Беләмче икәнсең син, әнкәсе. Хәзер инде ишек алдыбызга кое казыйсы гына калды миңа! — дидем хатыныма.

Ул, чиләкләр табылгач, тынычланган иде тынычлануын. Шулай да мине исәпкә калдырырлык итеп, нәрсә өчендер, ярым офтанулы, ярым сагынулы һәм үзенә бер төрле моңсу тавыш белән:

— Казырсың, әтисе, казырсың... Мәгәр мин фермага йөрүдән туктый алмамдыр. Үзем белән бергә эшләгән Хөмәйраләрне, Зарифаларны, Фахираләрне дә... ничә еллар буе үзем сауган сыерларымны да күрәсем килә. Сыерларымны әйтәм, ферма абзарына барып керсәм, иярен артымнан чыгалар, малкайларым, иярәнеп беткәннәр шул... — диде.

Бу сүзләрдән соң мин тирән уйларга чумдым. Менә мин әйтәм, ничек бит ул эш яраткан кеше, дим. Сөт аертырга, җөй тегәргә барганда да фермага, иптәшләре янына сугылгалап йөргәндер инде, дип тә уйлап куйдым. Ә мин аны, үземнең Мәликәмне, кайчакларда, нишләп озак тордың? — дип урынсызга рәнҗеткәнмен ләбаса... Һе, кешенең ни өчен ямансылавын белергә кирәк шул...

Күңелем нечкәреп китте, яшь чактагы кебек Мәликәмне кочаклап аласым килде, аның агара башлаган чәчләрен сыйпадым һәм:

— Дөрес әйтәсең, әнисе, эшләгән җир һич кенә дә онытылмый ул,— дидем.

Шул көннән алып мин: «Кайда, нишләп йөрисең син?» дип Мәликәмне борчымый торган булдым.

Ахырда шуны әйтеп үтим: мин ишек алдыбызга кое казырга өлгергәләгәнче колхозыбыз урам буйлап су трубалары үткәрде. Аның бер колонкасы нәкъ безнең өй каршысына туры килде. Хәзер суны шуннан гына алабыз. Шулай булса да, минем Мәликәм, я бүген колонканың суы болганчык, я бик саран агыза, дигән сылтау белән еш кына ферма коесына бара һәм анда шактый озак торып кайта.

Барса барыр инде, минем үземнең дә аякларым иртән тору белән гел мастерской тирәсенә тарта бит!

*Журналыбызның бу елгы 1—2 саннарында Эдуард Касыймовның «Бир кулыңны, дустым!» исемле повесте басылып чыккач, редакциягә укучылардан бик күп хатлар килде. Хат авторлары Э. Касыймовның бу әсәрен укыганнан соң туган фикерләрен язып җибәргәннәр. Төрле өлкәләрдә яшәүче һәм төрле эшләрдә эшләүче хат авторларының бу әсәрдәге персонажларга мөнәсәбәтләре дә төрлечә. Әмма ул хатларның барысы өчен уртак булган фикер дә ачык күренә: хат язучылар һәммәсе дә диярлек әсәрне нигездә яратып кабул иткәннәр һәм аның мөһим темасы күтәрүен искәртеп киткәннәр. Әсәрдәге теге яки бу персонажның эшенә, характерына бәйле рәвештә авторга сорау биреп язылган хатлар да байтак. Алдагы саннарның берсендә аларга автор үзе җавап бирергә әзерләнә. Ә бу санда без ул хатларның берсен укучыларга тәкъдим итәбез.*

## Әлбинә кулын бирерме?

**Эдуард Касыймов үзенең «Бир кулыңны, дустым!» повестенда мөһим проблемалар күтәрә, тормышка яңа аяк басып килүче яшьләр арасында мәхәббәт, әхлак, хезмәт мәсьәләләрен сурәтли. Авылга эшкә килүче укытучылар тормышын күрсәтү бик урынлы. Чөнки югары белем алган Әлбинә, Гөлсинә кебек чибәр кызлар яки шәһәрдә калырга тырыша, яисә район үзәген сайлый. Шунда җитәр-җитмәс нагрузка белән «ябышып» калырга ниятли. Сәбәпләр таба, яклаучылар эзли. Ә ерак авылларның мәктәпләре югары белемле кешеләргә мохтаҗ. «Бир кулыңны, дустым!» повестеның геройлары авылга килеп эшкә чумалар. Эш тә җиңел түгел, дәреслекләр, кирәкле әсбаплар җитешми, кайбер дәресләрне «җан көекләре» укыткан, балалар да төрле авылдан йөреп укыйлар. Бик авыр мәсьәлә ул, һәм автор да аны дөрес чагылдырган.**

**Инде мәхәббәт темасына килик. Әсәрдә бу мәсьәләгә карата дистәгә якын кешенең карашы чагылдырыла. Аларның берсен дә яшь-җилкенчәк диеп булмый инде. Акыл утырткан, югары белем алган кешеләр. Ә Борис белән Светлана мәхәббәтләренең тәүге җимешләрен көтәләр. Роберт белән Әлбинә мәхәббәткә бик җаваплы карыйлар, ә Гөлсинә белән Әхсән аңа бик өстән карыйлар. Вильдан да бу өлкәдә үз кыйбласын тапмаган, Котдус җимертеп дөнья күтәргә тотынмакчы. Шунысы ачык: бу мәсьәләгә һәркемнең үз бизмәне бар. Шуңа әсәр кызыклы да. Кара, укучы, чагыштыр, гыйбрәт ал һәм ошаганын сайла. Ә инде Әхсән белән Әлбинәнең мәхәббәтләре фаҗигале булуы повестьның бәясен тагын да күтәрә сыман.**

**Тормышта очрый торган табигый күренеш бу. Безне капчыкта яшереп булмаган кебек, тормыштагы чатаклыкларны да күрсәтмичә булмый инде. Һәм автор аны ташка басып чыгару белән дә чикләнми. Автор бе..к шагыйребезнең кызларга әйткән кисәтүле сүзләрен алар йөргән сукмакларга, кыя битләренә, хәтта өй эченә язып кую ягында. Бәлки, шулай кирәктер дә, чөнки «Бер ялгыш адымы аркасында никадәр кыз бала, бөтен гомеренә төзәлмәслек җәрәхәт алып, язмышын фаҗигале юлга сала».**

**Бер караганда Әлбинәнең эчкерсез мәхәббәтенә сокланып бетә алмыйсың. Яхшы тәрбия алып үскән, басынкы, әйбәт студент. Менә дигән тәрбияче булу өстенә, мәхәббәткә дә җитди карый. Автор аны шулай итеп күрсәтергә тырыша. Әмма әсәрне укыган саен, аңа карата шик арта. Әхсән әйткәнчә, чынлап та ул фәрештә түгел бит. Үз ихтыяры белән «Әлбинә утравына» барып, бер шешә кызыл аракыга**

яшьлеген корбан итүче 23—24 яшьләрдәге кыз бит ул. Һәм шул маҗараның нәтиҗәсе үзен сиздерә башлагач кына, өзгәләнә-бәргәләнә башлавы фаҗига түгел, мәзәк төсен ала. Аның җилбәзәк чоры артта калган, уңны сулдан аера алырлык югары белемле тәрбияче инде ул. Һич кенә дә аның мескен хәлен аңлыйсы, кайгысын уртаклашасы килми. Ә менә мәхәббәткә җиңел караган Гөлсинә һаман саф (үзе яхшы иптәш тә очраткан). Әлбинәнең авыр хәлен ишеткәч, ул коелып төшә, борчыла, дусты өчен теләсә нинди ярдәм күрсәтергә әзер. Безнеңчә, менә кемнән өлге алырга кирәк! Язучы Гөлсинәне дуслык, мәхәббәт мәсьәләсенә никадәр җиңел, өстән карап, җил кайдан иссә, шул якка башын сыгарга әзер торган итеп расларга тырышса да, аның инсафлылыгы, шәфкатьлелеге, рухи ныклыгы өскә калкып чыга.

Башта без Әхсәнне иптәшләре белән тиң күрәбез. Тик атлет гәүдәле булуы һәм спорт яратуы белән генә ул башка иптәшләреннән аерылып тора. Аның бөтен эшәкелеге ике якның да ризалыгы белән эшләнгән теге фаҗигадән соң ачыла. Шул көннән соң Әлбинә тагын яхшыра, булдыклы кешегә әверелә бара. Ә Әхсән, киресенчә, үҗәтләнә, мин-минлеккә бирелә, рухи яктан таркала. Әллә аны элек дуслары йөгәнләп тотканмы! Әллә биш ел буена Роберт та, Борис та Әхсәннең бер кимчелеген дә күрмичә, аерылып бер-ике ай торгач кына аның кем булуына төшенәләрме! Һәрнәрсәгә җитди караучы Робертка бергә укыган иптәшенең тискәре сыйфатлары элек тә билгеле булырга тиеш иде бит. Үзе яратып йөргән Әлбинә язмышы өчен алдан ук ул борчылырга, Әхсәнгә бу хакта әйтергә, һич югында, сак булырга кушып, Әлбинәне кисәтергә кирәк иде аңа. Ә ул шундый фаҗигане көтеп, Әлбинәнең кулын сорарга чиратта торган кеше сыман. Мескен хәлгә төшкән Әлбинәнең кулы нигә кирәк икән Робертка! Мәхәббәт хакынамы, аның яманатын яшереп калдыру өченме! Тик боларның берсенә дә ышанасы килми. Туачак балага ул гомер буе ялган ата, Әлбинәгә ялган ир була алмый. Кайчан да бу хәл фаш булачак. Үзенең тотанаксызлыгы аркасында мәсхәрәгә калып, бала көткән теләсә нинди кызның кулын көтеп торган Роберт кебек егетләр тормышта, белмим, буламы икән! Ә менә була икән шул. Хәтта икәү. Әлбинәнең бер ягында Рабига җиңги — үзенең улына аны килен итмәкче. Икенче якта бар яктан сыналган, яхшы Роберт аның кулын сорый. Ә Әлбинә аны яратамы соң! Яки «беткән башын» түбән иеп, аның тәкъдимен кабул итәрме! Ләкин Гөлсинә бит әнә ни ди: «Берәүләр ким-хур булудан качып, ашык-пошык кияү табарга омтыла. Табалар да. Кем очраса, шуңа ябышалар... Әмма яратмыйнитми чыккан кеше белән гомер итүе тагы...» ди. Ләкин Әлбинә өчен тормышның тагын бер куркыныч ягы бар. Ул, «намусын» югалтмас өчен (кеше-фәлән сизгәнче), кемгә булса да кияүгә чыгып калырга тиеш. Чөнки ул «укытучы шул. Укытучы булмаса, бер хәл иде». Мәхәббәткә җитди караш һәм намусны саклау шулай була микәннн! Кыскасы, кешеләрнең дә — берәүләрен ак кына дип, икенчеләрен кара гына итеп күрмәсәк иде. Ә бу әсәрдә шул нык сизелә. Әлбинә гөнаһсыз асыл зат итеп, Әхсән үзе күтәрә алмаслык эшәкелекләр иясе итеп бирелгән.

Ш. ШӘЯХМӘТОВ,
Башкортстан АССР,
Стәрлебаш авылы.

○ ◇ ○

**С. Червонная,**

сәнгать фәннәре кандидаты.
Мәскәү.

# ИМТИХАН УҢЫШЛЫ УЗДЫ[1]

Бөек Октябрьның 50 еллыгы алдыннан Мәскәүдә, Үзәк күргәзмә залында, «Совет Россиясе» күргәзмәсе ачылды. Ул — художникларның халык алдында зур отчеты булды.

Күп милләтле Россия Федерациясенең төрле республика, өлкә художниклары иҗатын берләштергән бу күргәзмә Совет Россиясе халыкларының дуслыгын һәм бердәмлеген, милли культураларның чәчәк атуын тагын бер кат раслый. Шул ук вакытта һәр халыкның культурасына үзенең поэтик сафлыгын саклый торган милли үзенчәлек, колорит хас. Бу милли колорит тирән тамырлары белән халык тормышына, халык иҗатына барып тоташа. Ул нинди дә булса милли чикләнгәнлектән, тарлыктан ерак тора.

Моны татар художниклары иҗаты мисалында да ачык күрергә була. Чагыштыру өчен сынлы сәнгать, скульптура, графика өлкәсеннән мисаллар алыйк.

Харис Якуповның «Уйлану. Терелләр һәм үлеләр» дигән картинасы күргәзмәдә аерым урын алып тора. Ул катлаулы интернациональ темага — ике культура көрәше һәм буржуаз культураның кризисы темасына, замандашыбызның катлаулы һәм бай рухи дөньясы белән формалистик сәнгатьнең интеллектуаль һәм эмоциональ гариплеге арасындагы тирән каршылыклар темасына багышланган бердәнбер полотно. Бу — нинди дә булса чит ил музеенда яки күргәзмә залында очраклы рәвештә натурадан күчереп алынган күренеш кенә түгел, ә рациональ төзелгән һәм уйланырга мәҗбүр итә торган картина.

Музейның ак стенасы фонында абстракт полотноларның мәгънәсез буяулары күренә. Кешеләр ул күренешләрдән аптырап калганнар. Әмма черек буржуаз культураның цинизмыннан үзләренең рухи дөньялары белән өстен торган көчле, горур кешеләр болар. Аларның нинди милләт кешеләре икәнлеге тәгаен билгеле түгел. Алар итальяннар, немецлар, серблар, французлар, чехлар булырга мөмкин. Художник, формаль сәнгать барлык кешеләргә дә ят, дип әйтергә тели сыман.

Х. Якупов иҗатына тәэсирле лиризм, шигърият хас. Вахитов исемендәге колхоз сыер савучысы Фәүзия Гәрәева портретында бу сыйфатлар аеруча яхшы гәүдәләнә.

Нәүфәл Адылов — «Совет Россиясе» күргәзмәсендә катнашучы бердәнбер татар скульпторы. Аның агачны уеп эшләгән «Батыр» исемле әсәре югары профессиональ осталык белән башкарылган. Адылов иҗатында декоратив сәнгать халык иҗаты традицияләре белән оста бәйләнгән. Бу скульптурада декоративлык өстенлек итә. Скульптура портретының композициясе тапталмаган.

«Совет Россиясе» сәнгатендә беренче тапкыр катнашучылар күп. Алар арасында Эмиль Ситдиков та бар. Аның «Төш вакыты», «Беренче», «Колхоз ветераннары» дигән линогравюралары хәзерге татар авы-

---

[1] «Социалистик Татарстан» газетасының үткән елда чыккан 253 нче саныннан күчереп басыла.

лы кешеләренә багышланган бөтен бер әсәрне хәтерләтә. Андагы милли үзенчәлек тышкы колорит булып кына күренеп калмый, ә әсәрдәге характерларны, тормыш ритмын һәм эчтәлеген сугара.

«Төш вакыты» дигән гравюрада хезмәт иясе кешесенең матурлыгын тою хисе бик яхшы ачыла: бу — әсәрдә сурәтләнгән киң җилкәләр яки көчле куллар гына түгел, бәлки беренче чиратта геройларның йөзләрендәге югары кешелек сыйфатларында күренә.

«Беренче» гравюрасы хисләргә аеруча бай. Монда кулына бала тоткан яшь хатын игътибар үзәгендә; иптәшләре аңа балаларча кызыксыну һәм шул ук вакытта хатыннарга хас горурлык белән карап торалар. Йомшак зәңгәр буяу куллану әсәрне тагын да ачып җибәргән. Гравюра бик матур һәм яхшы төзелгән. Иң мөһиме — анда гүзәл, көчле, яхшы һәм горур, катлаулы һәм рухи яктан бай кешеләр сурәтләнгән.

Шулай итеп, татар графикасы милли татар сынлы сәнгатенең гуманистик традицияләрен үстерә.

Татарстан художниклары коллективы үзенең составы буенча күп милләтле. Казанда һәм республиканың төрле шәһәрләрендә татарлар белән бергә башка милләт художниклары да эшли. Алар, халык иҗатының бай чыганагына, тарихка һәм татар халкының хәзерге тормышына, поэтик фольклорга мөрәҗәгать итеп, республиканың художество культурасын үстерүгә өлеш кертәләр.

Художник Ирина Колмогорцеваның татар халык әкияте «Гөлчәчәк»кә иллюстрацияләре — моның яхшы мисалы. Бу иллюстрацияләр образлы, фантазиягә бай булулары, халык поэтик чыганагыннан оста файдаланып эшләнүләре белән күргәзмәгә килүчеләрнең игътибарын җәлеп итә.

Йомгак ясап шуны әйтергә мөмкин, Татарстан художниклары «Зур Волга» зона күргәзмәсендә дә, «Совет Россиясе» күргәзмәсендә дә югары художестволы әсәрләре белән катнаштылар.

1970 елда булачак һәм Владимир Ильичның тууына 100 ел тулуга багышланачак күргәзмәдә дә Татарстан художниклары тагын да активрак катнашырлар, әле кузгатылмаган яңа темаларга яңа әсәрләр иҗат итәрләр. Россия художникларының һәм шулай ук башка автономияле республика художникларының тәҗрибәсен өйрәнү, һичшиксез, татар художникларына бу бурычларны уңышлы хәл итәргә булышыр. Совет Татарстанындагы сынлы сәнгатьнең милли мәктәбе коммунистик партиялелеге, тормышы белән, халык идеаллары белән тыгыз бәйләнгән булуы белән көчле. Татар халкы талантлы художниклары белән горурлана ала.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Шушы елның 24 маенда Татарстан язучыларының ачык партия җыелышы булды. В. И. Ленинның тууына 100 һәм Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 50 ел тулу көннәренә ничек әзерләнү мәсьәләсен тикшерүгә багышланган ул җыелышта Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Зәки Нури доклад белән чыкты. Ул бу ике зур датаны каршылау уңае белән язучылар алдында торган бурычлар турында сөйләде.

— В. И. Ленинның тормышы Казан белән тыгыз бәйләнгән,— диде докладчы.— Ул Казанда укыган, беренче революцион чыныгуын да шушында алган. Революциядән соң да В. И. Ленин Татарстан тормышы белән туктаусыз кызыксынып һәм аның үсүенә ярдәм итеп торды. Моның шулай икәнлеген тарихи документлар бик ачык күрсәтә. Без, язучылар, ул документларны яхшылап өйрәнергә һәм үз әсәрләребез аша халыкка ирештерергә тиешбез.

З. Нури үзенең докладында В. И. Ленинның Казан чоры тормышын сурәтләүдә татар язучыларының әле җитәрлек эшләмәүләрен дә искәртеп үтте.

— Совет власте елларында,— диде ул,— Татарстан промышленность үсеше буенча да, авыл хуҗалыгы һәм культура үсеше буенча да танымаслык дәрәҗәдә алга китте. Бу үзгәрешләр барысы В. И. Ленин җитәкчелеге, Ленин идеяләре белән бәйләнгән. Без, язучылар, үз әсәрләребездә республикабызда булган бу үзгәрешләрне, аның бүгенге уңышларын һәм ул уңышларны тудыручы кешеләрен ачыграк һәм киңрәк яктыртырга тиешбез. Җыелыштан соң һәр язучы бу хакта уйлансын һәм җиң сызганып эшкә тотынсын иде.

Аннары З. Нури В. И. Ленинның 100 һәм Татарстанның 50 еллыгына әзерлек буенча түбәндәге конкрет тәкъдимнәрне кертте:

— Республикабыз газета-журналларында В. И. Ленин һәм Татарстан тормышына кагылышлы очерклар урнаштырып барырга;

— В. И. Ленинның күреп белгән һәм аның идеяләрен тормышка ашыруда актив катнашкан өлкән буын революционерлар тормышын киңрәк яктыртырга;

— Башка милләт язучыларының В. И. Ленин турындагы иң яхшы хикәяләрен һәм очеркларын, тәрҗемә итеп, «Казан утлары» журналында бастырып барырга.

Язучылардан Ж. Тәрҗеманов, Г. Ахунов, М. Садри, М. Әмир, Л. Ихсанова, М. Елизарова, С. Хәким, Г. Латыйп һәм И. Гази да В. И. Ленинның тууына 100 ел һәм Татарстанның 50 еллыгына әзерлек мәсьәләсе буенча үзләренең фикерләре белән уртаклаштылар, конкрет тәкъдимнәр керттеләр.

— Алдыбызда торган ике зур дата уңае белән,— диде Ж. Тәрҗеманов,— минч өч тәкъдим ясамакчы булам. Һәркайсыбызга мәгълүм, опера һәм балет театрыбызның милли репертуары мәсьәләсе шактый кыен. Соңгы елларда либреттолар бөтенләй диярлек язылмый. Менә шуны һәм алдыбызда торган зур юбилейларны искә алып, безгә, бүгеннән башлап, опера һәм балет театрыбыз өчен яхшы либреттолар иҗат итү эшенә керешергә кирәк. Якынлашып килгән зур даталар уңае белән, өлкән буын язучыларыбызның элекке елларда бик популяр булган, әмма соңгы вакытларда игътибардан читтә кала башлаган яхшы әсәрләрен кабат бастырып чыгару эшенә керешергә дә бик вакыт, минемчә. Ә андый әсәрләр бездә байтак. Өченче тәкъдимем шул: газета-журнал редакцияләре В. И. Ленин һәм Татарстан тормышын чагылдыруга багышланган иң яхшы әсәрләргә конкурс игълан итсәләр, бик шәп булыр иде. Бу эш язучыларны рухландырып җибәрер һәм әдәбиятыбызны тагын да үстерергә ярдәм итәр иде.

— Совет власте елларында,— диде Г. Ахунов,— Татарстан илебездәге иң алдынгы нефть республикаларының берсенә әверелде. Нефть чыгару шактый катлаулы эш. Безнең нефтьчеләр әнә шул катлаулы эшне уңышлы башкарып киләләр, хәзер йөз миллион тонна нефть бирү өчен көрәш бара. В. И. Ленинның 100 еллыгын һәм Татарстанның 50 еллыгын каршылаган көннәрдә нефтьчеләребез тормышын да әдәбиятта тулырак чагылдырасы иде. Бу эшкә яшь язучылар гына түгел, бәлки тәҗрибәле өлкән язучыларыбыз да актив катнашсын иде. «Правда» газетасының үз хәбәрчесе Р. Сабиров һәм «Советская Россия» газетасының үз хәбәрчесе М. Зарипов икесе бергәләп Мәскәүнең «Недра» нәшрияты өчен зур күләмле очерклар китабы яздылар. Менә шул очеркларны «Казан утлары» журналында бастыра башларга тәкъдим итәм мин.

Сез барыгыз да отставкадагы полковник Барый Юсуповны яхшы беләсез инде. Аның турында «Казан утлары»нда кечерәк кенә очерк та басылып чыкты. Барый абый үзе

«И старость — радость» («Картлык та — шатлык») исемле китап язган. Без Әлмәттә аның ул китабын укып чыктык. Кызыклы һәм гыйбрәтле китап ул. Менә шул китапны тизрәк бастырып чыгару чарасына керешәсе иде.

Шагыйрь С. Хәким, алда торган зур даталарны үткәрүгә әзерләнгәндә, һәр язучыны бу мәсьәләгә бик җитди карарга чакырды. В. И. Ленин әсәрләрен күбрәк укыган саен, аның фикерләренең никадәр тирән һәм дөрес булуына тагын да ныграк төшенәсең, диде. Ленин хезмәтләре бүген дә бик актуаль.. В И. Лениннның тормышы һәм революцион эшчәнлегенә бәйләнешле әсәрләр язганда, без моңа игътибар итәргә тиешбез. Әйтәсе килгән сүзем шул, язучыларыбызның әсәрләре бүгенге көнгә авазаш булсын, бүгенге көн таләпләре югарылыгында торырлык булсын иде.

— Безнең язучылар арасында,— диде Н. Дәүли,— В. И. Ленинга багышлап нинди дә булса әсәр язмаган кеше юктыр. Ул әсәрләр моңарчы да басылып килде, хәзер дә чыккалап тора. Әмма ул әсәрләр хакында мактап та, яманлап та матбугатта сүз әйткән кеше юк. Минемчә, бу хакта уйланырга һәм ул әсәрләр турында да сүз әйтергә кирәк булыр.

— Алдыбызда торган бу зур даталарны билгеләп үтү уңае белән төзелгән планыбыз яхшы,— диде И. Гази.— Әмма ул планны тормышка ашырырга кирәк. Мин барлык иптәшләрне дә бу мәсьәләгә җитди карарга чакырам. Планыбыз кәгазьдә генә калмасын, тормышка ашсын иде. Югыйсә, без язучыларга иҗатсызлык хасрак. Кәеф булса — язабыз, кәеф булмаса — юк. Бу мәсьәләдә алай булмасак иде. Илһамны көтеп кенә ятарга ярамый. Үзебезне эшкә куша белергә, максат, план белән эшләргә кирәк. Яшьләр өлкәннәргә, өлкәннәр яшьләргә ышанып утырырга тиеш түгел. Һәркайсы көченнән килгәнчә тырышсын иде. Ярдәм кирәк булса, без язучыларга ярдәм итәчәкбез. Берәр җиргә барырга теләсәләр, иҗат командировкалары да бирә алабыз. Алда торган зур бәйрәмнәрне иҗади уңышлар белән каршылау өчен, хәзер безгә энергиябезне уңлата арттырып эшли башларга кирәк. Безнең барлык уңышларыбыз В. И. Ленин эшенең нәтиҗәләре. Без моны һәрвакыт истә тотарга һәм үз әсәрләребездә чагылдырырга тиешбез.

## ПОЭЗИЯ СЕКЦИЯСЕ УТЫРЫШЫ

21 майда Татарстан язучылар союзы каршындагы поэзия секциясенең чираттагы утырышы үткәрелде. В. И. Ленинның 100 еллыгына һәм ТАССРның 50 еллыгына яңа җырлар иҗат итү турында сөйләшүгә багышланган ул утырышта, шагыйрьләрдән тыш, Татарстан композиторлары да катнашты. Утырышны шагыйрь Сибгат Хәким ачты.

— В. И. Ленин белән Татарстанның бәйләнешен чагылдырган җырларны,— диде ул,— безнең шагыйрьләр һәм композиторлар тудырырга тиеш. Ленинның Кокушкино табигатен яратканлыгы мәгълүм. Шагыйрь белән композитор бергәләп шул якларда булып кайтсалар, һичшиксез, әйбәт җыр тудыра алырлар иде. Табигать аларга үзе сюжет бирергә мөмкин...

— Бу сөйләшү,— диде композитор Заһид Хәбибуллин,— бик вакытлы һәм кирәкле. Шагыйрьләр белән композиторлар, гомумән, ешрак очрашсыннар, тыгызрак элемтәдә торсыннар иде. Шагыйрьләрдән мин шуны үтенәм: гражданлык темасына язу белән бергә, яшьләрне югары әхлаклы итеп тәрбияләүгә юнәлдерелгән җырлар да язсыннар иде алар. Андый җыр текстларына без бик мохтаҗ. Концерт программаларында сай эчтәлекле җырлар шактый урын ала. «Аерыл», «саргаям» дигән сүзләр белән генә ерак китә алмабыз. Төзүчеләр, колхозчылар турында яхшы җыр текстлары кирәк. Үткен такмаклар да бик аз, алар кайчан туар икән?

Сара Садыйкова үзенең чыгышында әдәби кичәләрдә башкарырлык җырлар аз булуын, концерт программаларын яңартырга кирәк икәнлеген искәртеп үтте һәм үзенең Ленинга багышлап язган җыр текстын укыды.

Гөлшат Зәйнашева Татарстанда гына түгел, бәлки Бөтенсоюз күләмендә популяр булырлык җыр текстлары һәм җырлар иҗат итәргә вакыт икәнлеген әйтеп үтте һәм С. Хәким белән Н. Арслановның җәлилчеләрнең батырлыгын сурәтләүгә багышланган текстларына да көйләр язылсын иде дигән теләк белдерде.

— Соңгы елларда,— диде композитор Б. Мулюков,— патриотик темага җырлар аз язылды. Язылганнары да мактанырлык түгел. Язылган көйләрне һәм җырларны башта Композиторлар һәм Язучылар союзында тыңлауны гамәлгә кертергә кирәк. Шулай иткәндә, начар җырлар дөньяга чыкмас иде... Радио хезмәткәрләренә дә үпкә белдерәсе килә. Элек радиода эшләүче иптәшләр шагыйрьләр белән композиторларны чакырып сөйләшә, киңәшә торганнар иде. Совет музыкасы яңалыкларын — яңа кантаталарны, ораторияләрне шагыйрьләр белән бергәләп тыңлауны гадәткә керткәндә дә начар булмас иде.

Утырышта шагыйрьләрдән Н. Арсланов «Андый партия бар» һәм «Унике батыр турында баллада», С. Хәким «Таулар, таулар», Г. Зәйнашева «Казаным» исемле җыр текстларын укыдылар. Исемнәре аталган кешеләрдән тыш, утырышта шагыйрьләрдән Ә. Давыдов, З. Нури, Ә. Исхак, композиторлардан Ф. Әхмәдиев, Ә. Бакиров һәм А. Вәлиуллин да фикер алышуда катнаштылар.

## ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР КИҢӘШМӘСЕ

Шушы елның 14—15 маенда Казанда Идел буе автономияле республикалары тәнкыйтьчеләренең киңәшмәсе үткәрелде. Анда Мари, Мордва, Удмурт, Чуваш һәм Татарстан АССР язучылары союзларыннан килгән вәкилләр катнашты. Киңәшмәгә «Дружба народов» журналы һәм «Литературная Россия» газетасы редакцияләре хезмәткәрләре дә килгән иде. «Дружба народов» журналы инициативасы белән

үткәрелгән ул киңәшмәне Л. А. Терокопян (журналның тәнкыйть бүлеге мөдире) ачты.

— Дөньяда,— диде ул,— күп милләтле илләр шактый күп. Ләкин ул илләрнең күбесендә милли культураларның үсешенә тиешенчә әһәмият бирелми. Ә безнең илдә бөтенләй башкача. Безнең илдә һәр милләткә, шул исәптән аларның культура үсешенә дә, бик зур игътибар бирелә. Әмма, шулай булуга да карамастан, Идел буе республикаларының әдәбияты үзәк матбугатта бик аз яктыртыла. Моны һич тә нормаль хәл дип исәпләп булмый. Хикмәт бу республика вәкилләренең яхшы әсәрләре булмавында түгел. Әйбәт әсәрләр дә языла. Ләкин алар үзәк матбугатка вакытында җиткерелми, күрәсең.

Л. Терокопян А. Гыйҗләҗевның «Өч аршын җир» повестена, Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясенә, А. Расихның «Ике буйдак» романына тукталды һәм аларның яхшы әсәрләр икәнлеген дәлилләр белән аңлатып бирде. Удмурт һәм чуваш әдәбиятларыннан да мисаллар китерде.

— Без,— диде Р. Мостафин,— һәр көн иртән Мәскәүдән тапшырыла торган һава хәлләре турында белдерү тыңлыйбыз. Әгәр бүген Мәскәүдә 20 градус җылы булуын ишетсәк, белеп торабыз: ике-өч көннән Казанда да шундый ук температура булачак. Әдәбият өлкәсендә дә шулайрак. Безнең әдәбиятыбыз Мәскәү язучыларыннан өчдүрт елга соңгарак калып бара, минемчә. Мәсәлән, Н. Фәттахның «Артта калган юллар», Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» исемле әсәрләрендә күтәрелгән мәсьәләләрне Мәскәү язучылары моннан алты-җиде ел элек үк күтәреп чыкканнар иде инде.

Әдәбиятыбыздагы бу күренешнең сәбәпләрен Р. Мостафин язучыларның мөһим мәсьәләләрне вакытында тотып ала алмаулары белән аңлатты. Ул язучыларны мөһим мәсьәләләрне вакытында күреп алырга һәм аларны үз әсәрләрендә кыю яктыртып барырга чакырды. Аннары Р. Мостафин татар әдипләренә хас булган гомуми кимчелекләргә тукталды. Язучыларыбыз, диде ул, яңа материалларны да иске, традицион формаларга төреп бирәләр. Шунлыктан аларның әсәрләре урта кул әсәрләр булып кына кала. Шушы фикерен мисал итеп, Э. Касыймовның «Бир кулыңны, дустым!» повестена кагылды һәм ул әсәрдә персонажларның эчке кичерешләре шактый уңышлы сурәтләнгән булса да, интеллектуаль яклары тиешенчә ачылып җитмәвен әйтте.

Киңәшмәдә Татарстан вәкилләреннән Р. Харисов, Т. Галиуллин һәм И. Нуруллин иптәшләр дә чыгыш ясадылар.

Р. Харисов үзенең чыгышын «Беренче карлыгач» исемле коллектив җыентыкта әсәрләре басылган яшь шагыйрьләр иҗатын бәяләүгә багышлады.— Соңгы елларда,— диде ул,— яшь шагыйрьләр үз тавышларын шактый нык ишеттерә башладылар. Бу — куанычлы хәл. Әмма шунысы күңелне борчый: ул шагыйрьләр нигәдер барысы бер төрле тавыш белән җырлый. Барыннан да бигрәк, шул нәрсә шиккә төшерә, әлеге яшь шагыйрьләр бер төрле темага язалар, бер үк мәсьәлә күтәрәләр. Үзе сөйләгән сүзләргә дәлил итеп, Р. Харисов «Беренче карлыгач»та катнашкан авторларның әсәрләреннән мисаллар китерде, хәтта ул авторларның шигырennән берәр юл алып, бер үк темага багышланган төзек шигырь язарга мөмкин булуын да исбатлап бирде.

— «Дружба народов» журналы,— диде Т. Галиуллин,— безнең иң якын һәм яраткан журналыбыз. «Идел» («Волга») журналы, гәрчә ул Идел буе республикалары язучыларының әсәрләрен яктыртып барырга тиешле булса да, ышанычыбызны акламады. Анда Идел буе республикалары язучыларының әсәрләренә урын бик аз бирелә. Ул журнал күбрәк Мәскәү язучыларының әсәрләрен бастырырга омтыла. Ә безнең әдәбият турында ул журнал хезмәткәрләре бары тик ишетеп кенә беләләр.

Т. Галиуллин, үзенең бу фикерләрен раслау өчен, дәлилләр китерде. Аннары әдәбиятыбызның соңгы елларда бик нык үскәнлеген әйтте дә, шуңа мисал итеп, татар язучыларының поэмаларына тукталды. (Аның фикерләре белән кызыксынган кешеләргә «Казан утлары» журналының бу елгы икенче санында басылган «Поэманың барыр юллары» исемле мәкаләне укырга киңәш итәбез.)

— Мәсьәләне фәнни нигездә хәл итү,— диде И. Нуруллин,— заман таләбенә әйләнде. Әдәби процессны тикшергәндә дә шул таләпне күздә тотып эш итәргә кирәк, әмма, кызганычка каршы, әдәби әсәрләргә киңрәк караш ташлый алмыйбыз әле без.

Аннары И. Нуруллин социалистик реализм мәсьәләләренә тукталды һәм идеясе әйбәт булып та әдәби эшләнеше ягыннан йомшак булган әсәрләрне социалистик реализм әсәре дип атарга кирәкмәвен әйтте. Шулай ук, диде ул, төп геройларына карап кына әсәрләргә бәя бирү белән дә килешеп булмый. Әйтик, төп герое тискәре булган әсәрләрне дә, бары тик шул төп герое тискәре булган өчен генә социалистик реализм әсәре түгел дип бәяләргә ярамый.

Киңәшмәдә мари әдәбиятында проза жанрының торышы турында К. Васин, әдәби элементләр һәм бүгенге мордва әдәбияты турында Н. Черапкин һәм Алешкин, чуваш романнарының үзенчәлеге турында Г. Хлебников, удмурт әдәбиятының хәзерге хәле турында Ермолаев иптәшләр дә шактый кызыклы чыгышлар ясадылар.

Киңәшмәдә катнашучыларның барысы да киләчәктә «Дружба народов» журналы редакциясе Идел буе республикалары язучыларының әсәрләренә дә күбрәк урын бирсен иде, дигән теләкне белдерделәр.

## ЖУРНАЛ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

22 майда Язучылар союзының киңәйтелгән идарә утырышында «Казан утлары» журналының бу елгы 1—2—3—4 саннарында басылган материаллар хакында фикер алышу үткәрелде. Язучы Г. Галиев журналның әлеге саннарында басылган хикәя һәм очерклар турында сөйләде.

— Мин,— диде ул,— барлык хикәя һәм очерклар турында да озаклап тукталмастан, кайберләре турында гына фикеремне әйтеп китәргә булдым. Әле моннан берничә көн элек кенә проза секциясендә хикәяләр турында сөйләшү үткәрелгән иде. Анда А. Ганиевнең «Янәшә» («Казан утлары», өченче сан) исемле хикәясен М. Әмир бик мактады, ә Ф. Хөсни йомшак хикәя ул, диде. Бу хикәя шома язылган, әмма ул миңа ошамады. Хикәя озын, ләкин аның мәгънә ягы сыек... Мин бу хикәянең җирлеген, туфрагын таный алмадым...

Мин Р. Батуллин хикәяләрен укып барам, аны яратам. Әмма «Мираж» хикәясен укыгач, аптырабрак калдым. Анда ике кешенең сусыз һәм ризыксыз килеш ком сәхрәсендә адашып йөрүе сурәтләнгән. Ул кешеләрнең берсе бик нык ихтыярлы, икенчесе йомшак итеп бирелгән. Болай булмый бит инде иптәшләр! Бу хикәянең дә җирлеге безнең тормышка, безнең шартларга хас түгел. Ком сәхрәсе бездән шактый ерак бит...

Очерклар турында берничә сүз.

Бүгенге көн, бүгенге темага язылган хикәяләр булмаган кебек үк, журналның бу саннарында бүгенге көн турында очерклар да юк. «Депутат» исемле очерк, бүгенге көнгә багышланган булса да һәм исеменә карaганда бик зур нәрсә вәгъдә итсә дә, анда депутатка хас сыйфатлар бик сыек бирелгән. Верховный Совет депутаты шифер табуда булышудан ары китми. Бу очеркта чигенүләр артык күп һәм ул ялыктыргыч озын язылган. Кыскасы, мине канәгатьләндермәде бу очерк.

Г. Галиев журналда истәлекләргә урын бирелүен хуплады һәм М. Максуд, В. Хангильдин истәлекләре үзендә бик җылы тәэсир калдыруын әйтте.

— Бу саннарда,— диде Ш. Рәкыйпов,— зур күләмле проза әсәрләреннән Э. Касыймовның «Бир кулыңны, дустым!» исемле повесте басылды. Әйбәт ахлакны, пакьлекне яклап язылган бу әсәрендә Э. Касыймов персонажларның тормышын ышандырырлык итеп сурәтләгән. Әсәрнең теле дә матур. Автор Әхсәннең карьерист һәм ышанычсыз кеше икәнлеген уңышлы күрсәткән. Персонажларның рухи хәлен сурәтләгәндә Эдуард табигать күренешләреннән уңышлы файдаланган. Тулаем алганда, бу повесть әйбәт һәм Татарстан китап нәшрияты аны 1969 елда китап итеп бастырырга да планлаштырды инде.

В. Нуруллинның «Шинельсез солдатлар» исемле повесте Ватан сугышы чорындагы авыл халкы тормышын сурәтләүгә багышланган. Бу темага бездә байтак әсәрләр язылды инде. Әмма В. Нуруллин аларны кабатламый. Минемчә, аның отышлы ягы — вакыйгаларны бала авызыннан сөйләтүдә һәм тормышны дөрес итеп сурәтләүдә. Кыскасы, бу повестьны укыгач, В. Нуруллинның өметле яшь язучы икәнлегенә тагын бер кат ышандым.

М. Маликованың «Казан каласы — таш кала» исемле повесте җылы гына тәэсир калдыра. Бу — Мәдинәнең беренче зур әсәре. Шунлыктан анда эшләнеп бетмәгән образлар да очрап куя. Әмма, тулаем алганда, ул әсәр әйбәт тәэсир калдыра.

Ә. Баянов һәм Ә. Давыдов журналның 1—4 саннарында басылган шигырьләргә бик киң тукталып, аларга җентекле анализ ясадылар. (Аларның ул чыгышлары газета-журналларда басылачак).

Журналда басылган материаллар турында сөйләшүдә язучылардан Г. Ахунов, А. Шамов, М. Әмир, Н. Дәүли, И. Гази һәм әдәбият белгече Ә. Нигъмәтуллин (Уфа) да катнаштылар һәм журналның эшен яхшырту юнәлешендә күп кенә фикерләр әйттеләр, тәкъдимнәр ясадылар.



# Әнвәр Давыдов

*Шушы елның 23 июнендә күренекле шагыйребез Әнвәр Давыдов вакытсыз вафат булды.*

## Хуш, кадерле, олы дустыбыз!

**«Хәзер нинди сүзләр генә әйтсәң дә, ничектер, төссез тоела. Әнвәр Давыдов татар совет поэзиясенә вулкан аткан кебек шаулап килеп керде, үзенә бер төрле үзенчәлекле юл салып алга омтылды һәм шул яңача, Маяковскийча фарватердан бер генә адым да тайпылмады. Ул поэзиядәге һәртөрле шаблон фикергә, һәртөрле шаблон тәгъбиргә каршы көрәште.**

**Шигырьдә образ, характер булу — бик зур байлык ул. Әнвәр Давыдов тере образлар, безнең замандашларыбызның матур характерларын тудыруга ирешге. Ферма кызы Гөлсәгъдә, тракторчы Мөнирә, художник Әмир һәм башка истә калырлык образлар белән татар поэзиясе киңәйде. Бу яңачалык төзү материалларының да яңача булуын таләп итте. Зур талантлы, бай эрудицияле шагыйрьгә бу йөкне күтәрү авыр булмады. Татар поэзиясенең традицияләрен саклаган хәлдә, ул шигырьгә интернациональ поэзия үзенчәлекләрен кыю кертте, үзенең егерме елдан артык дәвам иткән иҗаты белән яңачалыклы поэзия юнәлеше тудырды. Хәзерге яшь шагыйрьләрнең үз иҗат эшчәнлекләрен Әнвәр Давыдовча башлап җибәрүләре шуңа бик әйбәт дәлил.**

**Безгә, исән калганнарга, хәзер бу гаять үзенчәлекле, әдәбиятка билгеле эз салган шагыйрьнең әсәрләрен әйбәтләп туплап чыгарырга, аны татар совет әдәбиятының байлыгына әйләндереп, җәелдерергә, өйрәнергә кирәк. Бу — шагыйрь истәлеген иң яхшы хөрмәтләү булыр иде.**

Син гомереңне яшьтән багышладың
Зур көрәшле чорга каратып,
«Коммун Әнвәр» диеп авылдашлар
Атадылар сине яратып.
Син аларның матур ышанычын
Бар тормышың белән акладың.
Вакчыллыктан өстен була белдең,
Гаделлекне генә якладың.
Син сүздә бер,
Эштә башка төрле
Була алмадың, туры булдың син.
Акылың белән безне, шигъриятне
Нурландырып һаман тордың син!
Шигъриятне замполиттай алга
Син күтәрдең, аңлап зур хакың!
Син чын шагыйрь һәм чын кеше идең,
Җиңел булсын инде туфрагың!

**ХИСАМ КАМАЛОВ.**

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210